ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№9 (368)
СЕНТЯБРЬ 2022

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ЧӘКЧӘКТӘ НИЧӘ ТӨШ БАР?

«ЦИФРЛЫ» ТАТАРСТАННЫҢ ТАТЛЫ ТӘМЕ

4 612750 670011

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская,
Ольга Туманская,
Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Айсылу Мансурова,
Михаил Рябинин, Ксения Сёмина, Мадинә Тимерҗанова
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова,
Анастасия Хатыйпова, Алсу Шакирова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Анна Атаманова, «Мисс Татарстан – 2022».
Рамил Гали фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 700 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: О–2672
Басарга кул куелды: 09.09.2022
Басмадан чыкты: 15.09.2022

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Гөлназ Яруллина,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9655-826-037
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 3050 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 5750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

ЧӘКЧӘКТӘ НИЧӘ ТӨШ БАР?

Казан август аенда гастрономик сәяхәтләр лидеры дип танылды. Сораштыруларны «Работа.Ру» һәм «ЮKassa» сервислары үткәргән, анда Россиянең 3,2 мең кешесе катнашкан һәм респондентларның 47%ы Казан өчен тавыш биргән.

Туристларның гастрономик сәфәрләр урынын сайлавында төп фактор булып үзенчәлекле милли кухня тора, дип аңлата аналитиклар. Һәм бездә милли аш-су нәкъ шундый үзенчәлекле – атаклы өчпочмак, гөбәдия, кыстыбыйдан тыш, монда каклаган каз, татар хамонын, чәкчәкне татып карарга була... Сүз уңаеннан, сез чәкчәктә ничә төш барлыгын беләсезме? Ә без беләбез – санадык! Чөнки бездә ел шундый – Цифрлы технологияләр елы. Бүгенге гаять тиз үзгәрешләр заманында шаккаткыч цифрлы трансформацияләр һәрберебезнең тормышына кагыла, барлык тармакларга үтеп керә. Басмабызның әлеге санында без тормышыбызны яхшырак, җайлырак, уңайлырак ясарга сәләтле мәгълүмати технологияләр турында сөйлибез. Һәм инде, әлбәттә, кунакларны чәкчәк, гөбәдия, каклаган каз һ.б.лар белән сыйлыйбыз, чөнки кунакчыллык – Казан өчен гадәти күренеш. Лондонда басылган «Виды Казани» литографияләр альбомы авторы Эдвард Турнерелли әле 1839 елда ук болай дип язып калдырган: «Казаннан кала, кунакчыллык шулкадәр киң таралган, шул ук вакытта гадәти күренеш саналган башка шәһәр дөньяда юктыр... Әгәр кемдер бер генә мәртәбә булса да чакыру ала икән, бу гомерлеккә... Әлеге кече күңелле хуҗа сиңа гомер буе кунакчыллык күрсәтәчәк... Тормышта бәхетне тәмле итеп ашауда һәм бәйрәм итүләрдә күргәннәр өчен... һәм, ниһаять, бәхетле булу өчен шау-шулы рәхәтлекләргә ихтыяҗ сизгәннәр өчен Казан – чын Эльдорадо!».

Сезне, хөрмәтле укучыларыбыз, кунакка көтеп калабыз! Казанга рәхим итегез!

Сезнең кунакчыл редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **963 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 101 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 ҖӘҮҺӘРЕ

БАРЫ ТИК ТАТАРСТАНДА

ДҮРТ ТОННАЛЫ ТАТЛЫ СЫЙ

Чәкчәк – Татарстанга килгән туристларның барысы да диярлек күчтәнәч итеп алып китә торган татлы сый. Тәме – телеңне йотарлык! Моның шулай икәнлегенә җиһанның төрле кыйтгаларыннан Казанга футбол буенча дөнья чемпионатына җыелган меңләгән кеше берьюлы инана алды. FIFA җанатарлары фестиваленең ачылышына җыелган халыкка бушлай татлы ризык – чәкчәк тәкъдим иттеләр. Бөтен кешегә дә җитте ул: чәкчәкне бик зур – диаметры 2,6 метрлы футбол тубы формасында ясадылар! Җанатарлар әлеге кондитер сәнгате әсәрен бик рәхәтләнеп юк итәргә керешкәнче, жюри аның авырлыгын теркәде. Россия Гиннеслар китабында түбәндәге язу пәйда булды: «Дөньяда иң зур чәкчәк. Нәтиҗә: 4026,4 кг. Рекордчы: «Казан шәһәре Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» АҖ. Урыны: Казан ш., Татарстан Республикасы, 2018 елның 14 июне».

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр
ТӨП ТЕМА

6. Дөньяга дрон күзләре аша карау, яисә Акыллы шәһәрдә яшәү ничегрәк

12. Кетәклектәге ноу-хау «Цифр» йомырка салуны ничек арттыра

16. Елмаегыз, сезне күзәтәләр! Машинаны ничек тизрәк һәм куркынычсызрак йөртергә

26. Шамил Садыйковтан медиаторт, яисә «Татмедиа»ның көче нидә

32. Сабый-вундеркиндлар һәм озын гомерле интеллектуаллар Бүген нинди мәгълүмат чараларына ихтыяҗ бар

35. Игелек ресурслары Социаль газлаштыру кем өчен мөһим

38. Ак халатлы ясалма интеллект Ул диагноз куярга сәләтлеме

44. Сәламәтлек сагында Яңадан яшәргә өйрәнү

48. Китап хәзинәләре утравы Цифрлы технологияләр аңа ничек булыша

игелекле эшләр

66 Портомойнядан Ту-144кә кадәр Сентябрьдә сез карарга тиешле топ-15 урын

70. Гүзәл туташка бүләк ителгән сарай Кремль урамындагы йортта нинди серләр саклана

74. Төн, йолдызлар, «Кара пулат»... Легенда ничек җанлана

мәңгелек кыйммәтләр

84. Татар-мөселман «җәмгыять-шәһәре» Яушевлар эшчәнлеге

88. Казан ханлыгында ислам Толерантлык һәм дини татулыкның чишмә башы

92. Көнбатыш кырыслыгы һәм Көнчыгыш купшылыгы Сәүдәгәр Борнаев үзеннән соң нәрсәләр калдырган

94. Россия халыкларының мәдәни мирасы елы Татар йолалары

98. Татарстан авылларына сәяхәт Карашәм – яктылыкка таба

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: **protatarstan.ru**

Фото: «Татарстан» журналы архивыннан

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

19.08

Марат ХӨСНУЛЛИН, РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары, – Лаеш районында М-12 трассасын төзү мәсьәләләренә багышланган күчмә киңәшмәдә:

– Россиядәге төзелешләр тарихында без беркайчан да мондый дәрәҗәдәге трассаны ике ел ярым эчендә төземәдек. Беркайчан да. Ә менә бүген М-12 мисалында моны эшләргә сәләтле булуыбызны күрсәтәбез. Авыр, бер дә җиңел түгел, катлаулы бурыч. Ләкин без уңышлы эшли алуыбызны күрәбез. Дүрт участокта эш билгеләнгән вакытыннан алда бара, дүрт участокта исә графикка сыешабыз яки бераз арттарак барабыз. Әмма нигездә әлеге участокны – 2023 елда, ә 2024 елда Екатеринбургка кадәр бөтен юлны тәмамлау мөмкинлеген күздә тотабыз.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

15.08

Чулпан ИЛДАРХАНОВА, Татарстан Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге директоры:

– Былтыргы җанисәп нәтиҗәләре буенча Татарстан Идел буе федераль округында халык саны арткан бердәнбер төбәк булды. Артым 219 мең кеше тәшкил итә, халык саны, беренче чиратта, миграция хисабына күбәйгән. Аерым алганда, безгә Башкортостан һәм Удмуртиядән күченеп килүчеләр саны өч тапкырга арткан. Халык санының иң күп артуы Казанда, Биектау, Яшел Үзән, Лаеш, Питрәч, Тукай районнарында күзәтелә.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

20.08

Маргарита ЛЯНГЕ, Этникара журналистика гильдиясе президенты, – «Итил» Идел буе халыклары мәдәнияте фестивалендә:

– Безгә үз музыкабызны тыңларга вакыт. Илебездә 192 төрле халык яши. Бу – бик зур байлык, әйдәгез, аннан файдалана белик.

Фото: tatar-inform, nazaccent.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр

ТӨП ТЕМА

Бу санда тәкъдим итәбез:

Акыллы шәһәрдә **ничек** яшәргә

«Цифр» йомырка алуны **ничек** арттыра ала

Ак халатлы ясалма интеллект диагноз куярга **ничек** булыша

Бүген **кайсы** мәгълүмат чараларына ихтыяҗ бар

Ни өчен хәрефләр саннарны ярата

Нинди ИТ-карарлар матур парк һәм яр буйларын ясарга булыша



ГАЛИҖӘНАП «ЦИФР»

Фото: «Татарстан» журналы архивыннан, pngegg.com

2022 ел Татарстанда Цифрлы технологияләр елы дип игълан ителде. Бу гаҗәп түгел: зур тизлек белән үзгәрә барган дөньяда киң колачлы цифрлы трансформацияләр һәркемгә кагыла: икътисадның һәр тармагына, социаль өлкәдә күрсәтелә торган хезмәтләргә. Һәм, гомумән, алар безнең алга таба үсеш юнәлешен билгели.

Ләкин монда мөһим нәрсәне күздән ычкындырырга ярамый. Цифрлаштыру, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, – үзмаксат түгел, иң беренче чиратта, безнең гражданнарның тормыш сыйфатын ныгытырга, муллыгын тәэмин итәргә һәм керемнәрен арттырырга, шулай ук бизнесның көндәшлеккә сәләтлелеген көчәйтергә мөмкинлек бирә торган инструмент. Килешәсездер, моңардан да төгәлрәк әйтү мөмкин түгел. «Татарстан», үз нәүбәтендә, әлеге тезисны реаль фактлар белән ныгытырга алынды. Әлеге санда без тормышыбызны азрак кына булса да яхшыртырга, уңайлырак, җайлырак, ниһаять, сәламәтрәк итәргә сәләтле мәгълүмати технологияләр турында сөйләргә булдык.

АКЫЛЛЫ ШӘҺӘРНЕҢ ЙӨРӘГЕ

Олеся Бондаревская

Робот-официант, үз-үзен кора торган дрон, пилотсыз такси – Татарстан Иннополисы технологияләре белән шаккатыра. Әле алар белән генә дә түгел.

Кошлар сайрый, балалар чыр-чу килә – бирeдә иртәнге як ниндидер пансионатны хәтерләтә. Урамнар буш диярлек, бары тик бала арбасы тарткан әниләр генә йөри. «Киләчәк шәһәре» эшче сыйныфының зур өлеше – хәзерге вакытта технопарклар офисларында яисә өйдән торып эшләүче айтишниклар. Мин исә әлегә иннополислылар гына куллана ала торган цифрлы сервисларны сынап карарга ашыгам.

Иң беренче эшем – иртәнге аш ашау. Моны ничек эшләргә кирәклеген белү өчен мин Иннага мөрәҗәгать итәм. Инна – Иннополис шәһәренең телеграм-боты, ул шәһәр тормышы турында барысын да белә.

«Ашау» – дип язам Иннага. Һәм минем телефонда җәмәгать туклануы биналарының тулы бер исемлеге пәйда була. Аларның барысы да диярлек сәгать 10.00нан эшли башлый. Аның каравы 9:30да Яндекс.Еда аркылы заказ биреп була. Заказ бирәм дә һәм түземсезлек белән көтә башлыйм – ботканы гына түгел, аны китерүчене дә. Ярты сәгать чамасы вакыт узгач, яныма ровер – тәгәрмәчле ак тартма килеп туктый. Кафедан йортка кадәрге юлны бу роботлар мөстәкыйль һәм шактый тиз уза, бары подъездга гына керә алмый.

Фото: Олеся Бондаревская, Анастасия Хатыйпова

1
Технопарк янында торган велосипедларны күреп, чат-ботка «Велосипедлар» сүзен язам, һәм миңа шунда ук велосипедчылар төркеменә сылтама килә.

2
Кафедан йортка кадәрге юлны бу роботлар мөстәкыйль һәм шактый тиз уза, бары подъездга гына керә алмый.

ИННОПОЛИС ИННАСЫ

Иртәнге аштан соң Иннополисны яхшырак өйрәнергә вакыт җитә. «Истәлекле урыннар» дип язам Иннага, әмма ул мине Зөя утраушәһәренә (28 км) һәм «Свияжские холмы» курортына (4 км) юллый. Монда исә музейлар, мәчетләр, чиркәүләр дә юк. Шәһәр белән танышуны нәрсәдән башларга соң? Бу сорауга җавап итеп, Инна миңа InnoInLove танышу төркемен тәкъдим итә. Сүз уңаеннан, кирәкле мәгълүматны бирә алмаган очракта бот кулланучыны консьерж хезмәтенә күчерә, анда кешеләр эшли һәм ярдәмне алардан сорарга була. Минем танышыма, мәсәлән, монда эшләүче кызлар автобуста онытып калдырган кулчатырын табарга ярдәм итте. Бу хәл башкалада булса, берәр ПАТПның онытылып калган кулчатырны эзләүдә булышуын күз алдына китерүе дә авыр.

Иннаның танышу турындагы киңәшләренә колак салмыйча, шәһәр буйлап йөрергә чыгам. Иннополис урманнар белән әйләндереп алынган. Янәшәдә генә – Введение Бистәсе авылы, «Свияжские холмы» курорты һәм гөрләп торган М-7 трассасы, әмма зәвыклы архитектура, урамнарда роботлар йөрү, кешеләр һәм транспорт агымы булмау сәбәпле, үзеңне гадәти тормыштан бөтенләй аерылган итеп тоясың. «Берләшмәләр» дип язам Иннага. «Сине бөтенләй аңламыйм, мин моны белергә тиешмени?» дип җавап бирә миңа бот. Чынлыкта Иннополиста берләшмәләр бар, бары тик Иннага конкретрак язарга гына кирәк. Технопарк янында калдырылган велосипедларны күреп, чат-ботка «Велосипедлар» сүзен язам, һәм миңа шунда ук велосипедчылар төркеменә сылтама килә. Мин аңа кушылам

3

Пилотсыз таксилар – Иннополисның төп туристлык «могҗизаларыннан» берсе.

4

Инженер Марат Маннанов пилотсыз таксиларның хәрәкәт итүен күзәтә.

5

Машинаның хәрәкәтен махсус планшетта карап торам. Борт компьютеры юлдагы вазгыятьне күрсәтә.

һәм күптән түгел җирле велосипедчыларның Казанга «Велотөн»гә баруы турында беләм.

КАГЫЙДӘЛӘР БОЗМАУЧЫ ПИЛОТСЫЗ ТАКСИ

Сөйләшергә мөмкинлек туган иң беренче кеше – пилотсыз такси хәрәкәтен күзәтүче инженер Марат Маннанов. Ул алгы пассажир утыргычында утыра, руль артында беркем дә юк. Машина шактый шома хәрәкәтләнә. Марат әйтүенчә, бу таксилар Иннополисның төп туристлык «могҗизаларыннан» берсе. Кайчагында чиратлар да пәйда була икән. Монда яшәүчеләр өчен шәһәр буйлап пилотсыз машинада йөрү уңайлы булса да, гадәти күренеш. Машина сәгатенә 60 км дан да тизрәк йөрми, чөнки тизлекне арттыру – юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу, бу көйләүләрдә тыелган. Һәр җәяүле кичүе алдыннан машина, туктап, җәяүлеләрне дә, велосипедчыларны да, ашарга илтүче роботларны да уздырып җибәрә. Ул юл хәрәкәтендә катнашучының нәрсә эшләргә җыенуын алдан фаразларга да сәләтле, һәм бу – кеше йөрткән транспорт чарасы белән чагыштырганда пилотсыз машинаның төп өстенлекләреннән берсе.

– Бервакыт кичке эңгер-меңгердә уң полосада хәрәкәт иткән бер пилотсыз такси җәяүлеләр кичүе алдыннан кинәт туктап кала. Инженер хата турында аңлатма яза башлый. Тик такси бортындагы лидарлар (инфракызыл сенсорлар – ред. иск.) бер төркем велосипедчыларның якынлашуын сизеп алган була, ә сынаучы шофер караңгыда аларны күрми калган, – дип сөйли Марат. Пилотсыз таксида эшли башлагач, ул үзе дә машинасын игътибарлырак йөртә башлаган. Миңа машинаның алдан күрә белүе һәм ашыкмавы ошый, ләкин мин системаның ватылуы турында хәбәр көтәм, мәсәлән, ишекләр бикләнә, без бу тәгәрмәчле робот эчендә калабыз. Машинаның хәрәкәтен махсус планшетта күзәтәм. Борт компьютеры юлдагы вазгыятьне күрсәтә бара. Иннополис пилотсыз машиналарны сынау өчен иң яхшы урын. Кешеләрдән тыш, монда юлга еш кына куян һәм төлке йөгереп чыга. Кешеләр белән чагыштырганда, хайваннарның нәрсә эшләячәген фаразлау авыррак. Куян, мәсәлән, фара яктысында озак йөгерә ала. Боларның барысына карата пилотсыз машина дөрес гамәл кылырга тиеш. Шундый ук шоферларга карата да. Каршы як полосага чыгып, безне чит ил машинасы узып китә һәм параллель рәвештә бара башлый. Таксиебыз шунда ук тизлекне ташлый һәм машинага алга узарга мөмкинлек бирә. Пилотсыз таксилар Иннополиста 2018 елдан бирле йөри, әмма чит шәһәрләрдән килгән кунаклар әлегә кадәр үзеннән-үзе әйләнүче рульгә сәерсенеп карый. Сәяхәт барышында безгә дә берничә мәртәбә бармак төртеп күрсәттеләр.

6
Цифрлы мохит монда, газоннардагы үләндәй, үзеннән-үзе үсеп чыга кебек.

7
Экраны песи баласы башы рәвешендә ясалган робот-официант.

КЫЕНЛЫКЛАР УРЫНЫНА УҢАЙЛЫКЛАР

«Мин Иннополисны яратам, ләкин 60 яшьтән соң күбрәк яратыр идем. Туктап тын алу, тынычлану, тәнне-җанны-нервларны дәвалау өчен яхшы урын, ләкин син әле яшь булганда, күбрәк хәрәкәт һәм ыгы-зыгы булуын телисең», – дип яза миңа бер танышым бу цифрлы оҗмахта яшәгәндә нинди хисләр кичерәсең дигән соравыма. Иннополиста чыннан да ыгы-зыгы юк. Шәһәр кечкенә, юл һәм трафик өчен вакытны әрәм итмәү хисабына бер көн эчендә күп нәрсәгә өлгерергә мөмкин. Шуңа күрә агрессия дә мегаполисларга караганда азрак кебек тоела. Сүз уңаеннан, Иннодагы берәр җирдә сумкагызны онытып калдырасыз икән, ул сез кире килеп алганчы шунда ятачак, диләр. Монда бөтен җирдә камералар куелган, каракны эзләп табу кыен булмаячак.

Цифрлы мохит монда, газоннардагы үләндәй, үзеннән-үзе үсеп чыга кебек. Асылда, алай түгел – айти-технологияләр шәһәрдә махсус һәм планлы рәвештә үстерелә. Менә яңа мисал – Kuji ресторанында робот-официант. Мин ресторанга керәм һәм кофе белән пирожныйга заказ бирәм. Янымнан әлеге дә баягы робот-официант узып китә – экраны песи башы рәвешендә ясалган. Кассада эшләүче хезмәткәр егет өстәл сайлавымны һәм бераз гына көтеп торуымны үтенә. Һәм мин электрон песинең заказымны китереп бирүен көтеп утырам, ләкин аның урынына әлеге егет килә.

– Кемдер уйнап, программаны бозган, – дип гафу үтенә ул. Бу хәлгә минем кәефем кырылды. Ләкин барыбер ун минуттан соң песи минем яныма килде.

8
«Дронопорт» компаниясенең пилотсыз очу аппаратлары операторы Андрей Павлов.

9
Андрей лэптоп программасында команданы җыя, гараж түбәсе ачыла һәм дрон, выжылдап һәм аз гына чайкалып, урынынннан өскә күтәрелә.

10
Очышны һәм Иннополисның биеклектән ачылган гаҗәеп манзарасын без аның «күзләре» аша күзәтәбез – рәсемнәр ноутбук экранына тапшырыла.

8



9

ДРОН КҮЗЛӘРЕ АША КАРАУ

Ләкин робот-песиләргә ихтыяҗ юкка чыгар вакыт ерак түгел кебек. Иннополис кешеләре ризыкны өйгә генә түгел, өстәлгә үк китертә алачак. Дрон тәрәзәдән кереп, заказны нәкъ өстәл уртасына куячак.

– Хәзер тест стадиясендәге дроныбыз 2 килограммга якын йөкне күтәрә ала. Бу функцияне, мәсәлән, кечкенә посылкалар җибәрү өчен кулланырга мөмкин. Дрон заказны маркетплейс пунктында алачак һәм аны сезнең ишегалдына китерәчәк, – ди «Дронопорт» компаниясенең пилотсыз очу аппаратлары операторы Андрей Павлов.

Ул идарә иткән квадрокоптер станциясе – кечкенә гараж. Андрей лэптоп программасында команданы җыя, гараж түбәсе ачыла һәм дрон, выжылдап, аз гына чайкалып, урынынннан өскә күтәрелә. Бер минутка тукталып уйлап тора, ягъни программаны йөкли, аннары «Попов» технопаркы ягына юл тота. Очышны һәм Иннополисның биеклектән ачылган гаҗәеп манзарасын без аның «күзләре» аша күзәтәбез – рәсемнәр ноутбук экранына тапшырыла. «Дронопорт» эшләнмәләре каплау зонасының шактый зур (300 км^2 га кадәр), сурәтләрнең детальләшү дәрәҗәсе югары булуы белән аерылып тора. Хәзерге вакытта «Дронопорт» пилотсыз очкычлары Иннополис, Мәскәү, Дубайда барган төзелешләр өстеннән оча, эшне контрольдә тотарга ярдәм итә. Мәгълүмат йөкләнгән системага нейрочелтәр урнаштырылган, ул сурәтне анализлый ала, мәсәлән, объектта күпме эшче куркынычсызлык техникасын үтәмәгәнен хәбәр итә. Мондый дроннар юл трафигын күзәтү өчен дә, гадәттән тыш хәлне тиз арада бәяләү өчен дә һәм тагын бик күп урыннарда кулланылырга мөмкин.

Ул арада дрон урынына кайта һәм шунда ук батарейкалары корылганнарына алыштырыла. Автомат рәвештә! Бу дронны ел дәвамында 24/7 графигы белән эшләргә өйрәткән Gaskar Group компаниясе «Дронопорт»ының тагын бер яңалыгы.



10

11
«Иннополис шәһәрен үстерү фонды» АКБОның шәһәр проектлары бүлеге җитәкчесе Анастасия Козырицкая.

12
Фермерлар үзләре үстергән кәбестә, помидор, кара карлыган һәм башка продуктларны тәкъдим итә. Берничә киоскта попкорн, кукуруз һәм туңдырма да саталар.

ОЧРАШКАНГА КАДӘР!

«Безнең карар кабул итәр өчен зур күләмдәге мәгълүматны өйрәнергә кирәк булган өлкәләрдә машиналар белән көндәшлек итү мөмкинлегебез юк. Машиналар исә безнең белән принципиаль чишелешләр таләп ителгән өлкәләрдә көндәшлек итә алмый. Чынлыкта кеше генә мондый карарларны кабул итә, кечерәк масштабта булса да, көнгә меңәр тапкыр», – диде үзенең бер чыгышында машина укытуы белгечләре өчен Kaggle онлайн-платформасына нигез салган Энтони Голдблум.

Иннополиста процесслар белән идарә итүдә ясалма интеллекттан максималь рәвештә файдаланырга тиешләр кебек. Ләкин юк: бүгенге көндә төп җирле проектларның берсе – шәһәрнең Россиядә беренче цифрлы игезәге, кешеләр, бизнес һәм администрация өчен онлайн-мәйданчык, анда һәркем сөйли һәм үзен ишеттерә ала.

– Без шәһәр администрациясе алдында торган бурычларны оптимальләштерергә, мэриянең халык, берләшмәләр, идарәче компанияләр, подрядчылар, социаль учреждениеләр белән диалогын җайга салырга телибез. Идея гади: һәр кешенең шәхси кабинеты бар, анда ул, беренчедән, шәһәрнең барлык объектлары турында (машина кую урыннары һәм яшел үсентеләрне дә кертеп) тулырак мәгълүмат белә ала, икенчедән, кушымталарда яки «Дәүләт хезмәтләре күрсәтү» системасында булмаган шәһәр сервисларыннан файдалана, өченчедән, проблема турында хәбәр итә яки үз идеясен җиткерә ала. Мондый хезмәтләр Россиянең күп кенә шәһәрләрендә бар, тик кагыйдә буларак, алар аерым-аерым сервислар. Без шәһәрнең кечкенәлеге һәм Иннополис Университеты кебек ресурсның булуы нәтиҗәсендә бердәм система булдыра алдык, – ди «Иннополис шәһәрен үстерү фонды» автоном коммерциячел булмаган оешмасының шәһәр проектлары бүлеге җитәкчесе Анастасия Козырицкая.

Хәзер платформа аша фатир яки машина кую урынын арендаларга, велосипед саклау урынына бронь ясарга, урын өчен түләргә мөмкин. «Проблемалар» бүлегендә кемдер сынган каен турында хәбәр итә. «Тәкъдимнәр» бүлегендә икенче берәү шәһәр үзәгендәге бушлыкны паркка әйләндерү яхшы булыр иде, дип яза. Киләчәктә әлеге платформалар администрациягә тиз һәм төгәл карарлар кабул итәргә, халыкка – үз шәһәрләрен үстерүдә, бизнеска кирәкле һәм нәтиҗәле проектларны тормышка ашыруда актив катнашырга ярдәм итәчәк. Болар барысы да үзара аңлашып яшәүгә китерәчәк. Бу социум гармониясенең нигезе түгелме?

P.S.

Цифрлы игезәк булдыру идеясе башка шәһәрләргә дә таратылачак. Ләкин бу зур өметләр уята торган проект белән танышканнан соң да мин Иннополис буйлап сәяхәтемне дәвам итәм, чөнки нидер җитми кебек тоела. Һәм кинәт Квант бульварының бер башында кечкенә генә базарга тап булам. Чып-чын базар. Якын-тирәдәге авыллардан килгән фермерлар үзләре үстергән кәбестә, помидор, кара карлыган һәм башка продуктларны тәкъдим итә. Берничә киоскта попкорн, кукуруз һәм туңдырма да саталар. Кайберәүләрнең әйберләр сатып алуларына да карамастан, таралырга ашыкмауларын күрәм: кешеләр аралаша – сатучылар белән, бер-берсе белән. Миңа тынгы бирмәгән теге хис юкка чыга. Хәзер мин Иннополисның акыллы булуы белән бергә, кешелекле шәһәр икәнлегенә дә төшенәм.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНДА РОБОТЛЫ ТОРМЫШ

Ксения Сёмина

Татарстанның агросәнәгать комплексы цифрлы технологияләр өчен чирәм җиргә тиң. Ләкин анда беренче шытымнар инде күренеп килә.

Зур кетәклекнең ике ягында да симез чуар тавыклар ябылган читлек рәтләре тезелеп киткән. Алар түшәм астына кереп, күзләрен ялтыратып, зәңгәр лампаны алыштыручы хезмәткәрне күзәтә. Аның смартфонына берничә минут элек кош психикасы өчен файдалы зәңгәр лампаның янып чыкканлыгы турында хәбәр килгән. Эшен тәмамлагач, хезмәткәр кушымтада «башкарылды» дигән тамга куя. Хәзер вентиляция системасын тикшерергә кирәк – кушымта мәгълүматлары күрсәткәнчә, бер кетәклектәге һавада аммиак микъдары арткан.

Предприятие хезмәткәрләре микроклимат, җайланма, азык, су һәм процессның башка күрсәткечләре турында мәгълүмат туплана торган бердәм системага тоташтырылган. Нейрочелтәр йомыркаларны саный (99,8% төгәллек белән, ягъни кешегә караганда төгәлрәк), азык күләмен арттыру яки киметү кирәклеге турында хәбәр итә. Болар барысы да предприятиегә азыкта гына да елына йөз меңнәрчә сум акчаны янга калдырырга мөмкинлек бирә. Моннан тыш, җитештерүдәге проблемаларны тиз арада хәл итү тәүлеклек артымны күбәйтергә һәм үлем-китемне азайтырга ярдәм итә.

ТАВЫКЛАР ҺӘРЧАК ЭЛЕМТӘДӘ

Мондый системалар Татарстанның иң эре кошчылык предприятиеләрендә, шул исәптән «Пестречинка»да инде берничә ел эшли. Әлеге системаларны урнаштыру һәм карап тору белән республиканың CloudD компаниясе шөгыльләнә.

– Без җитештерүдә катгый контроль таләп ителә торган теләсә кайсы юнәлеш белән эшлибез, бер-берсеннән дистәләгән чакрым ераклыкта урнашкан объектларны уртак челтәргә берләштерәбез. Ягъни сез бер үк кушымтада Мари Элдагы комплексыгыздагы хәлне дә, Чувашстандагысын да күрә аласыз, – ди CloudD ширкәтенә нигез салучы Руслан Кахаберидзе. – Безгә тармакның үзенчәлекләрен аңлау өчен берничә ел кирәк булды, ләкин, гомумән алганда, теләсә нинди ферма – мәгълүматлар җыелмасы ул. Урып-җыю техникасы саны, җыеп алынган бодай күләме, ашламаларга чыгымнар, терлекләрнең баш саны арту яки үлем-китеме – барысы да мәгълүмат. Ә ул сезнең карамактагы бер мобиль кушымтада җыелганда, карар кабул итү тизлеге бик нык арта.

Әлеге плюслардан тыш, авыл хуҗалыгы предприятиеләренең цифрлы юлга аяк басуы тармакка кадрларны да җәлеп итә, дип саный Кахаберидзе.

– Бүгенге яшьләр планшет тотып туган, диләр. Мәгълүматлар белән эшләү аларга аңлаешлы да, кызыклы да. Әнә шуның өчен егетләр предприятиегә килә һәм, процесс белән кызыксынып, эшкә кала, – ди Руслан Кахаберидзе. – Өлкән буын вәкилләреннән кайвакытта машиналар кешене эшсез калдыра кебек шикләр ишетәм. Калдырмаячак. Илдә һәм республикада аграр потенциал бик зур, эш бөтен кешегә дә җитә. Импортны алыштыру тенденцияләрен исәпкә алып, бу эшкә тизрәк тотынырга кирәк.

Компьютер программалары язучыларга да, фермерларга да консультатив ярдәм күрсәтү республика предприятиеләрендә автоматлаштыру процессларын тизләтү эшенә булышыр иде, дип саный Руслан Кахаберидзе.

– РФ Хөкүмәтенең 550 нче карары нигезендә, аграрийлар җитештерүне цифрлаштыру максатында субсидияләр алырга хокуклы. Ләкин моның өчен проектның ныкларга кирәк. Проектны язу гына да зур процесс – аны фермерлар үзләре генә эшли алмаячак. Без әлеге проектлау вазыйфасын үз өстебезгә ала алабыз, ләкин

Фото: tatar-inform.ru

бу мәсьәләдә сорауларыбыз бар, алар белән хәзергә беркемгә дә мөрәҗәгать итеп булмый. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы Республика мәгълүмат-исәпләү үзәге (РМИҮ) дә субсидияләр алырга ярдәм итә, әмма терлекчелек тармагына бәйле эзер проектларыбыз үтми – программа мөгезле эре терлеккә генә кагыла, – дип аңлата Руслан Кахаберидзе. – Бездә, мәсәлән, Эшкуарлыкка ярдәм итү фонды бар, ул кече һәм урта бизнеска булышлык күрсәтә, шул исәптән консультацияләр уздыра, федераль программалар буенча барлык сорауларга да бик тиз җавап бирә. Авыл хуҗалыгын цифрлаштыруда катнаша торган предприятиеләр өчен дә ник әле шундый ук структура булдырмаска?

ФЕРМЕР ЛАТЫЙПОВЛАР

РМИҮ мәгълүматларына караганда, сораштыруда катнашкан 290 Татарстан авыл хуҗалыгы җитештерүчесенең 90 га якыны исәп-хисап эшләрен 1С системасында алып бармый һәм предприятие белән идарә итү системасын кулланмый. 180 хуҗалык 1С программаларын куллана, ләкин процесслар белән идарә итү өчен бер генә аккаунтлары бар. Үзәк белгечләре билгеләп үткәнчә, Татарстанда аграр предприятиеләрне автоматлаштыру дәрәҗәсе түбән. Бу юнәлештәге төп каршылыклар исемлегендә – системаларның кыйммәтлеге һәм цифрлаштыруның өстенлекләре ачык күренмәү. Ләкин цифрлы эшчәнлек процессына инде берничә ел элек үк керешкән алдынгы хуҗалыклар да бар. Өстәвенә, алар арасында бу тармакның гигантлары дип саналмаган предприятиеләр дә очрый.

ТРның Биектау районындагы Латыйповлар фермасында 130 савым сыеры бар, аларны Lely роботы сава, ашата-эчертә. Сөтбикәләр аппарат белән саву урынына үзләре керә. Система шунда ук сөтнең составын һәм сыйфатын анализлый, стандартларга туры килмәгән сөтне аера, ачыкланган теге яки бу тайпылыш турында хуҗаларга хәбәр итә. Lely сыерларның авырлыгын, физиологик халәтен һәм хәтта күшәвен дә күзәтә. Хуҗалар иртә белән фермага сөт тапшырырга һәм робот әзерләгән идарә отчетын карарга гына килә.

– Без берничә ел чит илләргә йөрдек, Голландиядә, Германиядә булдык, төрле робот модельләрен карадык. Lely дигәнен сайладык. Әмма ул бик кыйммәткә төште, берничә дистә миллион сум тора иде. Ул чакта, 2019 елда, РФ Авыл хуҗалыгы министрлыгы яхшы грантлар бирә иде, һәм без өченче омтылыштан мондый грантны алуга ирештек. Әнә шулай итеп без бу комплексны сатып ала алдык. Хакын чыгарыр өчен, тагын 10 ел эшләргә кирәк әле. Тик аны сатып алганга бер дә үкенмәдек, – ди Минсинә Латыйпова.

Йокы дигән нәрсәне дә, ял итүне дә белмичә, гел элемтәдә торган робот чиста станок белән генә сава, җиленгә юылмаган куллар кагылмый, бу исә хуҗалыкта яраксызга чыгарыла торган мал санын мөмкин кадәр киметә – өч ел эчендә өч кенә сыер көтүдән алына. Фермерлар сөтне Татарстан предприятиеләренә тапшыра. Шунысы гаҗәп: сыйфаты буенча ул хәтта тиешледән дә югарырак. Товар җитештерүчеләр мондый продукция сатып алуга өстенлек бирсәләр, ничек шәп булыр иде! Бу исә Латыйповларга Lely роботының хакын тизрәк чыгарырга һәм цифрлаштыруның чираттагы югарылыгына күтәрелергә булышыр иде, күңелләре белән алар моңа күптән әзер инде. Мондый тәвәккәл аграрийларның саны бөтен төбәк авыл хуҗалыгы тармагын цифрлы трансформацияләү өчен кирәкле дәрәҗәгә җитсен өчен, РМИҮ фермерларга берничә төрле мәгълүмати сервис сатып алуда ярдәм итүдән тыш, җитештерүчеләрне цифрлы эш режимына өйрәтә торган белем бирү программаларын да тормышка ашыра.

КВАЛИФИКАЦИЯ КҮТӘРҮ

– Терлекчелектә дә, үсемлекчелектә дә, әинде механикалаштыру һәм транспортта бигрәк тә, бизнесның нәтиҗәлелеген күтәрү, чыгымнарны киметү, эзер продукция күләмен арттыру өчен күп мөмкинлекләр бар. Минем укучыларым – авыл хуҗалыгы тармагында хезмәт куючылар моны анык мисаллар белән раслый. Әгәр без цифрлы трансформацияне масштаблы процесс буларак күзаллыйбыз икән, сүз технология турында гына бармый, беренче чиратта ул – идарә итү культурасы турында да, – ди Мәскәү белгече, РМИҮнең белем бирү программалары тренеры Михаил Ясаков. – Шуңа күрә беренче һәм хәтта нуленче адым квалификацияне күтәрүдән гыйбарәт. Чөнки нәкъ менә шул кешеләр инновацияләр кертәчәк һәм цифрлы трансформацияне гамәлгә ашырачак, шул кешеләр үз эшләрендә яңа цифрлы ысуллар һәм технологияләр кулланачак. Шунлыктан, иң беренче чиратта, алар үзләренең гадәти, иялэнгән карашларын һәм культураларын заманча цифрлыга үзгәртергә тиеш. Безнең квалификацияне күтәрү программаларында (без инде ике зур төркемне укыттык) бу сорауларга 80% тан артык вакыт бирелә, чөнки болар – иң мөһиме һәм кирәклесе.

Әлеге программа буенча белем алучылар финанслау белән бәйле кыенлыкны һәм агросәнәгать комплексының сезонлы үзенчәлекләрен цифрлаштыруның төп киртәләре дип атый. Икенче урында – соңгы кулланучылар белән элемтә булмау. Автоматлаштырылган предприятиене кулланачак затларның ни теләгәнен белмичә торып, карар кабул итү шактый кыен.

– Татарстан аграрийлары цифрлаштыру мәсьәләләрендә алга киткән, әмма камиллеккә чик юк, – ди Михаил Ясаков. – Цифрлы технологияләр – киләчәк дигән сүз, агросәнәгать комплексы, динамиканы саклаган хәлдә, алга таба да бу юнәлешне үстерергә тиеш.

ФЕРМАДАГЫ «ЦИФРЛАР», РЕКОРДЛЫ САВЫМНАР ҺӘМ СЫЕРЛАР ӨЧЕН УЗИ ТУРЫНДА

«Татарстан» журналы сорауларына «Вамин» компаниясе генераль директоры Минтимер Минһаҗев җавап бирә

– Авыл хуҗалыгын цифрлаштыру – тармакны яңа дәрәҗәгә күтәрү өчен кирәкле төп бурычлардан берсе. Инде бүген үк әлеге бурычны уңышлы хәл иткән хуҗалыклар арасында ТР авыл хуҗалыгы министры Марат Җәббаров «Вамин» КТ кергән Гаврилов исемендәге агрофирманы атады. Агрофирма эшчәнлеге нәтиҗәләре чыннан да мактанырлыкмы?

– Гаврилов исемендәге агрофирма – 600 баш мөгезле эре терлекне караучы 25 хезмәткәр ул. Малларның күбрәк өлеше – 525 башы – сыерлар. Тәүлеклек тулаем савым 14 121 килограммга тәңгәл. Димәк, биредә бер сыердан уртача 31,3 литр сыйфатлы сөт савып алалар. Килешәсездер, нәтиҗә бик яхшы. Белүегезчә, Татарстанда сөт һәм ит терлекчелеге өстенлекле юнәлеш санала, ә без-

Фотолар: «Вамин» компаниясе, tatar-inform.ru. РЕКЛАМА

нең сыр һәм май җитештерә торган сөт эшкәртү заводларыбыз сыйфатлы сөтне кулланучылар булып тора. Максат – заводларны тулысынча үз сөтебез белән тәэмин итү. Гаврилов исемендәге агрофирманың моны гамәлгә кертүдәге өлеше бик мөһим. Без ябык цикл предприятиесе булып торабыз, сыр ясарга яраклы сыйфатлы сөт сыр кайнатучылар өчен иң мөһим мәсьәлә санала. Хәзерге шартларда заманча технологияләрдән һәм структураны цифрлаштырудан башка моңа ирешеп булмый.

– Мәгълүм булганча, «Вамин» предприятиеләре сөтне бүген берике агрофирма гына биргәннән күпкә артыграк эшкәртә. Моны ничек хәл итәргә?

– Быел без «Северный» авыл хуҗалыгы предприятиесендә 5960 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән яңа комплекс төзи башладык, ул хәзерге заманның бөтен таләпләренә җавап бирәчәк. Төзелеш этаплап барачак. Җитештерүне эшләтеп җибәрү 2027 елга планлаштырыла. Параллель рәвештә без гамәлдәге «Северный» АХП яңартабыз. Хәзер биредә 152 кеше эшли, уртача хезмәт хакы 30 мең сум чамасы. Предприятиедә автотехника паркы яңартылды, терлекчелекне цифрлаштыру системасы кертелде. Үрчемне яхшырту өчен терлекне идентификацияләүнең бердәм системасын кертә, сыйфатлы һәм балансланган рацион әзерләү өчен азык үзәкләре ача башладык. Электрон исәпкә кую системасы кеше факторыннан котылу, тулы рационлы оптималь тукландыру һәм үрчемне контрольдә тоту мөмкинлеген бирә. Нәтиҗәдә, мәсәлән, азык чыгымы якынча 15 процентка кимеде. 882 сыердан хәзер тәүлек саен уртача 23 тонна сөт алалар.

– Ә инде цифрлаштырылган участокларда җитештерү процесслары ничек бара?

– Биредә барысы да кешеләрдәге кебек: башта сыерларны дөрес тукландырырга кирәк.

DTM программасын файдаланабыз, ул, төрле азыкны кушып, балансланган рацион әзерләү мөмкинлеген бирә – сыйфат исә лабораториядә атна саен тикшерелеп тора. «Кухняда» меню катгый рецептура буенча әзерләнә: бозаулар өчен – бер төрле, савым сыерларына – икенче, үгезләргә өченче төрле азык бирелә. Азык 12 төрле компоненттан тора: кукуруз силосы; люцерна сенажы; бөртеклеләр – арпа, бодай; печән; салам; кукуруз; соя һәм рапс шроты; коры барда; патока; моннан тыш витамин һәм микро-элементлар – акбур, тоз, аш содасы, баетылган өстәмә-премикслар.

– Сөтлебикәләр өчен меню еш үзгәрәме соң?

– Рецепт ярты елга әзерләнә, тик һава торышына карап яки сыерлар чирләгән очракта аңа төзәтмәләр кертелергә мөмкин – ул чакта азыкка ветеринария препаратлары өстәлә. Шулай ук рецептура азыкны тикшерү нәтиҗәләренә карап та үзгәрә. Үгезләрнең – үз рационы, ул авырлыкны оптималь җыю өчен тәгаенләнгән: нигездә кукуруз силосы һәм комбиазыктан тора. Сыерларны исә, киресенчә, артык симертергә кирәкми: бер баш терлеккә 20-25 кг кукуруз силосы, 8-10 кг сенаж, 10 кг чамасы комбиазык һәм микроөстәмәләр бирелә. Савым сыерын ашату фронты бер башка – 65 см, эчертү фронты – 10 см.

– Ә саву процессы ничек оештырылган?

– Туйганчы ашагач, хайваннар саву залына керә. Һәр сыер тапшыргычисәпләгеч аша үтә, ул персональ чиптан мәгълүматны алып, аны системага кертә. Саву «Параллель 2х25» тибындагы савым залында башкарыла. Көненә өч тапкыр, төгәл 8 сәгать интервал белән. Беренче саву иртәнге 5 тә, аннары көндезге 1 дә һәм кичке 9 да. Саву тулысынча автоматлаштырылган, күрсәткечләр шундук компьютерга тапшырыла. Таблицалар автомат рәвештә тутырыла. Компьютерда һәр хайванга досье бар: бозаулау, аталандыру даталары, лактация, чирләгән очракта шуның турында мәгълүмат.

Хайваннар бәйдә түгел. Һәр секциядә 100–120 баш терлек. Бөтен эш катгый техкарталар буенча башкарыла, зыян салырга сәләтле бернинди импровизация дә булырга тиеш түгел.

– Нәрсәдер пландагыча килеп чыкмаган чаклар буламы?

– Кабатлап әйтәм, фермада эшнең төп принцибы – технологик картаны үз вакытында үтәү. Күрсәтмәләр никадәр төгәлрәк үтәлсә, шулкадәр яхшырак. Фермада атналык эш тәртибе бар. Дүшәмбе – УЗИ, кысыр сыерларны ачыклыйбыз. Сишәмбе – буаз сыерларны тикшерү. Чәршәмбе – вакцинация. Пәнҗешәмбе – ясалма аталандыру. Җомга – хайваннарны төркемнәргә тарату.

Көн саен үтәлә торган мәҗбүри эшләр дә бар. Комплекс видеокүзәтү белән җиһазландырылган – планнан тыш хәлләрдә оператив реакция бик мөһим.

Безнең яңа үрләр яулыйсы бар. Яңа комплекс төзү һәм хәзергесен камилләштерү буенча алда күп эш көтә.

Минем командама озак вакытлы максатлар куелган. Барысына да ирешербез, дип ышанам. Т



ӨСТЕНЛЕК – ЯСАЛМА ИНТЕЛЛЕКТКА

Ксения Сёмина

«Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, Цифрлы үсешкә ярдәм итү ассоциациясе советы рәисе һәм Kazan Digital Week халыкара форумының идеологы Рифкать Миңнеханов «Татарстан»га фотовидеотеркәүнең ни өчен кирәклеге, юлның цифрлы игезәге нинди булуы һәм ник пилотсыз автомобильләргә күчү заман таләбе икәнлеге турында сөйләде.

— Татарстанда фотовидеотеркәү комплекслары 2008 елдан бирле эшли. Бу вакыт эчендә юлдагы вазгыять ничек үзгәрде?

– Фотовидеотеркәү комплекслары – юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны һәм юл хәрәкәтен оештыруны контрольдә тотуның универсаль чарасы. Тизлекне арттыру очракларын теркәү башлагач, полосалар буйлап хәрәкәт итү һәм автомобильләрнең маневр ясау тәртибе яхшырды, светофорның кызыл утына йөрүләр азайды. Юлдагы бөкеләрнең кимүеннән гыйбарәт икенче һәм шактый күзгә күренеп торган нәтиҗәне трафик белән адаптив идарә итү (Мәгълүмати-транспорт системасының (МТС) подсистемасы) бирде. Тоташ йөрешле юл чатларында, магистраль һәм торак йортларга алып бара торган юлларда хәрәкәт җайланды. Автомобиль йөртүчеләр юл чатларындагы вазгыятьне күзаллау мөмкинлеге алгач, аңлы рәвештә тизлек режимын саклый. Скептикларның фаразларына карамастан, юл бөкеләре кимеде, шәһәр экологиясе яхшыра төште. Моның ачык нәтиҗәсе – Казанда хәтта иң тыгыз сәгатьтә дә коллапс тумый, бөкеләрдәге автомобильләр, акрын гына булса да, барыбер бара.

– 2012 елдан Татарстанда юл хәрәкәте белән идарә итүнең адаптив автоматлаштырылган системасы (АСУДД) эшли. Аның нәтиҗәләре нинди?

– Хәзер аның составында Казанның төп магистральләрендә – 184, Чаллыда 11 адаптив светофор эшли. МТС үстерүне күздә тоткан җирле проектны ахыргача тормышка ашырганда, Казанда адаптив светофорлар саны 40% тан артык, ә Чаллыда 20% (240 светофор, ягъни 50% ы) булачак. Автоматлаштыру юлларның үткәрү сәләтен – 15-20% ка, светофорлар арасында уртача тизлекне 15-20% ка арттырырга һәм һавада зарарлы матдәләр концентрациясен 20-25% ка киметергә мөмкинлек тудырды.

– Фотовидеотеркәү юл-транспорт һәлакәтләрен булдырмый калуда ничек ярдәм итә?

– Дөнья тәҗрибәсе шуны күрсәтә: профилактиканың иң нәтиҗәле чарасы – җәзадан котылып кала алмау. Хәзер Татарстанда 856 фотовидеотеркәү комплексы эшли, шуларның 166 сы – күчмә, 22 се – мобиль комплекс. 2008 елда беренче системалар кертелгәннән алып, 2021 елның декабренә кадәр юл-транспорт һәлакәтләрендә үлүчеләр саны 653 тән 312 кешегә кадәр кимегән.

– Цифрлы технологияләр юлларны куркынычсызрак итәргә булышамы?

– Быелтыр без юллардагы иң куркыныч участокларны ачыклауның цифрлы моделен эшләдек. Иң проблемалы урыннар – кимендә биш авария һәм өч төрле ЮТҺ теркәлгәннәре. Модель андый урыннарда өстәмә камера һәм датчиклар кую карарын кабул иткәндә булышачак. Трассаларда автомобиль хәрәкәте шактый көчле булганлыктан, һава торышының үзгәрүенә тиз игътибар бирү мөһим. Шуңа күрә Татарстан территориясендә 15 үзгәрүчән мәгълүмат таблосы, гамәлдәге 28 метеостанциясенә өстәп, тагын 15 юл метеостанциясе, шулай ук хәрәкәт интенсивлыгын контрольдә тота торган 18 датчик урнаштырылды. Мәгълүматлар «Автодория» тарафыннан эшләнгән «Цифрлы юл игезәге» подсистемасы белән эшкәртелә. Әлеге система машина йөртүчеләргә реаль вакыт режимында һава торышы шартлары турында хәбәр итә. Моннан тыш, республикада юл техникасын мониторинглау системасы эшли, ул юлларга реагентлар сибү яки куркыныч

Фото: tatar-inform.ru

кар көртләрен чистарту өчен бригадаларны оператив рәвештә җибәрергә булыша.

– Юл хәрәкәте белән идарә итүне цифрлаштыру алга таба нинди юнәлештә үсәчәк?

– Республика «Транспорт системасын үстерү» РФ дәүләт программасының «Юл хуҗалыгын үстерүнең гомумсистемалы чаралары» федераль проектында катнаша. Проектның бер этабы Транспорт системасы белән идарә итүнең бердәм платформасын (ЕПУТС) булдырудан гыйбарәт. Төбәкләрдәге ЕПУТС МТС белән идарә итүнең федераль платформасында бер сегмент булып тора. Платформага АСУДД подсистемалары, фотовидеотеркәү, транспорт агымнары мониторингы, гадәттән тыш хәлләрне видеокүзәтү һәм демодуляцияләү, метеокүзәтү, юлларны карап тоту хезмәте идарәсен диспетчерлаштыру, парковка белән идарә итү системалары керә.

– ЕПУТСны тулысынча кулланышка кертү кулланучылар өчен ни бирәчәк?

– Министрлык һәм ведомстволар берләштерелгән мәгълүмат алачак, ә бу исә иң нәтиҗәле карарлар кабул итүгә юл ачачак. Гади гражданнар һәм автомобиль хуҗалары өчен платформаның подсистемалары, төгәлрәге, алар күрсәткән хезмәтләр бик зур роль уйный. Без юлда вакытны янга калдыра торган адаптив светофорлар турында искә алдык инде. Башкалары да бар. Мәсәлән, авария-коткару хезмәтләре өстенлеген тәэмин итү модуле «Ашыгыч ярдәм» һәм янгын сүндерү машиналарына светофорның кызыл сигналына туктаулар санын киметергә мөмкинлек бирә. Ул шулай ук җәмәгать транспортының юл чатларында туктап тору вакытын 40% ка кыскарта һәм юлларда гомуми хәрәкәтне 37% ка тизәйтә ала. Авырлык һәм габарит контроле подсистемасы аша, Татарстан юлларыннан авыр яки зур габаритлы йөк ташыганда, тиешле рөхсәтне алырга һәм транспорт хәрәкәтенең маршрутын билгеләргә мөмкин һ.б.лар.

– Юлның цифрлы игезәге – пилотсыз транспорт, транспорт агымнары белән идарә итү кебек проектларда һәм башкаларда көн үзәгендә. Ни өчен ул нәкъ менә Татарстан өчен мөһим?

– Киләчәктә Татарстанда транспорт схемаларын планлаштыру цифрлы игезәк мәгълүматларына нигезләнеп алып барылачак икәнен генә дә телгә алу җитә. Бу мәгълүматларны җыю өчен, без LADA Largus автомобиленә көйләнгән юл лабораториясен сатып алдык. Ул, республика юлларында йөреп, һәр урынны панорамалы дүрт камера белән төшереп барырга тиеш. Оператор реаль вакыт режимында мәгълүматка берәр нәрсә язып куя ала. Үткән юлның язмасы саклана һәм соңрак цифрлы игезәккә әверелә. Мондый лаборатория башка төрле мәгълүматлар да туплый ала, мәсәлән, машина көпчәгенең юлда шуу дәрәҗәсе, юл катламының ныклыгы турында. Бу – диагностика, паспорт ясау һәм юл белән бәйле башка мәсьәләләрне чишү өчен кулланыла торган кыйммәтле мәгълүмат.

– АСУДД эше турында сөйләгәндә, сез экологик нәтиҗәлелек турында әйтеп үттегез. Аңа электрга көйләнгән транспортны үстереп тә ирешеп була. Әлеге юнәлештә эш уңышлы барамы, нәтиҗәләр ниндирәк?

– Бу – шулай ук югары технологияле мөһим проектларның берсе. Татарстанда хәзер 304 электрга көйләнгән автомобиль һәм 58 электр корылмасы бирү станциясе теркәлгән. Сүз уңаеннан, андый станцияләрне җитештерү белән Татарстанның ике предприятиесе шөгыльләнә. Бу елның җәендә ТР Министрлар Кабинеты 2022-2024 елларга республикада электр корылмасы бирү инфраструктурасын үстерү турында дәүләт программасын раслады. Максат итеп куелган саннарның берсе – 2024 елга Татарстанда 174 корылма бирү станциясен урнаштыру. Программа шулай ук электрга көйләнгән автомобиль хуҗаларына транспорт салымы түләүдә ташлама бирүне тәкъдим итә. «Электрга көйләнгән автомобиль һәм водородка көйләнгән автомобиль» федераль проекты буенча, пилот төбәкләрнең берсе булган Татарстан территориясендә, җитештерүчеләргә чыгымнарның бер өлешен федераль бюджеттан кайтару шарты белән, 95 шундый станция урнаштыру каралган. Алар Казанда, Чаллыда, Әлмәттә, Түбән Камада, Яшел Үзәндә, Иннополиста һәм республика магистральләрендә барлыкка килергә тиеш.

– Киләчәк проектларының кайсын республика өчен иң перспективалы дип саныйсыз?

– Өстенлекле дип әйтү дөресрәк булыр. Уйлавымча, ясалма интеллект кертү белән бәйле проектлар ул. Киләчәктә автомобиль белән идарә итү тулысынча компьютер контроленә күчәчәк бит, кешенең катнашы мөмкин кадәр аз дәрәҗәдә булачак яки бөтенләй бетереләчәк. Кеше факторы катнашмаганда, хәрәкәт куркынычсызрак булачак, транспортны куллану нәтиҗәлелеге артачак, йөк ташуга чыгымнар кимиячәк, шәхси транспортка ихтыяҗ да, экологиягә йогынты да азаячак. Татарстан хәзер берничә «пилотсыз» хәрәкәт проектын тормышка ашыра. «Алабуга» МИЗ Россия юл ФТИ белән берлектә югары автоматлаштырылган һәм пилотсыз транспорт чараларын сынау зоналарын булдыру белән шөгыльләнә. 2018 елдан башлап Иннополис территориясендә «Яндекс»ның пилотсыз таксие йөри. Иннополис университеты һавада һәм җир өсте транспортында пилотсыз идарә итү белән бәйле технологияләр эшләү һәм камилләштерүне дәвам итә. КАМАЗ якын арада сәгатенә 60 км га кадәр тизлектә гади маневрларны башкарырга сәләтле пилотсыз йөк машиналарын серияле җитештерүне җайга салырга планлаштыра. «Казан-Телематика» компаниясе пилотсыз электр платформалар куллануны күздә тоткан автоном коммерция транспорты системасын эшли. Кырларда пилотсыз «АгроБот» тракторлары хезмәт куя, алар кешене тулысынча алыштыра ала. Бу проектларның арта гына барачагына шикләнмим.

ТАТМЕДИА САННАРДА:

2007 елның **1** октябре

ТРның беренче Президенты Минтимер Шәймиев указы белән «ТАТМЕДИА» АҖ оештырыла. Бүген ул Татарстан Республикасында иң эре медиакомпания.

67 филиал

«ТАТМЕДИА» АҖ составына керә.

1685 кеше –

«ТАТМЕДИА» АҖндә эшли.

Акционерлык җәмгыятенең медиаресурсларына керә:

98 район, шәһәр һәм республика газетасы,

17 журнал,

19 телеканал,

14 радиоканал,

79 сайт,

1 «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы,

социаль челтәрләрдәге **350** профиль,

1 «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.

«ТАТМЕДИА» АҖ газеталары татар, рус, чуваш һәм удмурт телләрендә басыла.

газеталар

- **42** рус телендә
- **50** татар телендә
- **5** чуваш телендә
- **1** удмурт телендә

журналлар

- **1** рус телендә («Казань»),
- **10** татар телендә,
- **3** («Татарстан», «Чаян», «Идел»,) рус һәм татар телләрендә.

246 593 данә – 2022 елның II яртыеллыгында «ТАТМЕДИА» АҖ газеталарының җыелма тиражы.

Татарстанның **2** дәүләт телендә республикада телерадиотапшырулар алып барыла.

79 сайт

«ТАТМЕДИА» АҖнең шәһәр, район, республика интернет-ММЧның шулкадәр сайты бар. Монда «Татар-информ» эре мәгълүмат агентлыгы да керә.

74 360 537 уникаль караучы – 2021 елда «ТАТМЕДИА» АҖнең барлык ММЧ сайтларының суммар караучылар саны.

3 700000 млн нан артык кеше– «ТАТМЕДИА» АҖ филиалларының социаль челтәрләренә язылган кешеләрнең гомуми саны (2022 елның 1 маена).

26 600 кеше «Татмедиа» телеграм-каналына язылган. Бу холдингның иң зур телеграм-каналы. Электрон ресурс 2019 елның августында оештырыла. Холдингның телеграм-каналларына барлыгы 105 меңнән артык кеше язылган.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиевнең 2007 елның 23 августындагы УП-453 номерлы Указына ярашлы рәвештә оеша һәм 2007 елның 1 октябрендә ФСХнең 18 нче Районара инспекциясендә теркәлә.

Коры саннар артында – кызыклы һәм бай журналист тормышы. Минтимер Шәймиев журналистлар белән һәрвакытта җылы, дустанә мөнәсәбәтләрдә, һәм бу Президент пулына гына кагылмый. Һәр журналистның диярлек төрле очрашулардан, яңа объектлар ачылышыннан, презентация һәм бүләкләү тантаналарыннан «Шәймиев белән мин» сериясенә караган берәр фотосы бардыр, мөгаен. Шуларның кайберләрен без бүген сезнең хозурга тапшырабыз. Үзегезне табып, шул вакытларны исегезгә төшерегез әле – бу бит сезнең Татарстан Президенты белән аралашу форсаты туры килгән шәхси журналист тарихының бер өлеше.

БЕЗ ҺӘМ ШӘЙМИЕВ

Журналистлар республика Президентын аэропортта каршы ала. 2003 ел.

Аэропортта кунаклар көткәндә. 2004 ел.

Фотолар ТР Дәүләт Киңәшчесе матбугат хезмәтеннән алынды.

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында кунакта. 2004 елның 23 июле.

«Шәймиевкә... Шәймиев турында мәзәк сөйләдем». «Татар-информ» МА генераль директоры Шамил Садыйков (сулда). 2017 ел.

Татарстан Матбугаты көнендә ММЧ урамында ТНВ телеканалыннан бүләк тапшыру. 2004 елның 19 мае.

Болгарда Президент белән истәлеккә фотога төшү. 2010 елның 30 апреле.

Без һәм Минтимер Шәймиев. Матбугат конференциясеннән соң. 2010 елның 23 гыйнвары.

PRESSA

редакция кухнясы

ШАМИЛ САДЫЙКОВТАН МЕДИАТОРТ

Татьяна Вафина

15 ел элек Татарстанда массакүләм мәгълүмат чаралары эшенең яңа формасы пәйда булды – басма матбугат, радио һәм телевидениенең аерым редакцияләре бер холдингка берләште. Ул чакта «Татмедиа» оештыруга каршылар күп иде. Хәзер исә мондый холдинг оештыру тәҗрибәсен уртаклашу өчен башка төбәкләрдән мөрәҗәгать итәләр. «Татмедиа»да эшләү тәҗрибәсе, республиканың төрле районнарында урнашкан массакүләм мәгълүмат чаралары челтәре белән җитәкчелек итү, иң зур төбәк медиакомпаниясе КУХНЯСЫ ТУРЫНДА һәм иң зур төбәк медиакомпаниясе КУХНЯСЫНДА «Татмедиа» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков сөйли. Әлеге әңгәмә барышында без бик тәмле һәм бик зур туган көн медиаторты «пешерергә» тиешбез, хәзер шуңа иң сыйфатлы ингредиентларны салып «камыр» басабыз.

АЛДЫНГЫ ТӘҖРИБӘ

– Шамил Мөхәммәтович, моннан 15 ел элек сез кайда идегез? Кайсы редакциядә эшләдегез һәм әлеге яңалыкны ничек кабул иттегез?

– Мин «Казан» муниципаль телерадиокомпаниясендә баш мөхәррир булып эшли идем, «Татмедиа» төзүгә шаһит кына булмыйча, үзем дә бу вакыйгаларда турыдан-туры катнаштым. Нәкъ менә «Казан» телерадиокомпаниясе ул чакта беренчеләрдән булып «Татмедиа» составына керде.

15 елдан соң, әле хәзер генә кешеләр әлеге карарларның дөрес, зирәк булуына төшенә башлады. Баштарак ММЧ җитәкчеләре моңа каршы килде, нинди бәхет елмаюын аңламады, диик. Мин дә аңламадым. Безгә барыбызны да мөстәкыйльлектән мәхрүм итәләр кебек тоелды. Тик нәкъ менә киресенчә булып чыкты.

«Татмедиа» бердәм бухгалтерия системасын булдырды, юридик бүлек, IT-департаменты төзелде, холдинг филиаллары редакцияләре исә бары иҗат һәм контент белән шөгыльләнү, иҗади булмаган мәсьәләләргә вакыт сарыф итмәү мөмкинлеген алды. Редакцияләрдә төрле процессуаль ыгы-зыгы, кәгазьләр тутыру хәттин ашкан иде бит. Грантларда катнашу системасы үзе генә дә ни тора! Субсидияләр,

Фото: Алсу Шакирова

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

КАМЫР ӨЧЕН:
- «Татмедиа» АҖ филиаллары – 67 редакция;
- район, шәһәр һәм республика газеталары – 98;
- журналлар – 17;
- телеканаллар – 19;
- радиоканаллар – 17;
- Интернет челтәрендәге сайтлар – 81;
- «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы – 1;
- «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы – 1.

КРЕМ ӨЧЕН:
- Татарстан Республикасындагы ике дәүләт телен (рус һәм татар) кушарга;
- бераз чуваш телен өстәргә;
- бераз удмурт телен...

БИЗӘҮ ӨЧЕН:
- сыйфатлы контент;
- тоз, борыч, сторителлинг – тәменчә.

һөнәри конкурслар, техниканы яңарту сораулары, билгеле бер сервис, технологияләрдән файдалану, укыту мәсьәләләре – боларның барысын да «Татмедиа» хәл итә һәм шул рәвешле филиалларның эшен җиңеләйтә.

Хәзер, 15 ел үткәч, без моның чыннан да бик дөрес карар булуын яхшы аңлыйбыз. Төрле төбәкләрдәге ММЧ вәкилләре бүген тәҗрибә уртаклашырга «Татмедиа»га килә. Үзләрендә дә шуңа охшаш берләшмә булдырырга тырышалар, әмма әлегә барып чыкмый. Тик шулай да алар тырыша, бездән үрнәк ала, чөнки бүген бу – медианы төбәк масштабларында үстерүдә иң алдынгы тәҗрибә. Һәм моңа аңлатма да бар: Татарстан – тотрыклы үсештәге, алдынгы төбәк.

Массакүләм мәгълүмат чараларын берләштерү мәсьәләләрендә дә ул чакта республика алдынгы булды. Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең зирәк карары, ул вакытта Премьер-министр булган Рөстәм Миңнехановның әлеге процесс белән оста идарә итүе үз җимешләрен бирде. Һәм, һичшиксез, моңа «Татмедиа» республика агентлыгы җитәкчесе Марат Моратовның энергиясе, үҗәтлеге, аның Татарстандагы массакүләм мәгълүмат чараларын төбәкнең үзе шикелле үк алдынгы итү теләге дә бик булышты. Күрүебезчә, аларның тырышлыгы бушка китмәде.

БУ БИК ВАКЫТЛЫ ЭШЛӘНДЕ

– Сезнеңчә, ММЧ редакцияләре берләшү нәтиҗәсендә нәрсәгә ия булды?

– Тарихи яктан бу бик вакытлы эшләнде – медиа тармагындагы нәкъ менә шул абсолют трансформация, тамырдан үзгәрешләр чоры бит бу. Муниципаль ММЧ өчен бу – тормышның яңа этабына күчү чоры. Редакцияләр, беренчедән, берләшкәннән соң финанс тотрыклылыгына иреште һәм хезмәт хакын вакытында түли башлады.

Хәтерләсәгез, ул чакта бу җәһәттән проблемалар шактый иде. Бер холдингка туплангач исә, редакцияләр ничек акча эшләү хакында баш ватудан котылды, иҗат һәм үсеш белән тынычлап шөгыльләнү мөмкинлегенә алды. Икенчедән, технологик мәсьәләләрне глобаль хәл итү башланды: заманча техника, җиһазлар, компьютерлар сатып алынды. Өченчедән, журналистлар яңа технологияләрне үзләштерә башлады. Алдынгы төбәкнең массакүләм мәгълүмат чаралары артта сөйрәлә алмый бит инде.

БАШКА БЕРКАЙДА ДА ЮК

– Әйе, күп кенә журналистлар хәтерли әле – нәкъ шулчакта редакцияләрне яңа җиһазлар белән тәэмин итү, бөтен массакүләм мәгълүмат чаралары эшен глобаль үзгәртеп кору башланды: төргәктән башлап контентка кадәр, сайтлар, кайбер журналларның айпад-версияләре пәйда булды (аерым алганда, «Татарстан» журналыныкы), бина үзе ремонтланды: лифтлар, тәрәзәләр, менә хәзер без утырган ашханә... Сез «Татмедиа»ның хәзерге эшенә нинди бәя бирәсез?

– Хәзер «Татмедиа» – актив үсештәге холдинг. Менә шул ук «Идел-Пресс» типографиясен генә алып карагыз әле! 15 ел эчендә аны тулысынча үзгәртеп җиһазладылар. Бу – газета-журнал һәм китаплар җитештерү күләме буенча Россиядәге иң алдынгы типография. Технологик яктан иң куәтлесе, иң заманча типография станоклары куелганы.

Социаль челтәрләрне үстерүдә «Татмедиа» иң алдынгы тәҗрибәгә ия. Безнең үз Медиамәктәбебез бар. Без Россиядә беренче булып үз газета-журналларыбыз белән маркетплейсларга кердек, Россиядә беренче булып балалар һәм яшьләр журналларына видеопроектлар форматын керттек. «Татмедиа Junior» социаль челтәрләрдә утыздан артык проект алып бара, чөнки без аңлыйбыз: 30 яшьтән яшьрәк буын традицион медиадан файдаланмый. Алар газета укымый, радио тыңламый, телевизор карамый. Аларның бөтен тормышы – смартфонда. Шун-

1 Әдәби-музыкаль, мәдәни-агарту «Китап» радиосын уйлап таптык.

2 Татар телендә бик матур, оригиналь открыткалар чыгарабыз.

лыктан, киләчәк турында уйлап, без үз аудиториябезне әзерләргә, рус һәм татар телләрендә видеопроектлар булдырырга тиеш.

Шул ук вакытта без үзебезнең өлкән аудиториябезне дә югалтмыйбыз. Газета-журналлар, телеканаллар, радиолар 50 яшьтән өлкәнрәк укучы, радио тыңлаучы, телевизор караучыларга кирәк. Бу аудитория бик актив һәм гаять зур. Безнең газета-журналларыбызның тиражы 200 меңнән арта. Бу бит – тере укучылар. Аларның һәрберсе үз газетасын көтеп ала, аны кулына тотып, рәхәтләнеп укырга тели, гәрчә интернеттан гына да укый алса да. Шунлыктан басма матбугатның кызыклы булуы зарур. Соцчелтәрләрне генә түгел, традицион медианы да үстерү сорала. Таләпләр һаман катгыйлана бара, алар онлайн-медиага көндәшлек тудыра башлый. Контентының сыйфаты, кызыклы булу ягыннан да оттырырга тиеш түгел, көн кадагындагы мәсьәләләрне сиземләргә, укучыларның сорауларына җавап бирергә тиеш. Әйе, алар яңалыкларны тапшыру буенча артка кала, әмма газета-журналлар яңалыклар өчен тәгаенләнмәгән дә, алар сорауларга җавап табу, кызыклы кешеләр турында кызыклы мәкаләләр уку өчен кирәк. Басма публикацияләргә жанр таләпләре бик югары, димәк, сыйфат та калышмаска тиеш.

Соңгы өч елда дистәдән артык яңа медиа оештырылды. Мәсәлән, татар телендә әдәби «Китап» радиосы. Мондый радио башка беркайда да юк. Ул Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның инициативасы белән һәм аның ярдәмендә гамәлгә куелды. Хәтерләсәгез, совет чорында радиодан аудиоспектакльләр бара, артистлар китап укый иде. Хәзер исә моңа ихтыяҗ булса да, контент җитәрлек түгел. «Китап» радиосы нәкъ менә шул бушлыкны тутыра да инде. Ул Казанда гына сөйли, әмма смартфонда кушымтасы бар һәм күп кеше аны социаль челтәрләрдә тыңлый ала. 60 яшьтән өлкәнрәк аудиториягә тәгаенләнгән «Тәртип» ретро-радиосы контентын да смартфоннарда тыңлыйлар. Бу – «сөйли торган» радиога мохтаҗ гаять күпсанлы аудитория. Һәм ул аннан үзенә кирәкле әңгәмәләрне ишетә, күңеленә якын музыка тыңлый. FM-тапшыру Казанда һәм Яр Чаллыда, шулай ук смартфонда бар – бөтен дөнья татарлары ана телендәге сөйләмне ишетә, татар җырларын тыңлый ала.

Традицион медиага килгәндә исә, алар үз тираләрендә онлайн-формат та булдыралар. Һәркайсының сайты һәм үз соцчелтәрләре бар. Мәсәлән, «Татарстан» журналыныкы кебек. Аның рус һәм татар телләрендәге басма версиясе маркетплейсларда сатыла – Россиянең теләсә кайсы почмагында сатып алырга мөмкин. Бу уникаль хәл. Өстәвенә, Казанда вендинг аппаратлары системасы челтәре эшли – алар барлык метро станцияләрендә, аэропортта, вокзалларда бар. Хәзер «Татмедиа» журналларын аппаратлар аша сату киосклар аша сатуны куып тотты. Бу проектның абсолют уңышы, ул үзен аклады һәм хакын каплады, сатуга тере кешене катнаштыру таләп ителмәгән вендинг аппаратларының киләчәге бик өметле.

Тагын бер гадәти булмаган юнәлеш – ачык хатлар, ягъни открыткалар. Минемчә, бу да журналистика. Менә үзегез карагыз: мәгълүмат һәм эмоцияләрне тапшыру, укучылар белән эшләү... Онытылган элеккеге, әмма күңелгә якын һәм шундый рәхәт формат. Мин үзем дә кечкенә чагымда авылдагы әби белән бабайга тирләп-пешеп открытка яза, һәр бәйрәмдә котлау юллап сөендерә идем. Бу хәзер дә бик кирәк, элеккеге кебек бик киң таралмаса да, җылы, ихлас сүзләр язылган матур открытка алырга теләүчеләр шактый күп әле.

ДӘҮЛӘТНЕҢ СОЦИАЛЬ МИССИЯСЕ

– Күп кеше «Татмедиа» массакүләм мәгълүмат чараларын дәүләтнеке дип атый. Сез мондый фикер белән килешәсезме? Сезнеңчә, дәүләт матбугат чараларының киләчәге нинди?

3 Журналистларны үзебезнең Медиамәктәптә даими укытабыз.



4 Үзебезнең басма продукцияне популяр KazanExpress, Wildberries, Ozon һәм YandexMarket маркетплейслары аша сатабыз.



5 – Белеп ашагыз: бу торт кына түгел, бу – медиаторт! Мондыйны башка беркайда да авыз итә алмаячаксыз – барысы да эксклюзив, патентланган, рецепты инде менә 15 ел буе яшереп саклана һәм бары тик «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең туган көнендә генә пешерелә.

– Миңа үз гомеремдә күп төрле массакүләм мәгълүмат чараларында эшләргә туры килде: муниципальләрендә дә, хосусыйларында да, дәүләтнекеләрдә дә, коммерция телеканаллары җитәкчесе дә булдым... Шуңа чагыштырырлык тәҗрибәм бар. Бүгенге икътисадый вазгыять массакүләм мәгълүмат чараларының бизнес булудан туктавын күрсәтә. Рекламаның гаять зур күләме соцчелтәрләргә китте. Моннан ун ел элек коммерция ММЧ товар һәм хезмәтләрне рекламалау бәрабәренә көн күрсә, хәзер бу юк. Мондый массакүләм мәгълүмат чаралары юкка чыгу алдында тора, күбесе инде юкка чыкты да. Бүгенге чынбарлыкта аларның акча эшләү мөмкинлеге аз. Дәүләт контрактлары, субсидияләр, дәүләт ярдәме булган ММЧ гына исән кала. Тормышның бүгенге этабында дәүләт ММЧ булу үзен аклый, чөнки алар беренче чиратта кеше өчен эшли, табыш алуны максат итми. Алар укучы, җәмгыять мәнфәгатьләрен күздә тота. Бүген ММЧның, бигрәк тә газета-журналларның, социаль миссиясе, бурычы – халыкны мәгълүмат белән тәэмин итү. Кешенең мәгълүмат алуга хокукы бар, бу аның төп ихтыяҗы. Шунлыктан газета-журналлар чыгару – дәүләтнең социаль миссиясе ул. Мәсәлән, пенсия түләү кебек үк. Дәүләтнең социаль миссиясе халыкны газета һәм журналлар белән тәэмин итү ул. Һәм без, журналистлар, әлеге миссияне башкарырга, хакимият белән халык арасында элемтә урнаштырырга тиеш: халыкка хакимият эше нәтиҗәләрен күрсәтергә, хакимияткә халыкның фикер-теләкләрен җиткерергә. Электрон ММЧ халык кәефе индикаторына әйләнеп бара. Онлайн-ММЧ һәм социаль челтәрләрне мониторинглауның гаять зур системасы дәүләтнең халык белән тиз арада ныклы элемтә урнаштыру системасын формалаштыра, шуңа журналистларның җәмгыять мәнфәгатьләрен яклау бурычы торган саен мөһимрәк була бара.

Нindидер хәлләрдә безнең ярдәм белән үзләрен яклар өчен, халык журналистларга, массакүләм мәгълүмат чараларына мөрәҗәгать итү мөмкинлегенә ия булырга тиеш. Киләчәк – дәүләтнеке булган массакүләм мәгълүмат чаралары кулында.

ЮГАРЫ ТИЗЛЕКТӘГЕ ҮЗГӘРЕШЛӘР

– «Татмедиа»да бер гасырлык һәм аннан да күбрәк тарихлы газета-журналлар шактый. Архивлардан карап, әлеге басма ММЧ төрле дәверләрдә, шулай ук соңгы 15 елда ничек үзгәрүен күзәтеп була. Сезнеңчә, холдингның 15 ел яшәү дәверендә журналистлар да үзгәрдеме? Һөнәри яктан? Гражданлык позициясе ягыннан?

– Журналистика Петр I заманыннан бирле үзгәрмәгәндер, мөгаен. Дөресрәге, аның асылы үзгәрми. Бу – мәгълүмат җыю һәм эшкәртү эше. Мәгълүматны җиткерү ысуллары үзгәрә. Газеталар, сайтлар, соцчелтәрләр аша... Без сезнең белән сайтларның гөрләп үсү чорын кичердек инде. Хәзер соцчелтәрләр тантана итә, безнең укучылар шунда. Шунлыктан журналистның эш форматы гел үзгәреп тора. Хәзер бик популяр юнәлеш – сторителлинг. Үзебезнең Медиамәктәптә без журналистларны сторителлингка өйрәтәбез. Модалы яңа сүз, тик без һәр яңаның шактый онытылган иске нәрсә булуын яхшы беләбез. Һәм, совет журналистикасы дәреслеген укып, әлеге сторителлингның очерк – аерым бер кеше тарихы – жанрына бик охшаш булуын ачыклый алабыз. Без Медиамәктәптә журналистларны өйрәткән бөтен төп әйберләр: теманы ачу, геройның тарихы, конфликт, сюжет үсеше, язу сыйфаты – барысы да шуннан. Аңлашыла ки, хәзер интернет гасыры, тизлекләр, тәкъдим итү, формат һәм күләмнәр башка, әмма асылы бит барыбер элеккечә. Соцчелтәрләр безне активрак, җитезрәк булырга мәҗбүр итә. Бүгенге көн журналисты гаджетлар белән эшли, фото, видео төшерә, материалларны сайтка куя, аудиторияне анализлау инструментларыннан, маркетингтан файдалана,үзен кем укыганын, аудиториясенең нинди булуын белергә тиеш... Бу акыллырак, зирәгрәк булырга мәҗбүр итә. Бүген үзгәрешләрнең тизлеге бик югары. Соцчелтәрләрне алып бару алгоритмнары һәр өч ай саен үзгәрә. Журналистка бүген гел укырга, өйрәнергә туры килә. Даими белем эстәргә әзерлек – бүгенге көн журналистының төп компетенциясе. Шунлыктан безнең Медиамәктәптә һәр атна саен онлайн-укыту бара, һәм әлеге процесс очсыз-кырыйсыз. «Татмедиа»да эшләүче барлык журналистлар гел укуда. Һәм бу «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең төп бурычы – яңа технологияләрне үзләштерү. Безнең эшебез, безнең нәтиҗә, безнең «торт» нәкъ менә шуннан җыйнала.

ТАТАРЧА, РУСЧА, ЧУВАШЧА, УДМУРТЧА...

– Татарстан – күпмилләтле төбәк. Республика гражданнарының үз ана теленә ихтыяҗы туган телләрендәге массакүләм мәгълүмат чаралары белән тәэмин ителү җәһәтеннән ничек канәгатьләндерелә?

– Безнең төбәгебез нәкъ менә күпмилләтле булуы белән уникаль дә. Газета һәм журналлар дәүләт теле булган рус һәм татар телләрендә генә түгел, әлеге милләт халкы тупланып яшәгән районнарда чувашча да, удмуртча да чыга. Күпмилләтлелек – безнең байлыгыбыз ул. Хәзер татар теленә аеруча игътибар бирәбез. Бөтен дөнья татарлары үз ана телендә укырга, яңалыклар белән танышырга, туган телен өйрәнергә тели – һәм бу безнең төп бурычларыбыздан берсе булып тора, күп проектларны Президентыбыз хуплый. Татар алфавитын өйрәтү буенча «Әлифба» проекты соцчелтәрләрдә шулкадәр зур уңышка ия!

БЕЗНЕҢ ТӨП КӨНДӘШ – ЯСАЛМА ИНТЕЛЛЕКТ

– Планнарыгыз нинди? Нәрсә гамәлгә ашырылмады әле? Татарстанның массакүләм мәгълүмат чараларын нинди киләчәк көтә?

– Бурыч – яңа медиаларны үстерү. Хәзер телеграм-каналларның үсеше бик зур. Быел заманча медиалар инде сайтларсыз, соцчелтәрләр платформасында гына булдырыла. Эш тәртибе үзгәрә. Моннан биш ел элек мәгълүмат ул чакта икенче урында торган сайтка газета басылып чыккач гына куелса, хәзер барысы да нык үзгәрде. Журналист башта үз материалын соцчелтәрләргә, аннары сайтларга, иң соңыннан гына традицион массакүләм мәгълүмат чараларына урнаштыра. Көн картинасын, җәмгатьчелек фикерен соцчелтәрләр формалаштыра, алар – калган бар нәрсәнең дә локомотивы. Һәм безнең бурыч – контентның кызыклылыгын соцчелтәрләр аша көчәйтү.

Безнең төп көндәш – ясалма интеллект һәм массакүләм мәгълүмат чараларының роботлаштырылуы. Хәзер инде сыныйбыз, безнең экспериментал СНЕГ сайты бар, анда яңалыкларны роботлар яза. Алгоритмнар бар: пресс-релизны кертәбез дә, робот яңалыкны язып чыга. Сайтның робот язган яңалыклар тасмасы инде «Яндекс»та индексацияләнә. Бу – безнең киләчәгебез.

– Ягъни әлеге киләчәктә безне робот-журналистлар кысрыклап чыгарачак? Һәм безгә ясалма булмаган интеллектыбыз белән хәзер кая барырга инде?

– Безнең өчен журналистиканың иң катлаулы жанрлары, очерклар, репортажлар, аналитика мәкаләләре, кешеләр турында язу калачак, чөнки болар хакында бернинди ясалма интеллект та яза алмаячак.

ТАТМЕДИАЭКСКЛЮЗИВ

– Уф! Иркен суларга була алайса, роботлар безне җиңмәячәк.



6 «Татмедиа» АҖ генераль директоры кабинетындагы медиаторт белән сыйланырга Якутиядән коллегаларыбыз да килеп өлгерде. Һәм чәй эчә-эчә өстәге ике катны – «Татар-информ» МА, «Татарстан» һәм «Сөембикә» журналларын «ашап» та бетерделәр.
– Сезнең Татарстанда медиа бик тәмле икән! – дип мактады алар.

– Һәм менә шушы шатлыклы нотада «Татарстан»ны туган көн торты белән чәй эчәргә чакырам. Һәм бу гади торт түгел, бу – медиаторт! Мондыйны башка беркайда да авыз итә алмаячаксыз – барысы да эксклюзив, патентланган, рецепты инде 15 ел буе яшереп саклана һәм бары тик «Татмедиа» АҖ туган көннәренә генә әзерләнә. Безнең барыбызга да тынычлык һәм уңышлар телим!

«Татмедиа» басмалары арасында унөченең бер гасырлык тарихы бар! Кайберләре йөз еллык чикне уңышлы атлап узды һәм элеккеге кебек үк үз укучыларын шатландыруын дәвам итә.

«ТАТМЕДИА» ЭЛЕК ҺӘМ

«СӨЕМБИКӘ»

Киләсе елда татар хатын-кызларының яраткан басмасы – XVI гасырда Казан ханлыгы белән идарә иткән патшабикә хөрмәтенә аталган «Сөембикә» журналы **110 еллыгын** бәйрәм итәргә җыена. Журналның пәйда булу тарихы матур риваятькә охшаган, тик бу чын хәл. Басма 1913 елның октябрендә Себер бае Заһидулла Шәфигуллинның кызы – гүзәл Әсма туташның XX гасыр башының күренекле мәгърифәтчесе Якуб Хәлилигә кияүгә килгәндәге бирнәсе буларак басыла башлый. Әсма туташ кияүгә уртак тормыш татар хатын-кызларын агартуга багышланачак дигән шарт белән чыга.

Бүген «Сөембикә»не Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә яратып укыйлар.



«КАЗАН УТЛАРЫ»

Май аенда «Казан утлары» журналына **100 яшь** тулды! Ерак 1922 елда аңа татар пролетар язучылары нигез сала. Журнал 5 тапкыр исемен алыштыра, икегә бүленә һәм яңадан кушыла, әмма һәрвакытта да үз укучысына тугры кала – беренче еллардан ук аның битләрендә әдәби әсәрләргә өстенлек бирелә.

Бүген «Казан утлары» тагын әле яңа, кесә форматында китаплар чыгара. Аларны республика китап кибетләрендә, маркетплейсларда сатып алырга мөмкин.

«ТАТАРСТАН»

«Татарстан» иҗтимагый-сәяси басмасына быел **102 яшь** тула! Бу вакыт эчендә ул исемен 9 мәртәбә алыштыра – «Вестник Татарского областкома РКП (б) » да, «Татарстан коммунисты» да була. Басмага, бигрәк тә «бала» һәм «үсмер» чорларында, ТАССРның беренче затлары җитәкчелек итә. Аларның барысын да диярлек 1937 елларда атып үтерәләр һәм соңрак аклыйлар.

Бүген «Татарстан» элеккеге кебек үк акыллы гамәлләр, игелекле эшләр, мәңгелек кыйммәтләр турында яза. Журнал ике дәүләт телендә басыла, барлык милләт вәкилләре белән дус-тату яши. Шуңа күрә ММЧ арасында беренчеләрдән булып 1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнүе дә очраклы түгел!

«ЧАЯН» («СКОРПИОН»)

«Чаян»ның туу вакыты – 1923 елның гыйнвары. Тыйнак, гади, аклы-каралы журнал тиздән халыкның яраткан басмасына әйләнә. Ә «Менә «Чаян»га язармын әле!» дигән сүзләр халык арасында бик популяр була.

1956 елда «Чаян» рус телендә дә чыга башлый. Нәкъ шул чорда басма ил күләмендә танылa һәм үз тирәсенә Казан карикатурачылар мәктәбен туплый. Редакция бүген дә бөтен Россия күләмендә автор һәм рәссамнар белән хезмәттәшлек итә.

100 елга якын вакыт дәвамында аның «кыскыч»ларына нәсел-нәсәбен санга сукмый торган космополитлар һәм империалистлар эләгә, бюрократлар, ришвәтчеләр, миһербансыз түрәләр һәм башкаларны исә әйтеп тә торасы юк.



ММЧ: ХӘЗЕР

«Татмедиа»да уйлап табылган яңа проектларның да гомере озын булыр, алар гасырлар дәвамында татарстанлыларның исендә-хәтерендә калыр, дип уйлыйбыз. Чөнки бу кызыклы һәм мавыктыргыч проектлар барлык буын кешеләренең күңеленә хуш килә һәм яңадан-яңа үрләр яулый.

«ТАТМЕДИА JUNIOR»

Яшь буында татар теленә кызыксыну уяту максатыннан, татар телен куллануда тотрыклы гадәт формалаштыру өчен 2020 елда «Татмедиа» АҖндә «Татмедиа Junior» проекты эшли башлады.

Яңа проектлар «Салават күпере», «Сабантуй», «Ялкын», «Идел» журналлары редакцияләре базасында эшләнә. Хронометражы 1 минуттан алып 30 минутка кадәр булган 33кә якын яңа видеопроект дөнья күрде. Алар YouTube, ВК, TikTok социаль челтәрләрендә урнаштырыла. Проектлар, максатчан аудитория мәнфәгатьләрен исәпкә алып, мәгълүмати-күңел ачу, танып белү, агарту, фәнни-популяр һәм белем бирү характерында ясала.

«СНЕГ МЕДИА»

«Снег Медиа» – «Татмедиа» АҖнең иң перспективалы проектларыннан берсе һәм сторителлинг буенча Татарстанда бердәнбер. Проект барлык популяр социаль челтәрләрдә урын алган. Атна саен берәр кызыклы персонаж, гыйбрәтле хәл турында мини-фильм чыга: ракның дүртенче стадиясе, тән калынаю авыруы белән чирләгән ханым ничек яши һ.б.лар... Акушерка, хәзинә эзләүчеләр турында тарихны карарга мөмкин... «Снег Медиа» 2022 елда «Иң яхшы журналист әсәре»н ачыклау буенча Россия Журналистлар союзының Профессиональ конкурсында җиңүче дип табылды.

«ТӘРТИП» РАДИОСЫ

«Тәртип» – уникаль контентка ия халык радиосы. Аның төп бурычы – узганны киләчәк белән бәйләү: татар халык көйләрен, туган телнең, әдәбиятның байлыгын, татар халкының традицияләрен бүгенге тамашачыга җиткерү...

Эфирда 24 сәгать дәвамында алтын хитлар, классик әсәрләр һәм сыйфатлы заманча музыка яңгырый.

«МИЛЛИАРД.ТАТАР»

«Миллиард. Татар» лаеклы рәвештә төп «татар» сайты дип әйтергә була. Аны 2021 елның гыйнварында эшләп китә. Сайтта татар тарихы һәм мәдәнияте популярлаштырыла, укучылар татарлар өчен көнүзәк сорауларга һәм замана таләпләренә җавап таба. Бу әле бәхәс мәйданчыгы да булып тора. Проект каршында интеллектуаль клуб эшли. Ул төрле карашка ия кешеләрне берләштерә һәм татар халкы үсешенә һәм стратегиясенә кагылышлы актуаль мәсьәләләр буенча фикер алышу урыны булып тора.

«ТАТМЕДИА» ДИНАСТИЯЛӘРЕ»

Әти-әни, әби-бабай, кыз-ул, оныклар – тулы бер династияләр озак еллар дәвамында үзләре сайлаган журналист һөнәренә тугры кала. Һәр журналист гаиләсенең тарихы уникаль: аларны тыңлау сериал карауга тиң – һәр сюжетның төенләнеше, кульминациясе һәм чишелеше бар... «Татмедиа» династияләре» проекты буыннар бәйләнеше аша журналист һөнәрен популярлаштыруга юнәлдерелгән.

Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

«Татарстан»журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9172-740-352

Реклама 16+

РӨСТӘМ УСМАНОВ: «ТАТАРСТАНДА ГАЗЛАШТЫРУ ПРОЦЕНТЫ – РОССИЯДӘ ИҢ ЮГАРЫСЫ»

Фотолар «Газпром трансгаз Казан» җәмгыятеннән алынды. РЕКЛАМА

«Татарстан» сорауларына «Газпром трансгаз Казан» җәмгыяте генераль директоры җавап бирә.

ГАЗЛАШТЫРУ СОЦИАЛЬ ПРОГРАММАСЫ ТУРЫНДА

– Билгеле булганча, илдә газлаштыру (яки өстәмә газлаштыру) социаль программасы гамәлгә ашырыла, аның нигезендә газны җир кишәрлеге чикләренә кадәр үткәрү гражданнарның акчаларын җәлеп итмичә башкарыла. Татарстанда программа ничек тормышка ашырыла?

– ТР Министрлар Кабинеты карары* белән расланган графиклар буенча, 2023 ел ахырына кадәр 10 066 йортны газлаштыру каралган. Әлеге программадан исә, безнең исәпләүләргә караганда, барлыгы 18 меңнән артык кеше файдалана алачак. Газ белән эшли торган җиһазларны газ бүлү челтәрләренә тоташтыру турында 11 меңнән артык килешү төзелгән. Газлаштыру программасы кысаларында, гражданнардан акча алмыйча гына, газүткәргеч 5,5 мең җир кишәрлеге чигенә кадәр китерелгән. 1300 дән артык йорт газга тоташтырылган.

– Хәтта үз кишәрлеге эчендә дә газ тоташтыру чыгымнарын күтәрә алмаган акчасыз кешеләргә нишләргә?

– Республика җитәкчелеге гражданнарның аерым категорияләренә кишәрлек эчендә газны тоташтыруга киткән чыгымнарны компенсацияләү турында карар кабул итте. Болар – Бөек Ватан сугышы ветераннары, 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләләр, I һәм II төркем инвалидлары, инвалид балалары булган гаиләләр, шулай ук җан башына уртача керем бер кешегә 10 мең сумнан артмаган гаиләләр. Компенсация 80 мең сум тәшкил итә. Бу сан Россия буенча уртача күрсәткечтән югарырак. Шунысын да искә алып үтим: кайбер төбәкләр ишегалды

* Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 18 маенда кабул ителгән 460 нчы карары

«ГАЗПРОМ ТРАНСГАЗ КАЗАН» ҖӘМГЫЯТЕ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ГАЗНЫ КУЛЛАНУЧЫЛАРГА ЫШАНЫЧЛЫ ҺӘМ ӨЗЛЕКСЕЗ РӘВЕШТӘ КИТЕРЕП БИРҮ ҺӘМ БҮЛҮ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНӘ, ШУЛАЙ УК ГАЗ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ СИСТЕМАСЫН КУРКЫНЫЧСЫЗ ЭКСПЛУАТАЦИЯЛӘҮГӘ ЮНӘЛДЕРЕЛГӘН ЭШЛӘРНЕ БАШКАРА. 2022 ЕЛНЫҢ 6 АЕНДА ГАЗ ТРАНЗИТЫ 89,3 МЛРД КУБОМЕТР ТӘШКИЛ ИТТЕ. РЕСПУБЛИКАДАГЫ КУЛЛАНУЧЫЛАРГА 8,1 МЛРД КУБОМЕТР ТАБИГЫЙ ГАЗ КИТЕРЕЛДЕ. ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ БУЕНЧА КӨТЕЛГӘН КҮЛӘМНӘР 2021 ЕЛ ДӘРӘҖӘСЕНДӘ – 18,2 МЛРД КУБОМЕТР БУЛАЧАК. БУ КҮРСӘТКЕЧ БЕЛӘН УЛ ВАКЫТТА БЕЗ МӘСКӘҮДӘН ГЕНӘ КАЛЫШТЫК.

эчендә газ тоташтыру чыгымнарын бөтенләй бирәүгә дә капламый.

– Татарстанда потенциаль кулланучыларның җир кишәрлекләре чигенә кадәр газүткәргечләр салуның федераль программа кабул ителгәнче үк алып барылганлыгы дөресме?

– 2019 елдан башлап, республикада Торак-коммуналь хуҗалыкны, сәнәгать оешмаларын һәм башка оешмаларны газлаштыру буенча төбәк программасы нигезендә мөрәҗәгать итүчеләрнең җир кишәрлеге чигенә кадәр газүткәргечләр төзү каралган иде. Быел 3000 нән артык җир кишәрлеге чигенә кадәр газ торбасы сузу планлаштырылган. Бүгенгә исә инде 1500 гә якын җир кишәрлеге чигенә хәтле газүткәргечләр китерелгән һәм файдалануга тапшырылган. Әлбәттә, соңыннан аларның хуҗалары газлаштыру өчен гариза бирә алачак.

РЕСУРСЛАР ҺӘМ ИХТЫЯҖЛАР ТУРЫНДА

– Гамәлдәге һәм, бәлки, перспективадагы газлаштыру программаларын тормышка ашыруны нәрсә тоткарларга яки, киресенчә, тизләтергә мөмкин?

– Аңлашыла ки, барлык кирәкле ресурслар булганда, газлаштыру уңышлы барачак. Газ китерә торган төп газүткәргечләр дә, тиешле егәрлекләр дә булырга тиеш. Былтыр декабрь аенда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән «Газпром» ширкәтенең Идарә рәисе Алексей Миллер очрашуында төгәл килешүләргә ирешелде. «Газпром» җитәкчелеге ике документны хуплады. Беренчесе – Татарстанны газ белән тәэмин итүнең генераль схемасы, ул стратегик планлаштыруны тормышка ашырып, киләчәктә республикада газ куллануны тәэмин итү өчен, бистәара һәм магистраль газүткәргечләр төзүне күздә тота. Мәсәлән, «Алабуга» махсус икътисадый зонасы һәм бөтен Түбән Кама сәнәгать комплексының киләчәктә газ куллану мөмкинлеге шактый зур. 2030 елга республикада газ куллану күләме, нигездә Түбән Кама сәнәгать узелы хисабына, 33 млрд кубометрга җитәргә мөмкин, дип планлаштырабыз. Бу кадәр кубометрларны кирәкле ресурслар белән дә тәэмин итәргә кирәк.

Моннан тыш, республика тарихында беренче тапкыр бистәара газүткәргечләр төзү программасын раслау планлаштырыла.

– Аны тормышка ашыру өчен күпме вакыт бирелә?

– Программада 2 млрд сум бүлеп бирү карала. 2023–2024 елларга проект-тикшеренү эшләре планлаштырыла, 2024–2027 елларда актив төзелеш алып бару күздә тотыла.

– Барлык потенциаль кулланучылардан сорау. Эчке базар өчен газ җитәрме соң? «Газпром» яңа төзелешләр белән бәйле планнарга ничегрәк караячак?

– Әгәр без бу төзелешнең кирәклеген дөрес итеп нигезли алсак, «Газпром» яңа финанслар бүлеп бирүне раслаячак. Дус булмаган партнерларның гамәлләре аркасында эчке базарда газ куллануны арттыру мәсьәләсе көн үзәгенә менде. «Газпром» җитәкчелеге һәм шәхсән Идарә рәисе беренче чиратта эчке базар ихтыяҗларын тәэмин итү яклы, бу очракта торак та, кече һәм урта бизнес белән эре сәнәгать субъектлары да күздә тотыла. Бүген республикабыз Россиядә газлаштыру дәрәҗәсе буенча иң алдынгыларның берсе – Татарстанда бу сан 99,5% тәшкил итә. Без бу турыда горурлык белән сөйлибез. Югарыда санап үтелгән барлык чараларны үтәгәндә, әлеге нисбәтне 99,8% ка кадәр күтәрергә мөмкин.

Әгәр дә без бүген әйткән адымнарны ясамасак, 99,5% тәшкил иткән газлаштыру дәрәҗәсе иртәгә 80% ка кадәр, аннары тагын да түбәнрәккә тәгәрәячәк. Республика динамик рәвештә үсә: тораклар төзелә, заводлар ачыла, кече һәм урта эшкуарлыкның яңа субъектлары барлыкка килә. Алар барысы да газ куллана. Республика да, «Газпром» җитәкчелеге дә уртак фикердә – кулланучы теләгәнен алырга тиеш, шуңа күрә без киләчәккә карап эшлибез.

ЭКОЛОГИК КУЛЬТУРА ҺӘМ ЭКОНОМИЯ ТУРЫНДА

– Быел РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары Виктория Абрамченко «Газпром» ГАҖ Идарәсе рәисе Алексей Миллерга «Газпром трансгаз Казан» хезмәткәрләренең «Идел көне» экологик проектында актив катнашканнары өчен рәхмәт белдерде. Укучыларга экология белән төп эшчәнлегегезне ничек берләштерә алуыгыз кызыклы дип уйлыйм.

– Монда гаҗәпләнергә урын юк. Хезмәткәрләрнең экологик культурасын күтәрүгә, әйләнә-тирә мохитнең пычрануын киметүгә юнәлтелгән колачлы проектларны тормышка ашыру – эшебезнең бер өлеше. Җитештерү эшчәнлегебездә табигатьне иң күбе метан бүленеп чыгару пычрата. Алдыбызда торган бурыч – моны мөмкин кадәр киметү. Бу мәсьәләне хәл итүнең бер юлы мобиль компрессор станцияләре ярдәмендә газны газүткәргечнең ремонт

барган участогыннан гамәлдәге өлешенә кудырудан гыйбарәт. Шул рәвешле саклап калынган газны аннары кулланучыларга җибәрәбез. Шундый ук чаралар компрессор станцияләрендә дә тормышка ашырыла.

– Нәтиҗәсе нинди?

– Узган ел энергияне сак тотуга юнәлдерелгән чаралар 50 млн кубометрдан артык газны янга калдырырга мөмкинлек бирде. Чагыштыру өчен: кышын бөтен Татарстан бер тәүлектә шуның кадәр газ куллана. Күз алдына китерегез әле элегрәк бу хәтле ягулык атмосферага очып китә иде, хәзер исә алдынгы технологик ысуллар куллану бәрабәренә ремонт эшләре вакытында газ югалту кими, шуның белән бергә атмосферага тискәре йогынты да азая.

«Идел көне» экологик акциясенә килгәндә, биредә коллектив объектларыбыз янындагы су саклау зонасын чистарту белән генә чикләнми. «Газпром трансгаз Казан» ел саен су биоресурсларын ясалма үрчетү белән бәйле табигатьне торгызу чаралары үткәрә. Әйтик, быел көз Татарстан һәм Киров өлкәсе сулыкларына 103,5 мең чөгә, сазан, юанбаш маймычы җибәреләчәк.

Экологик культураны күтәрүнең иң яхшы ысулы – көндәлек практика. Шуңа күрә предприятиедә чүп-чарны аерым җыюны күздә тоткан максатчан программа эшли. Җитештерү территорияләрен, безнең объектлар янындагы яшел зоналарны, елга ярларын төзекләндерү, чистарту «Яшел яз – 2022», «Идел көне» һәм башка массакүләм экологик акцияләр кысаларында гына түгел, ә даими рәвештә үткәрелә.

ХЕЗМӘТ ХАКЫ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ГАРАНТИЯЛӘР ТУРЫНДА

– «Газпром трансгаз Казан» җәмгыятенең колачлы бурычларын тормышка ашыручы кешеләргә ни дәрәҗәдә уңайлыклар тудырыла?

– Без югары квалификацияле коллективның тотрыклылыгын саклап калырга тырышабыз, кадрлар агымы «Газпром»да иң түбәннәрдән санала. Хезмәткәрләрнең социаль гарантияләре коллектив килешүдә теркәлгән. Хезмәт хакының реаль дәрәҗәсен саклау өстенлекле бурычларның берсе булып тора. Аерым алганда, 1 гыйнвардан хезмәт хакларына еллык индексация ясалды һәм алар 7,5% ка арттырылды, ә 1 июльдән «Газпром» ГАҖ җитәкчелеге хезмәт хакларын тагын 10% ка индексацияләде. Без мондый чаралар, шактый зур социаль пакет белән бергә, хезмәткәрләрнең хезмәт хакын реаль дәрәҗәдә сакларга һәм инфляция процессларын җитәрлек дәрәҗәдә компенсацияләргә мөмкинлек бирә, дип саныйбыз.

Әлбәттә, күп балалы гаиләләргә ярдәм аерым игътибар үзәгендә, аз керемле гаиләләргә һәм инвалид балалары булган гаиләләргә айлык пособие түлибез, шулай ук мәктәпкәчә учреждениеләргә түләү чыгымнарын компенсацияләү дә каралган. 2022 елның беренче яртыеллыгында җәмгыятьнең 11 хезмәткәре, уңайлы яңа фатирларга күчеп, торак шартларын яхшыртты.

– Социаль гарантияләр ветераннарга да кагыламы?

– Әлбәттә. Пенсия яшенә җиткән, шулай ук вакытыннан алда пенсиягә чыккан хезмәткәрләр бер тапкыр бирелә торган пособие ала. Дәүләтнеке булмаган пенсия белән тәэмин итү һәм пенсионерларны социаль яклау юнәлешендә дә шактый эшләр башкарыла. Дәүләтнеке булмаган пенсия белән тәэмин итү килешүләре нигезендә предприятие кертемчеләрнең барлык йөкләмәләрен үти. Бөек Ватан сугышының һәр ветеранына матди ярдәм күрсәтү – изге бурычыбыз. Ярты ел нәтиҗәләре буенча хезмәткәрләребезгә, шулай ук пенсионерларга барлык социаль түләүләр суммасы 560 млн сумнан артты.

– Ә кемгәдер шифаханәдә сәламәтлеген яхшыртырга кирәк була калса?

– Үзегез нәтиҗә ясагыз. 2022 елның 6 ае эчендә 2,5 мең хезмәткәр, аларның гаилә әгъзалары һәм пенсионерлар шифаханә-курорт һәм реабилитация-тернәкләндерү дәвасы алу өчен юлламалар белән тәэмин ителде. Алар «Газовик» шифаханә-профилакториендә, «Газпром»ның Кара диңгез буендагы шифаханә-курорт объектларында, шулай ук Татарстан шифаханәләрендә дәваланды. Үсеп килүче буынга – аерым игътибар. Быел Татарстанның һәм башка төбәкләрнең балаларны савыктыру лагерьларында 460 тан артык бала ял итте. Тагын 130 бала әти-әниләре белән республикабыз, Краснодар крае һәм Кырым шифаханәләрендә һәм пансионатларында булып кайтты.

ФИЗИК КУЛЬТУРА ТУРЫНДА

– Массакүләм спортны үстерү дә җәмгыятьнең өстенлекле максатлары исемлегендәме?

– Бездәге массакүләм спорт һәм физкультура-сәламәтләндерү хәрәкәтендә 5000 нән артык хезмәткәр һәм аларның гаилә әгъзалары катнаша.

Без хәтта үзебезнең спартакиадаларны да үткәрәбез. Апрель аенда җәмгыять хезмәткәрләре спартакиадасы узды, аның финал өлешендә барлык структур бүлекчәләрдән 400 дән артык спортчы катнашты. Аның җиңүчеләре Санкт-Петербургта узган «Газпром» ГАҖ спартакиадасында предприятие данын лаеклы яклады.

АК ХАЛАТЛЫ ЯСАЛМА ИНТЕЛЛЕКТ

Ольга Туманская

Компьютер төймәсенә бер-ике тапкыр басуга, үпкәнең рентген сурәте Интернет челтәре буенча Мәскәү клиникасыннан Иннополиска «оча». Биредә AI RADIOLOGY CXR сервисы өзеклекләрсез эшләп тора. Ул медикларга үпкәдәге тайпылышларны табарга һәм аңларга булыша. 40 секундлап вакыт үтүгә, табиб-рентгенолог пациентка куелган диагноз турында ясалма интеллект тарафыннан әзерләнгән отчетны ала.

Ап-ак зур бүлмәгә килеп керүгә, тынычлык билэп ала. Компьютер өстәле янына утырган белгечләр үз мониторларына текәлгән. Барысы да бик гади, тыйнак – безгә Ясалма интеллект институты нәкъ шулай күренде. Бу – Иннополис Университетындагы технологик үзәкләрнең берсе, биредә «акыллыбашлар» бары тик фантастлар гына хыяллана алган нәрсәләрне тормышка ашыру юнәлешендә эшли.

БИРЕДӘ ИНТЕЛЛЕКТНЫ ӨЙРӘТӘЛӘР

Институтның бер эш проектын «компьютер күзе» дип атыйлар. Бу ясалма интеллектның бер өлеше, аның ярдәмендә «электрон ми» сурәтләрне танырга, аннан соң аларны аерырга өйрәнә. Әлеге технологияне куллану өлкәсе шактый киң – космоста һәм һавада фотога төшерү һәм видеомониторинг системаларыннан алып, медицина сурәтләрен «укуга» кадәр. Безне нәкъ менә соңгысы кызыксындыра.

– Ясалма интеллектны медицина сурәтләрен танырга һәм аңларга өйрәтү идеясе безнең институтта әле 2014 елда ук туды. Ә инде дөньяны COVID-19 билэп алгач, без тагын да тирәнгәрәк китәргә һәм үзебезнең эшләнмәне кулланышка – табибларга үпкәдәге чирләрне табарга ярдәм итә торган гамәли сервиска кертергә уйладык, – дип сөйли әлеге сервисны уйлап табучыларның берсе Шамил Хастиев.

Барысы да ясалма интеллектны үпкәдә тайпылыш бармы-юкмы икәнлеген ачыкларга өйрәтүдән башлана. Компьютер «акылы»

Фотолар Александр Ефремовтан, Мәскәү Сәламәтлек саклау департаментының Диагностика һәм телемедицина үзәге матбугат хезмәтеннән алынды.

акрынлап үз квалификациясен арттыра бара һәм инде хәзер ул, ялкынсынган урынны табып, аны сурәттә контур белән әйләндереп алу гына түгел, чирне тәңгәлләштерергә дә өйрәнә.



– Медицина белеме алу өчен кешегә алты елдан артык вакыт кирәк, ә ясалма интеллектны өйрәтергә күпме вакыт таләп ителде? – дип сорыйм мин Шамилдән.

– Әлбәттә, күпкә азрак вакыт! Ләкин биредә шуны аңлау мөһим: диагноз куйганда соңгы сүзне ясалма интеллект түгел, элеккечә үк табиб әйтәчәк. Әлегә сервис бары тик икенче фикерне җиткерүче генә, әле озак вакытлар ул кешене тулысынча алыштыра алмаячак. Аның каравы инде бүген үк, кеше факторын, ягъни табиб ялгышларын булдырмый калырга булыша.

Сервис бүген дә үз «белемен» арттыру юнәлешендә эшли – хәзер инде эш барышында килгән мәгълүматка таянып. Сүз уңаеннан, ул монда, Иннополистагы серверда урнашкан. Шул рәвешле аны уйлап табучылар камилләштерү һәм эшләп бетерү белән генә шөгыльләнмичә, ясалма интеллектка хезмәт күрсәтү белән дә мәшгуль. Бу әлеге сервисны куллана торган клиникалар өчен бик уңайлы: күпме оештыру һәм техник мәсьәләләр хәл ителә бара.

ЭКСПЕРИМЕНТ ДӘВАМ ИТӘ

...Тайпылышлар булмаган үпкә сурәте. Әмма бу без, кешеләргә, шулай күренә. Предикатив диагностика сервисы икенчерәк фикердә: тукымаларда нindидер үзгәрешләр бүген булмаса, иртәгә башланачак. Ә хәзергә – нуленче стадия – фактта авыруны исәпли башлау ноктасы. Ә бәлки ул башланмас та, чөнки әлеге мәгълүмат нигезендә чирне кисәтү чаралары программасын төзергә була...

Әлеге футуристик картинаны Мәскәү Сәламәтлек саклау департаментының Диагностика һәм телемедицина үзәгенең перспективалы үсеш буенча директор урынбасары Игорь Шулькин аңлата. Аның фикеренчә, киләчәктә ясалма интеллектны үстерү шул исәптән алдан кисәтү яисә фаразлау медицинасына да бәйле булачак. Аңа башлангыч бүген үк салынган инде.

– Без үзебезнең эшләнмәне кулланышка – табибларга үпкәдәге чирләрне табарга ярдәм итә торган гамәли сервиска кертергә уйладык, – дип сөйли әлеге сервисны уйлап табучыларның берсе Шамил Хастиев.

Мәскәү Сәламәтлек саклау департаментының Диагностика һәм телемедицина үзәгенең перспективалы үсеш буенча директор урынбасары Игорь Шулькин фикеренчә, киләчәктә ясалма интеллектны үстерү шул исәптән алдан кисәтү яисә фаразлау медицинасына да бәйле булачак.

– Компьютер күзе, компьютер аша күрү эксперименты Мәскәүдә 2020 елда башланды. Коронавирус китереп чыгарган пневмонияне ачыклау, үпкәнең зарарлану дәрәҗәсен билгеләү өчен күкрәк читлегенә ясалган томография нәтиҗәләрен компьютерда эшкәртү әлеге экспериментның беренче юнәлеше булды, – дип сөйли Игорь Шулькин. – Икенче юнәлеш – күкрәк читлегендә урнашкан органнар рентгенографиясенә анализ ясау. Бүген проектта әлеге проблема белән мәшгуль егермегә якын компания катнаша. Шуңа күрә AI RADIOLOGY CXR сервисы бердәнбер түгел, әмма иң лаеклылардан берсе. Белгәнебезчә, камиллеккә чикләр юк. Бигрәк тә сүз ясалма интеллектны гамәли сәламәтлек саклау өлкәсенә кертү турында барганда.

Ай саен эксперимент сайтында лидербордлар – төгәл күрсәткечләргә нигезләнгән сервислар рейтингы басыла. Әлеге язманы әзерләгәндә Иннополиста уйлап табылган сервис лидерлар исәбендә түгел иде, әмма кайчандыр ул беренче урынны биләп торган иде инде. Вазгыять ай саен үзгәреп тора, ә көндәш компанияләр арасында күрсәткечләрнең аермасы бик кечкенә.

– Әлеге сервисны шактый сизгер итеп көйләргә була: әгәр ясалма интеллект патология юк дип раслый икән, 99,9% очракта чыннан да тайпылыш булмый, – ди Игорь Шулькин. – Аның үзенчәлеклелеген яхшыртасы, ягъни диагноз «кую» төгәллеген генә арттырасы калды.

Программа төзүчеләргә алгоритмны камилләштерергә табиб-рентгенологлар ярдәм итә. Ә алар арасында экспериментта катнашучыларның саны меңнән артык! Бүген алар өчен ясалма интеллект сервисын куллану көндәлек эшкә, диагноз куюда аерылгысыз инструментка әйләнгән. Ә программаны эшләүчеләр белән медикларны көн саен аралашу бәйләп тора.

– Табиблар, сурәтләрне беркетеп, безгә үз фикерләрен җиткерә: әйтик, менә бу очракта сезнең сервис шәп эшли, ә менә монда аны әле эшләп бетерергә кирәк, дип саныйм кебек фикерләр, – дип сөйли Шамил Хастиев. – Һәм без камилләштерәбез, яхшыртабыз, яңа функцияләр кертәбез... Гомумән, бер урында тормыйбыз.

АЛГА АТЛЫЙБЫЗ!

– Без инде Татарстандагы медицина оешмаларында пилот проектларын уңышлы башкарып чыктык: әйтик, Казанда Республика онкология клиник диспансерында, Республика туберкулезга каршы клиник диспансерында, ТР ССМның Республика клиник хастаханәсендә, Әлмәттәге медицина-санитария частенда, – дип санап китә Иннополис университеты директоры урынбасары – беренче проректоры Искәндәр Бариев. – Һәм бөтен җирдә дә безнең сервис яхшы нәтиҗәләр күрсәтте, үз потенциалын ачты. Киләчәктә без аны башка төбәкләргә дә кертергә ниятлибез, шулай да Татарстан безнең өчен өстенлекле урында. Өстәвенә, безгә билгеле булганча, бүген Мәскәүдә эшләгән кебек референс-үзәкне республикабызда да ачарга планлаштыралар. Анда да ясалма интеллект сервисын куллану күздә тотыла.

Иннополиста эшләнгән сервис хәзерге вакытта клиник сынаулар уза. Бу Сәламәтлек саклау өлкәсе буенча федераль күзәтчелек хезмәтендә медицина эшләнмәсенә теркәлү узу өчен кирәк. Чөнки теркәлү пилот проектларда катнашмаган оешмаларда да әлеге сервисны кертү өчен таләп ителгән шарт.

– Инде бүген үк Мәскәү эксперименты кысаларында алынган тәҗрибәне исәпкә алып, галимнәр командасы башка модальлекләр белән эшләү өчен яңа сервислар уйлап табу юнәлешендә эшли. Мисалга, КТ, МРТ, патоморфологик тикшеренүләр белән эшләү өчен, – дип сүзен дәвам итә Искәндәр Бариев.

Ягъни эшен үпкәдә тайпылыш бармы дигән гади сорауга җавап табудан башлаган Иннополис ясалма интеллекты үз алдына куелган бурычларны катлауландыра бара. Бүген ул инсультны танырга, кеше организмында яман шешне ачыкларга өйрәнә.

– Бүген без үзебезнең университетта тест үткәрү стадиясендә, сервис эшенең төгәллеген арттырырга тырышабыз һәм, минем уйлавымча, тиздән яңа версияне чын хастаханә шартларында сынап карауга әзер булачакбыз, – ди Шамил Хастиев.

Ә хәзергә... Кырык секундлап вакыт үтә һәм югары технологияләр шәһәреннән мең чакрым диярлек ераклыктагы табиб документ – ясалма интеллект куйган диагнозны ачып укый. Үпкәдә тайпылыш ачыкланган. Диагноз куелган. Барысы да дөрес – икесе дә бер фикердә.



ҮЗЕҢНЕ АВАТАРДАЙ ХИС ИТ!

Ольга Туманская

Фотолар: автордан, КФУның МТИС институты архивыннан алынды.

– Әйдә, яхшырак күренсен өчен чүмечен күтәр! – дип команда бирә проектны эшләүче.

Аның ноутбук янында утырган хезмәттәше монитордагы интерфейс иконаларына кагыла һәм экранның теге ягында кечкенә генә трактор шунда ук җавап бирә.

Кечкенә генә төгәллек: без КФУның Мәгълүмат технологияләре һәм интеллектуаль системалар институтында (ИТИС), ә оператор таләбе буенча әйтерсең лә тылсымлы таяк ярдәмендә чүмечне әйләндерә торган чын машина – бездән берничә чакрым ераклыкта.

МИН МОНДА ДА, АНДА ДА

– Корпусын борсын! Ә аннан соң бераз гына барсын да кире борылсын, – дип эшләнмәләренең мөмкинлекләрен күрсәтүне дәвам итә Игорь һәм Олег Сергуниннар. Кечкенә трактор таләпләргә берсүзсез буйсына.

Без күргән нәрсә «Аринет Спейс» челтәр платформасы дип атала. Бу – ерактагы җайланмалар белән идарә итү системасы. Ул күпкулланучылы һәм заманча социаль челтәрләрнең тулы функциональлына ия. Бертуган Сергуниннар раславынча, система теләсә нинди җайланманы идарә итешле ясый ала. Хәтта гараж шартларында җыелганны да. Бездән мең чакрым ераклыкта булганны да.

Ә хәзер чын тормыштан мисал китерик: Нью-Йорктагы хирург медицина роботы ярдәмендә дистанцион рәвештә Лондонда опе-

Күпкулланучылы дистанцион җайланмалар белән идарә итүнең Татарстанда уйлап табылган өр-яңа системасы теләсә кайсы җайланманы идарә ителешле ясый ала. Хәтта ул бездән меңнәрчә чакрым ераклыкта булса да.

рация ясый. Кинәт аңа нейрохирург ярдәме кирәк була. Классик схема буенча, алар икесе дә Нью-Йоркта пульт янында очрашырга тиеш.

– Безнең система исә реаль вакыт режимында Җир шарының төрле нокталарында эшләүче берничә белгечне тоташтырырга мөмкинлек бирә, – дип дәвам итә ИТИСның «Сәнәгать процессларында киңәйтелгән чынбарлык технологияләре» фәнни тикшерену лабораториясе хезмәткәре һәм «Аринет Спейс» компаниясе генераль директоры Олег Сергунин.

Бу проектның презентациясе катнашучыларда зур кызыксыну белән бергә, бик күп сорау да тудырды.

– Дөньяда мондый системалар бармы?

– Бөтенләй юк! Яңа буын интернет-платформасын булдыру өчен, без инде билгеле булган чишелешләрне кулландык, тик аларны стандарт булмаган формада берләштердек, куштык һәм үзебезнең эшләнмәләр белән тулыландырдык.

– Кулланучылар бер-берсеннән меңнәрчә километр ераклыкта... Ә сигналларның тоткарлануы белән нишләргә?

– Стерео FHD видеоны трансляцияләгәндә тоткарлану 0,5 секундтан да артык түгел, бу мәгълүмат тапшыру челтәренең операторына һәм тибына бәйсез рәвештә! Тоткарлану юк дип әйтергә мөмкин. Җайланма белән идарә итү реаль вакыт режимында бара! Бу – безнең ноу-хау.

ИТИСның икенче – «Өстәлгән/виртуаль чынбарлык һәм уеннарны эшләү» лабораториясе хезмәткәрләре коллегаларына сорауларын юкка гына бирми. Аларга платформаны өр-яңа эшләнмәләр белән тутырырга туры киләчәк. Бу тормышка ашуга, идарә итү пультына утырган һәркем үзен атаклы «Аватар» фильмы яки «Суррогаты» картинасы герое итеп тоя алачак.

КАТНАШКАНДАЙ ТОЮ ЭФФЕКТЫ

Мин робот. Миңа мондый хисне VR-шлем бирә. Кулымны күтәрәм, һәм механик әзмәвер дә шулай ук эшли – без аның белән бербөтен кебек. Виртуаль чынбарлык дөньясы – Virtual Reality шундый. Ә хәзер күз алдына китерегез: бу робот ясалган түгел, ә чып-чын, ди. Мин исә ниндидер уен эчендә түгел, ә җитештерү процессында катнашам. Мәсәлән, югары вольтлы баганалар утыртам, чыбык сузам. Үземнең аватар белән Extended Reality технологиясе, ягъни робот белән минем арадагы бәйләнешне булдыра торган киңәйтелгән чынбарлык ярдәмендә идарә итәм. Сүз уңаеннан, нәкъ минем күз алдымда идарә менюсы барлыкка килергә мөмкин. Мин бармак белән (туры мәгънәсендә) һавада кирәкле вкладканы сайлап, механик әзмәверне иелергә мәҗбүр итәм һәм аңа тиешле йөкне күтәртәм.

– Телекатнашу (ягъни еракатан торып катнашу) системасы аша без мондый гамәлне бүген үк эшли алабыз, – ди өстәлгән/ виртуаль чынбарлык һәм уеннарны эшләү лабораториясе җитәкчесе Влада Кугуракова. – VR һәм AR технологияләрен куллану «Аринет Спейс» интерфейсын кулланучы өчен гади һәм аңлаешлы итәргә мөмкинлек бирәчәк. Идеалда оператор үзен, әйтик, шул ук трактор кәнәфиендә утырып, кыр буйлап йөргәндәй хис итәчәк. Гәрчә аның янында бернинди кыр да, трактор да юк.

Робот, трактор, пилотсыз эшли торган механизмнар... Уйлап табучылар платформаны теләсә нинди җайланмага тоташтырырга мөмкин, дип раслый. Ләкин ничек?

– Моның сере – берләштерелгән плата-да: ул безнең тарафтан дистанцион идарә ителәчәк механизмның үзенчәлеген исәпкә ала, – дип аңлата Игорь Сергунин. – Аның ярдәмендә идарә итү блогы җайланмага тоташа һәм механизмнарының эшли алу чикләре – «иреклек дәрәҗәсе» турында «сораштыра». Мәсәлән, винтильне күпмегә кадәр борырга мөмкин яисә рычагны ничә бүлемгә кадәр тартырга була. Әлегә без 24 ирeклек дәрәҗәсен кулланабыз, гәрчә безнең платформа тарафыннан аларның саны чикләнмәсә дә.

Йөз ирeклек дәрәҗәсенә ия һәм ерактан торып эшләргә сәләтле робот безнең көндәлек тормышыбызга кереп китәргә бик мөмкин. Чагыштыру өчен: гаять зур хәрәкәтчәнлеккә ия кеше организмында мондый ирeклек дәрәҗәләре йөздән бераз гына артыграк.

– Әлеге эшләнмәнең гражданлык кушымталары – бик күп, аны кайда кулланып булмавын әйтү җиңелрәктер, – дип сүзгә кушыла Влада Кугуракова. – Мөгаен, чәчәкләрне исни алмыйдыр. Хәер... анысы да мөмкин хәл кебек.

Мәсәлән, хәзер күп кенә уйлап табучылар интеллектуаль авыл хуҗалыгы техникасын булдырырга тырыша – ул үзе сөрсен, үзе чәчсен. Әмма бүген аграрийлар эшли торган гадәти машиналар паркы белән нишләргә? Алар белән берләшә алырлык кирәкле плата ясап, яңа платформа базасында тракторчыга өйдән торып эшләүне тәкъдим итәргә мөмкин. Сменалап, 24/7. Төрле төбәкләрдәге вакыт аермасын исәпкә алганда, хәтта беркемгә дә төнлә эшләргә туры килмәячәк.

СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘР БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ХУПЛАНА

Өстәлдә робот-чаян йөри. Ул башын төрле якка боргалый, кыскычларын да хәрәкәткә китерә ала. Әлбәттә, мондый конструкция белән хәзер беркемне дә шаккатырып булмый. Ә нәрсәсе гаҗәп соң? Чаян-роботның төрле өлеше белән төрле кеше идарә итә ала. Мәсәлән, уң кыскычының операторы Мәскәүдә утыра, сулыныкы – Лос-Анджелеста. Бу аларга җайланма белән идарә иткәндә көйле эшләргә генә түгел, ә реаль режимда аралашырга да комачауламый. Аларга бу бәйләнешне яңа буын «Аринет Спейс» социаль челтәре тәэмин итә.

– Без уйлап тапкан дистанцион җайланмалар белән күпкулланучылы идарә итү системасы, социаль челтәрләр функционалы белән бергә, кеше өчен гадәти форматта аралашырга (видеоконференцияләр оештырырга һәм үткәрергә, видеошалтыратуларга ясарга, текст һәм медиафайллар белән алмашырга) гына түгел, аларга физик дәрәҗәдә дә хезмәттәшлек итәргә мөмкинлек бирә, – дип сөйли Игорь Сергунин.

Һәм менә инде дөньяның төрле почмакларында яшәп, Африкадагы бер кырда сменалап эшләүче комбайнчылар төркеме күз алдына килә. Социаль челтәр аларга бергә «җыелырга» һәм, димәк, бердәм эшләргә, уртак хезмәткә кагылышлы мәсьәләләрне тиз арада хәл итәргә мөмкинлек бирә. Урып-җыю кампаниясе җитәкчесенә дә үз коллективы белән өзеклекләрсез идарә итәргә булыша. Монда чакырылган эксперттан тиз арада киңәш сорарга, кирәк булганда яңа хезмәткәрне эшкә алырга, җитми торган техниканы табарга, хезмәт күрсәтүләрне яки продукцияне сатарга, хәтта инвестор эзләү турында игълан бирергә дә мөмкин.

– Бу коммуникацияләрдә революция: инде социаль челтәрләрнең таныш функционалына өстәп, кулланучылар физик бәйләнешнең чиксез мөмкинлекләрен ала, мәсәлән, алар дусты яисә хезмәттәшенең кулын кыса, кочаклап исәнләшә ала! – дип безне гаҗәпләндерүен дәвам итә Сергунин. – Гади генә итеп әйткәндә, алар матди дөнья белән аралаша һәм хәтта дистанцион идарә итә ала: махсус манипулятор-җайланма ярдәмендә. Шулай итеп, виртуаль дөнья системасы безне реаль, ләкин ерактагы чынбарлык дөньясына илтә ала. Без аны күреп, ишетеп кенә калмыйча, аңа тиеп-орынып та карый алабыз. Ә, бәлки, тиздән ис тә сизә алырбыз!

– Безнең өчен шунысы мөһим: проектыбызның глобаль максаты – дөньяда «артык кешеләр» җәмгыятен ясалма формалаштыру тенденциясе күзәтелүе шартларында кеше интеллектының кыйммәтен һәм уникальлеген арттыру, – ди аны уйлап табучылар.

– Проектыбызның глобаль максаты – кеше интеллектының кыйммәтен һәм уникальлеген арттыру, – дип аңлатты безгә КФУның Мәгълүмат технологияләре һәм интеллектуаль системалар институты хезмәткәрләре Влада Кугуракова һәм Олег Сергунин.

ЯҢАДАН ЯШӘРГӘ ӨЙРӘНҮ

Руфия Фазылова

Инсульт дигән зәһәр чирнең ни икәненә быел гаиләбезгә үз мисалында инанырга туры килде: әнинең абыйсы өч айдан бирле рәтләнә алмый. Баш мие зарарлану сәбәпле, кеше үзеннән-үзе «яшелчә»гә әйләнә икән. Бик авыр күренеш...

Казан 7 нче шәһәр хастаханәсенең реабилитация үзәгенә баргач, инсультның бик яман чир икәненә янә бер кат инандым. Егерме биш яшьме, кырыкмы, алтмышмы – берәүне дә аямый ул...

РОБОТЛАР ДӘВАЛЫЙ?

7 нче шәһәр хастаханәсенең реабилитация үзәге әле 2022 елда гына ачылган. 12 мең квадрат метр мәйдан биләгән әлеге сигез катлы бинаны бер ел дигәндә сафка бастырганнар. 147 урынга исәпләнгән реабилитация үзәгенә иң заманча медицина җиһазлары урнаштырылган.

Инсульт кичергән авыруларны тернәкләндерү бүлеге дүртенче һәм бишенче катларда урнашкан. Тренажерлар коридордан ук башлана. Мөмкинлеге, теләге булган кеше сәгатьләр буе да шөгыльләнә ала. Ләкин андыйлар сирәк. Күбесе инструкторлар, туганнары ярдәмендә генә йөри, коляскалылар да байтак. Барысы да бирегә зур өмет белән – аякка басарга дип килгән. Әнә шундыйларның берсе – Казанда яшәүче Рифат Мамаев. Җитмеш яшен тутырган ул. Башкалар белән чагыштырганда, аның хәле күпкә яхшы-

Фото: Александр Ефремов

рак – үзе атлап йөри, сөйләмене, кулларына да әллә ни зур зыян килмәгән. (Мондый авырулар биредә күп түгел.)

– 31 майда инсульт кичердем, – диде Рифат абый. – Ике көн алдан беренче билгеләре пәйда булды – аягым томый башлады. Рульдә барганда, машина педаленә басам – аяк тыңламый. Ул көнне көчкә кайтып җиттем. Икенче көнне кулым белән проблемалар башланды – әйтерсең алар минеке түгел. Инде 31 май иртәсендә хәлем тагын да начарланды. Хатыным «Ашыгыч ярдәм» машинасын чакыртты. Тиз арада 7 нче шәһәр хастаханәсенә алып килделәр. Компьютер томографиясе ясадылар. Шунда инсульт диагнозы куйдылар. Аннан соң биредәге нейрореанимация бүлегенә салдылар.

Реанимациядән соң Рифат абыйны 7 нче шәһәр хастаханәсенең неврология бүлегенә яткыралар. Монда баш мие зарарланган (ягъни инсульт булган) кешеләр өчен шундый аерым бүлек бар. Анда тиешле дәвалау курсы узганнан соң, бирегә – реабилитация бүлегенә күчерәләр. Нәтиҗәдә дәвалау курсының икенче этабы башлана.

– Болай эшләү бик әйбәт нәтиҗә бирә, – дип аңлатты Казан 7 нче шәһәр хастаханәсенең үзәк нерв системасында тайпылышлар булган пациентлар өчен реабилитация бүлеге җитәкчесе Эльмира Хөсәенова. –

Инсульт булганнан соң беренче өч айда тернәкләнү узу яхшы.

Бүлек җитәкчесе белән үзәкне карап йөрибез. Кинезиотерапия залы – мөстәкыйль йөри алмаучылар өчен. Биредә күпләр беренче адымнарын ясый. Реабилитация үзәгенең башка бүлекләреннән дә килеп шөгыльләнәләр.

– Каты баш мие җәрәхәте алган авыруларны унынчы-унбишенче көнгә, ә инсульттан соң җиденче-унынчы көнне кинезиотерапия залына алып киләбез, – ди Эльмира Хөсәенова. – Монда йөрәк-кан тамырлары, сулыш алу системаларын ныгыталар.

Гади итеп аңлатканда, кешеләрнең аяк-кулларын робот йөртә. Ә икенче җайланма – экзоскелет авыруларны урыннан торырга, утырырга өйрәтә. Коридор буйлап ясалган махсус рельсларда исә кешеләр янәдән йөрергә өйрәнә.

ЛФК, массаж, логопед, психолог белән шөгыльләнү, инә белән дәвалау – барысы да инсульттан соң тернәкләндерү программасына керә. Шул исәптән төрле препаратлар белән дәвалау да каралган.

– Безнең команда зур, – диде Эльмира Растямовна. – Физик реабилитация медицинасы табиблары, физиотерапевт, невролог, инструктор, психолог, логопед, медицина реабилитациясе буенча шәфкать туташлары – барыбыз да авыруларны аякка бастыру өчен эшлибез.

«ХОЛКЫНА ТҮЗЕП БУЛМЫЙ...»

Инсульт төрле кешегә төрлечә тәэсир итә: берәүләрнең аяк-куллары йөрмәс була, икенчеләрнең – акылына, өченчеләрнең сөйләменә зыян килә. Палаталарның берсендә илле ике яшьлек Сергей ята. Быел гыйнвар аенда аңа инсульт булган. Аяк-куллары йөри, тик менә сөйләшә алмый.

– Алайса сезгә җиңелрәктер, җәмәгатегез үз-үзен йөртә бит, – дим Сергейның хәлен белергә килгән хатынына.

– Юк, – ди ханым. – Сөйләшә алмау да бик зур проблема икән. Ирем нәрсәдер аңлат-

Башкалар белән чагыштырганда, Рифат Мамаевның хәле күпкә яхшырак – үзе атлап йөри, сөйләмене, кулларына да әллә ни зур зыян килмәгән.

– Безнең команда зур, барыбыз да авыруларны аякка бастыру өчен эшлибез, – диде Эльмира Хөсәенова.

сез. Кайчагында алар якыннарына гына түгел, дәвалаучы табибларга карата да дорфалык күрсәтә, шөгыльләнәселәре килми. Бу гаҗәп тә түгел, алар тормышка пессимизм белән карый башлый. Күп вакыт аларны теге яки бу тренажерда эшләргә күндерергә туры килә. Аз гына уңышлары өчен дә мактыйбыз, шул рәвешле күңелләрен үстерәбез.

Еш кына инсульт булган кешенең якынына да психолог ярдәме кирәк икән. Шуның өчен реабилитация үзәгендә алар белән дә эшлиләр. Бу кыенлыкларның вакытлыча икәненә, аларны бергәләп кенә җиңеп булачагына нәкъ менә психологлар инандыра.

Бүлектә күпләргә махсус аппарат ярдәмендә психотест үткәрәләр. Җайланма баш миенә тулы диагностика үткәрергә ярдәм итә. Гомумән, биредәге һәр аппарат, җиһаз турында аерым язарга була. Арада чит илдә эшләнгәннәре дә, үзебездә ясалганнары да бар.

макчы була, ләкин әйтә алмый. Ачуы килгәч, мине этеп-этеп җибәрә. Гыйнвардан бирле гаиләбез күген кара болыт каплады... Хастаханә юлыннан кайтып кергән юк. Өйдә көлеп түгел, елмаеп та сөйләшмибез. Кычкырып эндәшсәк тә, иремнең ачуы килә. Холкы бик үзгәрде... Бик авыр хәл бу.

Тагын икенче бер палатадагы ханымнан да шундый фикер ишеттем: инсульт булганнан соң иренең холкы бозылган. Бөтен нәрсәгә кызып китә, йөзе гел караңгы.

– Мин иремне аңлыйм да, юк та, – диде әлеге ханым. – Илле биш яшендә урын өстенә калды. Биш ай узды инде, һаман үзен үзе йөртә алмый. Җитмәсә, сөйләгән сүзен дә яхшылап аңлап булмый. Миңа да бик авыр, дүрт айдан бирле аны карыйм, административ ял алдым. Бер улыбыз эшләгән акчага көн күрәбез. Ирем шуларны аңларга тиеш тә кебек...

Ни кызганыч, инсульттан соң күпләрнең холкы начар якка үзгәрә. Мондый очракта психологлар авыруның якыннарына сабыр булырга киңәш итә.

Казанның 7 нче шәһәр хастаханәсенең үзәк нерв системасында тайпылышлар булган пациентлар өчен реабилитация бүлегендә эшләүче Ләйсән Зарипова көн саен нәкъ шундый авырулар белән очраша. Логопед, нейропсихолог ул.

– Нейропсихология – фәндә чагыштырмача яшь юнәлеш, – ди Ләйсән Зарипова. – Баш миенең танып-белү процессларын, аның үзенчәлекләрен, мәгълүматны ничек кабул итү сәләтен өйрәнә. Кыскасы, нейропсихологлар баш мие эшчәнлеген җайга салуны максат итеп куя. Пациентларның психоэмоциональ халәте төрлечә була бит. Позитив фикер йөртүчеләр дә бар, төшенкелеккә бирелүчеләр дә байтак. Аларның һәркайсына төрле дәвалау ысуллары кулланабыз. Инсульт бәргән һәр кеше зур стресс кичерә, монысы – бәхәс-

АРТА, ЯШӘРӘ...

Татарстанда ел саен якынча – 16 мең, ә Россия буенча 450 меңгә якын кеше инсульт кичерә. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, XXI гасырда инсульт аеруча киң таралган авыру булачак.

– Үлемгә китерә торган чирләр арасында инсульт икенче урында тора, – дип дәвам итте сүзен Эльмира Хөсәенова. – Инсульт миокард инфарктыннан гына калыша, бу – дөнья статистикасы. Шул исәптән Татарстанда да бу шулай. Инсульт очракларының күбәюе кешенең тормыш тизлеге артуы, аның киеренкелектә яшәве белән бәйле. Шулай ук су һәм һава пычрануы, профессиональ факторларның йогынтысы, алкоголь һәм тәмәке куллану, югары калорияле яки сыйфатсыз ризык белән туклану, аз хәрәкәтләнү дә тәэсир итә. Моңа әле нәселдәнлек тә кушыла.

Реабилитация бүлегенә баргач та гаҗәпкә калдым: арада яшьләр шактый. Шундый авыруларның берсе – егерме биш яшьлек Рафаэль белән сөйләшеп тә тордым. Дүрт ай элек матур гына эшләп йөргәндә егеткә инсульт булган. (Әтисе дә шушы чирдән җиде ел элек дөнья куйган.) Дөрес, палатадагы башка авырулар белән чагыштырганда, аның хәле күпкә әйбәтрәк: аягында йөри, анык сөйләшә. «Реабилитация бик ярдәм итте», – диде ул.

– Ни кызганыч, инсульт яшәрә, – дип сүзгә кушылды Эльмира Хөсәенова. – Соңгы биш еллык статистиканы карасак, авыруларның өчтән бер өлешенә 50 яшь тә тулмаган әле. Янә бер күңелсез сан: яшүсмерләрдә артериаль гипертония өч тапкыр ешрак күзәтелә башлады.

– Әлеге куркыныч чирдән тулысынча дәваланып буламы?

– Тулысынча дәваланып була, дип әйтә алмыйм. Ул күп факторларга бәйле. Инсульт никадәр иртә ачыклануыннан, дәвалауның кайчан башлануыннан, тагын авыруның гомуми

сәламәтлегеннән һәм кешенең яшәү рәвешеннән дә тора. Шулай ук яшькә һәм хроник авыруларга да бәйле. Кыскасы, инсульттан соң төрле кеше төрлечә терәкләнә. Кызганычка, авыруларның күбесе хәтта берничә терәкләндерү курсыннан соң да тулысынча савыкмый. Могҗиза булып, барысы да уңайланган очракта да инсульт кичергән һәр кеше табиб кушканча яшәргә тиеш. Янәдән әлеге куркыныч чир кабатланмасын өчен, профилактика турында даими истә тотарга кирәк.

– Инсультны кисәтү өчен, табиб буларак ниләр эшләргә киңәш итәсез? – дим.

– Иң мөһим чара – беренчел профилактика. Ул дөрес туклану, спорт белән шөгыльләнү, начар гадәтләрдән арыну һәм стрессыз яшәү, җитәрлек йокы һәм ял итү, даими медицина тикшеренүләре... Дөрес яшәү рәвеше, табиб язган даруларны даими рәвештә куллану инсультны булдырмый калырга сәләтле һәм кешегә 8–10 ел өстәмә гомер бирергә мөмкин.

...Реабилитация үзәгеннән чыккач, күңелне сөенеч тә, көенеч тә биләп алды. Сөенеч – мондый заманча үзәкнең башкалада ачылуы һәм аның елына меңәрләгән кешегә аякка басарга ярдәм итәчәге. Көенеч– инсульт авыруларының күбәюе һәм яшәрүе. Саулык – иң зур байлык шул. Биредә аның шулай икәнлегенә янә бер инанасың.



ТАБИБЛАР, ИНСУЛЬТ БУЛГАНМЫ-ЮКМЫ ИКӘНЛЕГЕН ТИКШЕРҮ ӨЧЕН, АМЕРИКАДА АШЫГЫЧ ЯРДӘМ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТЕЛӘ ТОРГАН ТЕСТНЫ ТӘКЪДИМ ИТӘ:

– **Face (йөз, бит)** – кешегә елмаерга кушыгыз. Инсульт булган очракта ул моны эшли алмаячак яки кыек итеп елмаячак.

– **Arms (куллар)** – авыруга кулларын күтәрергә һәм шул килеш 10 секунд тотарга кушыгыз. Инсульт булган очракта кулның берсе төшә яки калтырый башлый.

– **Speech (сөйләм)** – кешедән гап-гади җөмлә әйттерергә кирәк. Инсульт булган очракта аның нәрсә сөйләгәне аңлашылмый башлый.

– **Time (вакыт)** – әгәр алда саналганнарның бер генә симптомы булса да, авыруга тиз арада беренче ярдәм күрсәтергә кирәк.

Иң мөһиме: инсульт вакытында беренче 3–6 сәгать вакыт аралыгында табиб ярдәм күрсәтсә, баш миенә авыр зыян килүдән котыларга мөмкин.

ЭЛЬМИРА ХӨСӘЕНОВАДАН КИҢӘШ:

Иң төп кагыйдә – инсультның беренче билгеләре күренгәннән соң, кеше мөмкин кадәр тизрәк (өч сәгать эчендә) хастаханәгә китерелергә тиеш. Беренче ярдәмне дөрес оештыру мөһим.

КЕШЕ ҮЗЕ ГЕНӘ БУЛМАГАН ОЧРАКТА:

– инсульт дип шикләнгәндә, тиз арада ашыгыч медицина ярдәме чакыртыгыз;

– телефоннан авыру турында кыскача мәгълүматны әйтергә әзерләнегез;

– ашыгыч ярдәм диспетчерына үзегезнең контактларны калдырыгыз;

– табибларны каршы алырга әзер булыгыз;

– пациентка дөрес итеп урнашырга булышыгыз: иң яхшысы – башны бераз күтәртеп янда яту;

– ашыгыч ярдәм көткән арада авырудан хроник чирләре турында сорашыгыз: инсульт симптомнары кайчан барлыкка килгән, нинди препаратлар кабул иткән (бу мәгълүмат табибларның вакытын алмаячак һәм тиз арада карар кабул итәргә мөмкинлек бирәчәк);

– пациентка суларга авыр икән, кыса торган киемнәрен (яка, галстук яки шарф) чишегез, тәрәзәләрне ачыгыз;

– ашыгыч ярдәм көткән арада авыруга һич кенә дә су, ризык бирергә яки аны урыныннан торгызырга ярамый! Аның йоту функциясе бозылган булырга һәм ул тончыгырга мөмкин.

КЕШЕ ҮЗЕ ГЕНӘ БУЛСА:

– инсульт билгеләре нык сизелмәсә, аяк-куллары йөрсә, кеше үз-үзенә беренче ярдәмне күрсәтә ала, ягъни ашыгыч ярдәм чакырырга, туганнардан, күршеләрдән шалтыратып ярдәм сорарга кирәк;

– башны күтәртебрәк горизонталь халәттә ятып ярдәм көтәргә;

– сулыш алырга җайлы булсын өчен, муенны кысып тора торган әйберләрне чишәргә;

– иң мөһим кисәтү – инсультка шигегез бар икән, кадерле вакытны җуймас өчен, тизрәк табибка мөрәҗәгать итегез!

КИЛӘЧӘК КИТАПХАНӘСЕ

Хәзерге цифрлаштыру дәверендә Татарстан Республикасы Милли китапханәсе заманча мәгълүмат системасына актив керә бара һәм асылда бүген үк аның иң мөһим компонентларының берсенә әверелә. Әлбәттә, шул ук вакытта ул үзенең төп бурычын – белем һәм мәдәни мирасны саклаучы ролен үтәвен дәвам итә.

Мәдинә Тимерҗанова,
Айсылу Мансурова

«Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе» дәүләт мәгълүмати системасы 2019 елда эшләп китте. Ул мәгълүмати һәм технологик, белешмә һәм белем бирү сервисларын берләштерә. Шулай итеп, белгечләр раславынча, китапханә һәм белем бирү мохите белән идарә итү өчен уңайлы интерфейс булдырыла һәм төрле чыганакларга шәхсән керә алу мөмкинлеге тәэмин ителә. Бик катлаулы әйтелдеме? «Татарстан» бу мәсьәләне гадиләштерергә һәм IT-технологияләр килгәннән соң республикадагы төп китап саклау урынының ничек үзгәрүен ачыкларга уйлады. Сүзебез күзгә чалынган яңалыклар, новацияләр турында.

БЕРДӘМ КИТАП УКУЧЫ БИЛЕТЫ

Республикадагы 1500 дән артык китапханәнең теләсә кайсына керү мөмкинлеге алу өчен, бүген бер генә китап укучы билеты – шәхси штрих-кодлы бердәм үрнәктәге билет алу да җитә. Сезгә тагын kitap.tatar.ru ның «Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе» порталында шәхси кабинетка керү һәм бушлай Wi-Fi (ул Татарстанның дәүләт һәм муниципаль китапханәләрендә бар) куллану өчен логин белән пароль дә биреләчәк. Нәтиҗәдә Россия Федерациясенең бердәм китапханә фондыннан файдалану мөмкинлеге барлыкка киләчәк.



ТР МӘК ПРОГРАММАСЫН ТОРМЫШКА АШЫРУ ГРАЖДАННАРГА ДӘҮЛӘТ КИТАПХАНӘ ХЕЗМӘТЛӘРЕН КҮРСӘТҮНЕҢ СЫЙФАТЫН КҮТӘРӘ, аерып әйткәндә, читтән торып китапка заказ бирү, заказның үтәлешен контрольдә тоту, интернетта электрон каталог белән танышу мөмкинлегенә юл ача. 2019 елда порталга – 271 642, 2020 елда – 281 238, 2021 елда – 352 772, быелның беренче яртыеллыгында 176 085 кеше кергән. «Китапханәчедән сора» виртуаль белешмә хезмәте аша ел саен кулланучыларның 300 ләп соравына ике дәүләт телендә җавап бирелә.

Фотолар Татарстан Республикасы Милли китапханәсеннән алынды, Даниил Шведов, Регина Штейнберг, Диләрә Шакирова

2022 ЕЛ АХЫРЫНА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ ТЕСТ РЕЖИМЫНДА «РУСЛАН-НЕО» АВТОМАТЛАШТЫРЫЛГАН СИСТЕМАСЫНА КҮЧӘ. Яңартылган автоматлаштырылган система документны каталогта эзләү эшенең тотрыклылыгын, өстәмә модуль кертү юлы белән китапларны онлайн-броньлау мөмкинлеген һәм кулланучыларның стационар компьютердан да, мобиль җайланмадан да эшли алуын көйли торган дизайнны тәэмин итәчәк. Нәтиҗәдә милли китапханәдә укучылар санының артуы көтелә.

ЯДКӘРЛӘР «ЦИФР»ГА КҮЧӘ

2019 елдан башлап, Милли китапханә китап ядкәрләрен, сирәк һәм кыйммәтле басмаларны цифрлы форматка күчерү белән шөгыльләнә*. 2024 елга 1500 документ цифрлаштырылган булырга тиеш. Китап фондын, аеруча аның кыйммәтле өлешен саклап калу – өстенлекле юнәлеш. Заманча техника оптималь җылылык-дымлылык режимын сакларга мөмкинлек бирә, янгын куркынычсызлыгын һәм китапханәнең гомуми иминлеген тәэмин итә. Документларны сканерлау өчен, А0 форматына кадәр төрле басмалар белән эшләргә мөмкинлек бирә һәм беренчел чыганакларның сакланышын максималь дәрәҗәдә тәэмин итә торган автоматик һәм планетар китап сканерлары кулланыла.

ФОНДЛАРГА КЕРҮ ГАДИЛӘШТЕРЕЛӘ

Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү терминаллары укучыларга түбәндәгеләрне эшләргә мөмкинлек бирә:

– китапханәнең ачык фондыннан алынган басмаларны электрон китап укучы билетына мөстәкыйль рәвештә теркәргә һәм аларны кире китапханәгә кайтарырга;

– үз формулярыңны тикшереп һәм бурычларың булу-булмавын белеп торырга;

– китап алганда, каракларга каршы RFID-тамгаларны автомат рәвештә деактивлаштырырга;

– начар күрүчеләр өчен махсус режимда эшләргә (станцияләр терминал белән аралашу һәм китап алу эше барышында укучыларга тавыш белән әйтеп җибәреп ярдәм итә).

ЧИРАТЛАР ЮК

Китап кайтару терминаллары китапларны хәтта укучы билетыннан башка да кире тапшырырга мөмкинлек тудыра. Җайланмаларның өстенлекләре: сыйдырышлыкның зурлыгы, чиратларның кимүе, китапханә мәйданнарын файдалы куллану. Станцияләрнең берсе бинага кергән җирдә урнаштырылган, димәк, укучылар үз вакытларын китапханәнең эш режимына көйләүдән азат ителә.

Китапханәнең электрон каталогына һәм Татарстан Республикасының җыелма электрон китапханә каталогына оператив һәм уңайлы керү мөмкинлеген сенсорлы мәгълүмати киосклар тәэмин итә. Махсус системалар китапларны рөхсәтсез алып чыгуны тикшереп тора һәм уку залларындагы хезмәтләрдән файдаланучыларның саны турында мәгълүмат җыеп бара.

ИНТЕРНЕТ ЯРДӘМ ИТӘ

Китапханәнең барлык биналары да чыбыксыз Wi-Fi системасына тоташ технология кулланып ялганган. Бина үзе исә интернет челтәренә бер үк вакытта бик күп кулланучының уңайлы эшләвен тәэмин итә алырлык чыбыклы-оптик элемтә линияләре белән тоташтырылган. Цифрлы технологияләр китапханәнең коммуникация мөмкинлекләрен киңәйткән, бу исә китап укучылар аудиториясе, социаль партнерлар, әлеге тармактагы хезмәттәшләр, фәнни һәм иҗади берләшмәләр белән хезмәттәшлекне күп тапкыр активлаштырырга, китапханәгә карата уңай мөнәсәбәт булдырырга һәм аны мөмкин кадәр танытырга мөмкинлек бирә. Төрле медиаконтентлы социаль челтәрләр аеруча актив кулланыла торган каналлар исәбендә.

ЦИФРЛЫ МАТУРЛЫК

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең бер эстетик һәм техник үзенчәлеге – кунакларны бинаның үзәк фойесында каршы ала торган яктылыклы-кинетик инсталляция. Ул түшәмнән асылынып торган хәрефләрдән гыйбарәт. Биш язу төренә караган, махсус рәвештә яктыртылган бу хәрефләр түшәм артына яшерелгән катлаулы, бик төгәл чыгырлар ярдәмендә хәрәкәткә китерелә. Хәрефләр алдан язылган сценарий нигезендә билгеле бер рәвештә урнаша һәм аерым бер төскә керә, ә махсус программалар теләсә кайсы катлаулыктагы мавыктыргыч сценарийлар яздырырга мөмкинлек бирә.

*«Цифрлы мәдәният» («Мәдәният» милли проекты) федераль проектының «Мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүләрне цифрлаштыру һәм мәгълүмат кырын формалаштыру» («Цифрлы мәдәният») төбәк проекты кысаларында.



Республика китапханәләренең 1300 дән артык мини-сайтын берләштергән «Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе» порталында китапханәләрнең интерактив картасы тәкъдим ителә, **ВАКЫЙГАЛАРНЫҢ БЕРДӘМ АФИШАСЫ ТӨЗЕЛӘ, Ә «ЭЛЕКТРОН КОЛЛЕКЦИЯЛӘР» БҮЛЕГЕ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ ФОНДЛАРЫННАН СИРӘК ҺӘМ СОЦИАЛЬ ӘҺӘМИЯТКӘ ИЯ БАСМАЛАРНЫҢ ТУЛЫ ТЕКСТЛЫ ТУПЛАНМАСЫНА КЕРҮ МӨМКИНЛЕГЕН ТӘЭМИН ИТӘ.**



УҢАЙЛЫ ДА, МАТУР ДА БУЛСЫН

Ксения Сёмина

Хештеглар һәм зур-зур язулар, экстрим-спорт өчен рампалар, уңайлы кафелар – Татарстан парк һәм скверларында мондый объектлар һәм башкалар... нәкъ менә сезнең социаль челтәрләрдәге фоторәсемнәрегез ярдәмендә барлыкка килә.

«Гаилә белән ял итәргә барган идек, Лаешта бик ошады! Барысы да кеше өчен эшләнгән. Заманча пляж, киенү-чишенү бүлмәсе, бәдрәф, душ – бөтенесе дә көйләнгән, кереп ашап чыгарга да урыннар бар, күләгәле шезлонглар да бушлай... Анапаны хәтерләтә. Монда тагын киләчәкбез әле, анысында – бер атнага. Мондый матурлык өчен рәхмәт!» – интернеттагы ихлас сүзләр, сокланып язылган мондый фикерләр «Кама диңгезе» пляжы турында. Табигый ландшафт белән эшләгәндә, проектлаучылар виртуаль ландшафт – Яндекс.Карта сервисыннан, төгәлрәге, кулланучыларның бу локациягә кагылышлы фотосурәтләреннән файдаланган.

ЧЫН ДИҢГЕЗДӘГЕЧӘ БУЛСЫН

– Яндекс.Карта сервисындагы фотолар нигезендә без бу урында кулланучыга кайсы тарафтан яки нинди объектларны фотога төшерү ошаганын билгелибез. Территорияне тагын да танытырлык һәм популярлаштырырлык яңа фотога төшү урыннары булдырырга тырышабыз, – ди архитектор Лилия Гыйззәтова. Казанның һәм Татарстанның барлык җәмәгать киңлекләре Лилия һәм аның хезмәттәшләре – «Архитектура десанты» бюросы катнашында яңартыла.

Хәзер Лаештагы Кама яры хәтта сезон тәмамланганнан соң да популяр булган чыпчын пляжга әверелгән. Монда төшерелгән бик күп фотоларда – комнан ничектер серле рәвештә чыгып торган көймә, ятьмәләр белән чолгап алынган үзенчәлекле күзәтү мәйданчыгы, «Кама диңгезе» хәрефләре, пергола. Әлеге элементларның урыны җентекләп планлаштырылган, хәтта көн дәвамында аларны куллану ничек үзгәрәчәге дә исәпкә алынган.

– Теге яки бу пространствоның проектын өч үлчәмле SketchUp дизайн программасында сызып чыгабыз. Лаештагы пергола проектын эшләгәндә, мин кояш функциясе ярдәмендә аның ни дәрәҗәдә яхшы күләгә ясавын тикшердем. Күләгә кирәгенчә «куе» килеп чыксын өчен, пергола биеклеген берничә тапкыр алыштырдым, – дип сөйли Лилия.

Фотосурәтләр, комментарий, геолокацияле теглар, кешеләрнең кайсы объектларга ешрак баруы турында язулар – җәмәгать киңлеге проектын әзерләгәндә нәә шундый ачык мәгълүматлар тикшерену нигезенә салына. Шул рәвешле теге яки бу территориягә килүченең портреты, аның ни белән мавыгуы билгеләнә, өстәмә сервислар, инвентарьны прокатка алу пунктлары яки яраткан шөгыльләр өчен махсус урыннар ясау турында карарлар кабул ителә.

Фотолар Анастасия Хатыйпова, tatar-inform.ru, Татарстан Республикасы җәмәгать киңлекләрен үстерү программалары матбугат хезмәтеннән алынды.

КАМСКОЕ МОРЕ
ЛАИШЕВО

КАРУРМАНГА ТӨШКӘН ЯКТЫЛЫК

Куе ябалдашлы имән, юкә, өрәңгеләр арасыннан агач түшәлгән юл сузылган. Сукмаклар урман уртасына кереп китә. Бу яшел лабиринт спортчыларга, эт асраучыларга, шулай ук тукталышка кадәр юлны кыскартырга яратучыларга яхшы таныш. Монда хәтта караңгыда да адашып булмый: юллар яхшы яктыртылган. Җәяүләп йөрергә теләүчеләр өчен дә өстәмә вариант каралган: уйланып бара-бара, гөжләп торган паркның үзәгенә, таш җәелгән киң бульварга килеп чыга аласың.

Бу территориянең – Горки һәм Әмәт урманнары һәм алар арасындагы кечкенә генә буш мәйданның язмышы шактый аяныч була. Шәһәр өчен тиңе булмаган яшел массив 1970 нче еллардан бирле төрле яктан киселә килә, ә аннары интенсив төзелешләр белән кысрыклана. 1990 нчы елларда бу урман куркыныч урынга әйләнә: әйләнә-тирәне төрле маргинал һәм криминал затлар басып ала. Әмма тирә-яктагы микрорайоннар үсә, шуның белән бергә аларда яшәүчеләрнең уңайлы ял зонасына ихтыяҗы да арта. 2014 елда Горки-Әмәт урманы, ниһаять, җирле әһәмияткә ия аеруча саклана торган табигый территория статусын ала. Аның яңарышы әнә шулай башлана. Хәзер паркны, бигрәк тә аның урманлы өлешен, танырлык та түгел.

– Бу урын Родина урамы һәм Җиңү проспекты арасындагы транзит зона буларак кулланылган. Безгә исә кешеләрне үтәли узудан туктатырга, паркны балалар да, өлкәннәр дә вакытларын уңайлы итеп үткәрә алырлык урынга әйләндерергә кирәк иде. Без узып китүчеләр һәм монда килүчеләр агымының ничек бүленүен тикшердек. Аланнарда ял итү зоналарын, әйтик, фонтан, балалар мәйданчыкларын урнаштырдык. Паркның үсемлек һәм хайваннар дөньясы – тере табигатьне өйрәнер өчен искиткеч материал. Моның өчен «Эко-йорт» төзелде, анда балалар өчен дәресләр уздырыла. Социаль челтәрләрдәге контентны тикшереп, без бу территориянең яшүсмерләр арасында популяр икәнлеген аңладык. Шулай итеп велодром пәйда булды, – дип сөйли Лилия Гыйззәтова.

Лилия Горки-Әмәт урманын ныклап өйрәнә. Сукмакларны яктырту өчен, яктырту системасын көйләү проекты кирәк, ә аны төгәл маршрутны билгеләгәндә генә ясап була. Топографик сурәтләрдә тапталган сукмакларны яшеллек каплый. Шуңа күрә Лилия һәм аның хезмәттәшләре GPS-трекерлар белән бөтен урманны йөреп чыга, һәм шул рәвешле аның яңа картасы ясала. Ә Әмәт урманындагы күпләр яраткан чаңгы юлы, яктыртылганнан соң, тагын да популярлашып китә.


ГОРКИНСКО-
ОМЕТЬЕВСКИЙ
ЛЕС



ЧАҢГЫ ЮЛЫ ТӨРЛЕ БУЛА

Һәр проектның үз мантыйгы һәм концепциясе бар. Аккош күлләре территориясен яңарту проектын эшләгәндә, «Архитектура десанты», беренчедән, пляжга таба баручы һәм аннан кире китүче кешеләр агымын аеру, икенче яктан, кулланучыларга урман территориясенә керү мөмкинлеген азайту һәм шул рәвешле җирле флора һәм фаунага антропоген йогынтыны чикләү мәсьәләләренә аеруча зур игътибар бирә. Күл буендагы сукмакларның бер өлеше инде бик күптәннән тапталган була һәм моны проектлаучылар да исәпкә ала. Нәтиҗәдә, зур һәм кече күлләр тоташкан урында өстәмә «урап узу юллары» барлыкка килә.

– Әле күптән түгел генә монда килүчеләр агымын Strava кушымтасы аша күзәтеп бару бик уңайлы иде, бу кушымта ярдәмендә спортчылар үз хәрәкәтләрен һәм шөгыльләнү нәтиҗәләрен исәпкә алып бара. Strava кешеләр санын һәм аларның хәрәкәт траекториясен төсле карта рәвешендә күрсәтә, – ди Лилия Гыйззәтова. – Без мондый картадан Аккош күле буендагы гомуми чаңгы юлын проектлаганда файдаландык, безгә аны профессиональ спортчылар шөгыльләнә торган чаңгы юлыннан аерырга кирәк иде. Профессиональ чаңгы юлы зур булмаган җете кызыл әйләнә рәвешендә, ә гомуми чаңгы юлының төсе тоныграк, анысы зуррак та. Strava кушымтасының өстенлеге шунда: карталар нәкъ менә яшел массивлардагы активлыкны күрсәтә, трекер тотып, әллә ничә чакрым йөрисе юк.

Хәзер Аккош күле буйлап кышын да, җәен дә бик рәхәтләнеп йөреп кайтырга була. Моны паркның интернеттагы фотоларыннан да күрә алабыз. Күлләрне төзекләндергәннән соң барлыкка килгән объектлардан монда килүчеләр актив файдалана. Ләкин, әлбәттә, үзең барып күрү, парк буйлап трекер яки камера белән йөреп, сәфәрең турында цифрлы «бәяләмә» калдыру рәхәтрәк. Кем белә, хәзерге вакытта Татарстандагы чираттагы проектны әзерләүче белгечләргә бәлки нәкъ менә шул җитмидер.



КҮЗЛЕКСЕЗ ҺӘМ КОНТАКТЛЫ ЛИНЗАЛАРСЫЗ!

Күзлектән һәм контактлы линзалардан 15 МИНУТ ЭЧЕНДӘ ҺӘМ МӘҢГЕГӘ КОТЫЛЫП БУЛА!

Казанның «Эксклюзив+» офтальмология клиникасында **ReLEx® SMILE®** технологиясе белән күз күременә лазерлы коррекция ясала.

+ Куркынычсыз
+ Авыртуларсыз
+ Тиз тернәкләнү

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

Бу – күз күременә лазер белән коррекция ясауның беренче һәм бүген организмга иң аз тыкшынулы, сакчыл ысулы.

«Эксклюзив+» клиникасында ReLEx® SMILE® операцияләре 2018 елдан бирле үткәрелә. ReLEx® SMILE® – күз күремен Германиянең Carl Zeiss Meditec компаниясе тарафыннан булдырылган фемтосекундлы лазер ярдәмендә төзәтү технологиясе ул. Әлеге ысулны Вальтер Секундо һәм Маркус Блум җитәкчелегендәге офтальмологлар төркеме эшләгән.

ReLEx® SMILE® технологиясе ярдәмендә ерактан күрмәү һәм миопик астигматизм дәвалана. Коррекция процедурасы тиз, авыртуларсыз уза, организмга минималь дәрәҗәдәге хирургик кагылу белән башкарыла. ReLEx® SMILE® процедурасыннан соң икенче көнне үк пациентлар актив тормышка кайта.

Күз күремен SMILE технологиясе ярдәмендә лазер белән төзәтү өчен шартлар:

- -1,5 тән -10 диоптрияга кадәр ерактан күрмәү (миопия);
- 6 диоптрияга кадәр астигматизм;
- миопия һәм астигматизм бергә күзәтелү.

Күз күремен SMILE технологиясе белән төзәтүнең өстенлекләре:

- ZEISS VisuMax® инновацияле лазеры процедураның төгәллеген, нәтиҗәлелеген һәм алдан фаразлап башкарылуын, димәк, пациент һәм табиб өчен уңайлылыкны тәэмин итә.
- ReLEx® SMILE® операциясе вакытында мөгез катлауның тышкы катламнары LASIK һәм Femto-LASIK операцияләренә караганда 80% ка азрак киселә. Мөгез катлаудагы кечкенә кисем лентикуланы чыгару өчен генә кирәк.
- Күзнең мөгез катлавы юка булган пациентлар өчен дә ярый.
- Операция бер этапта башкарыла.
- Тиз тернәкләнү.
- Актив тормыш рәвеше алып барганда да рөхсәт ителә (контактлы спорт төрләре, авиация һ.б.).

Казанның «Эксклюзив+» клиникасында Россиянең төрле шәһәрләреннән инде 3000 нән артык пациент ReLEx® SMILE®-технологиясе белән лазерлы коррекция ясатты. Клиниканың бай тәҗрибәле һәм үз эшләренең чын осталары булган офтальмологлары пациентларга әйләнә-тирә дөньяның бар матурлыгын күрә алу шатлыгын кайтарырга ярдәм итә.

ReLEx SMILE

NEW

Лазер хирургиясенең соңгы буыны. Күз күремен лазер белән төзәтү операциясе беренче тапкыр мөгез катлау кисәген (flap) формалаштырмыйча гына уздырыла. SMILE мөгез катлауның бөгелешен аның өслегенә зыян китермичә генә үзгәртә, мөгезкатлауның алгы тукымасындагы нерв төеннәре тулысынча саклана. Бу – күз күремен лазер белән төзәтүнең бик сакчыл һәм куркынычсыз ысулы.

2022 елның 31 октябренә кадәр коррекция бәясе – ~~130 000 сум~~ **110 500 сум**
(ике күз өчен)

ОФТАЛЬМОЛОГИЯ
ЭКСКЛЮЗИВ+

+7 (843) 279-70-70
+7 (987) 299-30-03

Казан шәһәре, Космонавтлар ур., 42. https://exclusive-plus.ru

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

Фото «Эксклюзив+» клиникасыннан алынды. РЕКЛАМА

БӨТЕН НӘРСӘНЕ ЭШЛИБЕЗ: 3D ПРИНТЕРДАН АЛЫП АКЫЛЛЫ СПОРТЗАЛГА КАДӘР

Казан авиация технологияләре фәнни тикшеренү институты (КНИАТ) авиация һәм машина төзелеше тармагында әйдәп баручы санала. Аның инновацияле проектлары шактый төрле һәм, заман белән бергә атлап, төрле җитештерүләрне яхшыртырга һәм яңартырга сәләтле.

КНИАТ түбәндәге юнәлешләрдә махсуслаша: салкын штамповкалау, җылытып штамповкалау эшләнмәнең өслеген ныгыту, чистарту һәм эшкәртү, гальванопластика, гальваноөслек сылау, тавыш йота торган панельләр җитештерү, аддитив технологияләр, стандарт булмаган җайланмаларны проектлау, эшләү һәм җитештерү

Фото КНИАТ матбугат үзәгеннән алынды. РЕКЛАМА

һ.б.лар. Институт иң катлаулы бурычларга алына һәм аларны уңышлы башкарып чыга. Биредә, һичшиксез, КНИАТның гендиректор Игорь Ларионов җитәкчелегендәге һөнәри кадрлар составы, шулай ук авиакомплекс буенча Татарстан Президенты ярдәмчесе Равил Зариповның бик зур ярдәме мөһим роль уйный.

АДДИТИВ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР – ПЛАСТИК, МЕТАЛЛ, БЕТОН КЕБЕК МАТЕРИАЛЛАРНЫ КАТЛАМЛАП ӨСТӘҮ ЫСУЛЫ БЕЛӘН ӨЧ ҮЛЧӘМЛЕ ОБЪЕКТ, ДЕТАЛЬ ЯИСӘ ӘЙБЕРЛӘР ҖИТЕШТЕРҮ МЕТОДЫ. МОНДЫЙ ӨЧ ҮЛЧӘМЛЕ, ЯИСӘ 3D-ОБЪЕКТЛАР, 3D-ПРИНТЕР ЯРДӘМЕНДӘ БУЛДЫРЫЛА.

КИЛӘЧӘК 3D ЯКЛЫ

Бүгенге икътисад хәл итәргә тиешле бурычларның берсе – яңа продукция уйлап табуны һәм җитештерүне гадиләштерү һәм арзанайту. Әгәр бөтен җирдә экренләп металлны кысрыклап чыгаручы композицион материаллар югары эксплуатация характеристикаларына ия булса, прототиплаштыруның, ә алга таба җитештерүнең дә тизләгеген арттыруны 3D-басма тәэмин итә алачак. Әлеге ике технологияне берләштерү чыннан да гаять зур перспективалар ача. Нәкъ менә шуңа күрә аддитив технологияләр – институт эшчәнлегенең иң перспективалы юнәлешләреннән берсе.

Бүген Казан институты тарафыннан 700^{0}Ска кадәр индукцияле кызарга сәләтле, филамент урынына гранулалар кулланырга мөмкинлек бирә торган басу җайланмасы эшләнгән. Сәнәгать өчен 3D принтеры уйлап табылган һәм эшләнгән. Әлеге җайланмада катламлап эретү методы ярдәмендә «Fused Deposition Modeling» FDM яисә «Fused Filament Fabrication» FFF модельләштерү технологиясе гамәлгә ашырылган, аның басу зонасы: 1000 мм лы өстәл, басма биеклеге 800 мм. Принтер төрле материалларны кулланырга мөмкинлек бирә, шул исәптән базарда гранулалар формасында (3 мм га кадәр) булган композитларны да. Хәзерге вакытта «Туполев» ГАҖ филиалы – С.П. Горбунов исем. Казан авиация заводы мәнфәгатьләрендә профильләрне бөгә торган станок өчен эре габаритлы пуансоннар бастырылган һәм сынау үтә. Эластик мохиттә алюминий детальләрне штамплау өчен, блокларның полимер формаларын FDM методы белән җитештерү технологияләрен эшкәртү эшләре башкарылган. Хәзерге вакытта электрүткәрүчән пластиктан гальванопластика өчен гибрид детальләр һәм җиһазлар эшләү технологиясе сынала. Ябык сәнәгать камерасын эшләү башкарыла, бу басу эшендә инженер пластигын кулланырга мөмкинлек бирәчәк.

Йомгак ясап, тагын бер мәртәбә КНИАТ тарафыннан эшләнә торган 3D-принтерларның төп көндәшлекле өстенлекләренә басым ясыйк: зур размердагы детальләрне эшли алу, ныклык, искермәү сыйфатлары яхшыртылган азәрүчән инженер композитларын куллана алу мөмкинлеге. Шулай ук филаментка ихтыяҗ юкка чыга, бу импортка бәйлелекне киметә.

Сүз уңаеннан, бүген институт, аддитив проектлар буенча эшләү белән беррәттән, укыту-өйрәтү белән дә шөгыльләнә. Әйтик, «Аддитив технологияләр буенча белгеч» юнәлешенең әзерлек программасы буенча белем бирү эшчәнлегенә лицензия алынган.

ЧҮКЕЧ УРЫНЫНА ПРЕСС

Зур потенциалы булган тагын бер проект – җылыткычлы пресснең сынау үрнәген уйлап табу һәм җитештерү, җылыткычлы штамповка технологиясе буенча фәнни тикшеренү эшләрен башкару.

Пресс авиация һәм машина төзелеше юнәлешендәге предприятиеләр өчен эшләнә һәм искергән механизмнарны, мәсәлән, шул ук чүкечне алыштырырга тиеш. Җайланма титан, алюминий, тутыкмый торган кушылмалардан ясалган детальләрне штамплау өчен каралган.

ТЕЛӘСӘ НИНДИ РЕЛЬЕФ ЯСАУ КӨЧТӘН КИЛӘ

Институт эшчәнлегендә иң мөһим юнәлешләрнең берсе – электролит формалаштыру технологиясе буенча детальләр ясау (гальванопластика). Процесс төрле электролитлардан никельне формага гальваник утыртудан гыйбарәт, алга таба аңардан утырым аерыла һәм катлаулы формадагы юка стеналы күләмле конструкцияләр җитештерүдә киң кулланыла.

Мондый технология өслекнең катлаулы һәм микро-, макрогеометрик рельефын югары төгәллектә яңадан ясарга мөмкинлек бирә, аңа никель утыртыла. Шулай ук өстенлекләр арасында – бер формадан алына торган детальләрнең тәңгәл килүе; җиһазлар һәм җайланмаларның түбән бәяләре.

СЕЗНЕҢ ӨЧЕН БАРЫСЫН ДА УЙЛЫЙ

Казан институты кызыксынулары зонасында авиация һәм сәнәгать кенә түгел, спорт та бар. Дөресрәге, тренировкаларның сыйфатын арттыра торган җиһазлар. Сүз интеллектуаль спорт тренажерын эшләү турында бара.

Нәрсә эшли белә? Акыллы тренажер гәүдәнең антропометриясен исәпкә ала һәм истә калдыра, шәхси smart-картаны урнаштырганда автомат рәвештә көйләнә. Тренировка программаларын ясалма интеллект эшли һәм аны күзәтеп тора.

Интеллектуаль тренажер ерактан торып процесска профессиональ тренерларны, медикларны кушарга һәм аерым бер кешенең, шулай ук тулы бер команданың үсеш статистикасын алып барырга, шулай ук тренировкалар программасын көйләргә мөмкинлек бирә. Бер генә картага ия булып та кулланучы бердәм челтәргә кушылган теләсә кайсы залда яисә тренажерда шәхси тренировка программасын кертә һәм күнегүләрне туктап калган урыннан дәвам итә ала.

Глобаль челтәргә, сенсор һәм видеокамералар сыйфатында кире элемтәгә ия булып, дөнья чемпионатларын, клуб ярышларын яисә дөнья рекордларын теркәүне карарга була.

КНИАТ проектлары илнең сәнәгать куәтен арттыруга, тормышка яңа технологияләр кертүгә юнәлдерелгән. Институт кызыксынган компанияләр белән хезмәттәшлеккә әзер, яңа партнер һәи фикердәшләр белән аралашуга шат.

ИМИНЛЕК КАПКАСЫ

Төнге каравылчы – акча өчен йоклый торган профессионал ул, диләр халыкта. Ә менә нейрочелтәр йокламый.

Күз алдыгызга китерегез: административ бинаның буш залы. Кереп килүче кунак як-ягына карана да, беркемне дә күрмичә, рам аша уза. Сигнал яңгырый һәм рамнан соң көйләнгән турникет ябыла. Диспетчер бүлмәсеннән куркынычсызлык хезмәте белгечләре чыга. Алар кунак кешегә детекторның аның портфелендә бинага алып керү тыелган әйберне күреп алганлыгын аңлата, ул әйберне күрсәтергә кирәклеген сорый. Шул ук сигналны полиция бүлегендә кизү торучы да кабул итә. Бинадагы сак хезмәте аларга наряд чакырту ихтыяҗы бармы-юкмы икәнлеген хәбәр итәргә тиеш.

ДЕТЕКТОР БАРЫСЫН ДА ХӘТЕРЛИ

Төп шөгыльләре тикшереп кертү аркалары, беренчел тикшерү һәм җир асты металл эзләгечләре ясау булган «Метаскан» компаниясендә хәзер нәкъ менә шундый куркынычсызлык системасын эшләү белән мәшгульләр. «Метаскан» җайланмалары белән бөтен Россия буйлап меңләгән мәктәп, бакчалар, хастаханәләр, хакимият биналары, полиция бүлекчәләре, суд һәм башка учреждениеләр җиһазландырылган. Җайланмаларны уртак челтәргә берләштерү – компания технологияләре эволюциясенең чираттагы адымы.

– Хокук бозуларны булдырмый калу һәм җинаятьчелекнең кимүе – мондый системаларны кулланышка кертүнең ап-ачык нәтиҗәсе. Өстәвенә, Татарстанның эре шәһәрләрендә тышкы видеокүзәтү челтәре бар инде, – ди «Метаскан»ның баш конструкторы, Идел буе дәүләт технология университеты (Мари Эл) доценты Алексей Фоминых. – Киләсе адым – рамлы металл детекторларның челтәрле эш принцибын кертү. Ә беренчел төп максат – оператор бер пульт аша барлык җайланмаларның эшен күрә алсын, әйтик, пуш-хәбәрләр яки сигналлар кабул итсен һәм детекторларны тиз арада кабызу мөмкинлегенә ия булсын. Сер түгел, кайбер сак хезмәтләре вәкилләре рамның гел хәвеф сигналы биреп торуыннан арый һәм аны челтәрдән аерып куя.

БОЛЫТ ХЕЗМӘТЕ

Җыелган мәгълүматны бергә туплау өчен, компания болыт сервисын эшләтеп җибәрә. Килгән кешенең йөзе, рам аша узу вакыты, үзе белән алып кергән металл әйберләре, тән температурасы – һәрбер кунак турында бу мәгълүматны рам җыя һәм системага җибәрә ала. «Метаскан» теләсә нинди детектор, шул исәптән стандарт булмаган зурлыктагы, 10 метр ераклыктагы кешеләр төркеменең йөзләрен һәм тән температурасын тану функциясенә ия детекторлар ясауга заказны оператив рәвештә үти ала. Казан дәүләт энергетика университетында нәкъ әнә шундый иминлек «кысалары» урнаштырылган да.

КУРКЫНЫЧСЫЗ ҖИР

«Метаскан» җитештерә торган җир асты металл эзләгечләренең дә иминлекне кайгыртканнары бар. 2019 елда Алексей Фоминых Федераль куркынычсызлык хезмәте вәкилләре соравы буенча 7 см га кадәр тирәнлектәге грунтта авырлыгы 0,15 г нан зуррак объектларны билгели ала торган металл эзләгеч ясаган. Җайланмалар Росгвардия һәм РФ Кораллы көчләренең Халыкара минага каршы үзәге арсеналларына кертелгән. Бу металл эзләгечләр бик җыйнак, су үткәрми (30 м тирәнлеккә кадәр), көйләве һәм кулланылышы бик җиңел. Хәзерге вакытта «Метаскан» металл эзләгечләре хәрби хәрәкәтләр узган урыннарда МОН, «Клэймор» һәм башка типтагы миналарны, шулай ук тарттырып куела торганнарын да ачыклау өчен кулланыла.

– Анда иң кечкенә хата да фаҗигагә китерергә мөмкин. Безнең технологияләр мондый афәтләрне булдырмас өчен хезмәт итә. Территорияне куркынычсызландырырга булышу – безнең өчен мөһим һәм бик җаваплы миссия, – ди Алексей Фоминых.

METASCAN
metascan-md.com
тел. 8 800 444-00-27
info@metascan-md.com
grunt. metascan-md.com

Фотолар «Метаскан» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

150 ел элек хуҗабикәләр керне **ничек** юган

Туристлар Татарстанда **нинди** ханымнарны эзли

Узган гасыр студентлары сөйгәннәренә **нәрсәләр** бүләк иткән

«Кара пулат» легендасы **кайда** җанлана

Иң уңышлы гаилә **кайда** яши

СЕНТЯБРЬДӘ СЕЗНЕ КӨТКӘН ТОП-15 УРЫН

1 «ИСКЕ КАЗАН»

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАРСТАНЫНЫҢ СОҢГЫ БАШКАЛАСЫ УРНАШКАН УРЫНДАГЫ ТАРИХИ-МӘДӘНИ ҺӘМ ТАБИГАТЬ МУЗЕЙ-ТЫЮЛЫГЫ

НӘРСӘ КАРАРГА

Борынгы шәһәрлек, кирмән (реконструкция), чын гунн казаны (V-VI гасырлар) һәм казыну эшләре вакытында табылган башка ядкәрләр. Биредә арбалеттан атып карарга, изге чыгыш суын эчәргә, мастер-класста үз кулларың белән түбәтәй тегеп карарга була.

Биектау районы, Камай авылы

2 «КЫРГЫЙ ФЕРМА» ЭКОПАРКЫ

ТЕЛӘКЛӘР КАБУЛ БУЛА ТОРГАН УРЫН

НӘРСӘ КАРАРГА

Биредә тимгелле болан һәм маралларны күрергә, аларны сыйпарга һәм ашатырга мөмкин. Кызыксынучан һәм аралашудан куркып тормый торган тимгелле боланнар үз вольерларында яши. Балалар, хәер өлкәннәр дә, сәгатьләр буе аларның борыннарын, сыртларын сыйпап тора ала. Урманда болан очрату – байлыкка, ә аның мөгезендәге тармак очларын күрү үзеңнең икенче яртыңны табуга, диләр. Шуңа күрә теләкләрне чынга ашыру вакыты җитте!

Балык Бистәсе районы, Шомбыт авылы

3 ДЕНДРАРИЙ

ИДЕЛ-ЧУЛМАН ДӘҮЛӘТ ТАБИГАТЬ БИОСФЕРА ТЫЮЛЫГЫ

НӘРСӘ КАРАРГА

Гасырлык тарихка ия дендрарийда япон сакурасына, Маака Ерак Көнчыгыш шомырт агачына, Көнчыгыш Европаның иң борынгы наратларына һәм тагын 500 төрле агач һәм куакка карап сокланырга мөмкин. Икеөч сәгать эчендә сез Европа, Азия һәм Америка буйлап сәяхәт кыла аласыз.

Яшел Үзән районы, Садовый бистәсе, Вехов ур., 1.

ТАТАР АВЫЛЫ

ЭТНОГРАФИК ТАТАР АВЫЛЫ – АЧЫК ҺАВАДАГЫ МУЗЕЙ

НӘРСӘ КАРАРГА

Безнең көннәргә кадәр сакланып калган чын тегермәнне. Әгәр туры килсә, он тарттыру процессын күрә аласыз, чөнки тегермән әле бүген дә эшли. Вакыт галиҗәнаплары буенча сәяхәт кылып була: йөз ел элек салынган, мунча-сарайлары һәм көнкүреш кирәк-яраклары белән сакланган татар утарларын күрергә мөмкин. Татар миче рус миченнән нәрсәсе белән аерылып торуы һәм татар авылларында ни өчен тимерчеләрнең булмавы турында ишетә аласыз.

Яшел Үзән районы, Исәк авылы, Кыр ур., 40

4

5 ПОРТОМОЙНЯ

АК ТАШТАН САЛЫНГАН БОРЫНГЫ БИНАДА УРНАШКАН XIX ГАСЫР ҖӘМӘГАТЬ КЕР ЮУ ЙОРТЫ. УНИКАЛЬ МУЗЕЙ, ИЛДӘ БЕРДӘНБЕР

НӘРСӘ КАРАРГА

Бернинди күчерелмәләре дә булмаган экспозицияне. Могҗиза белән сакланып калган бинада провинциаль Алабуганың шәһәр кер юу йорты тулысынча торгызылган. 150 ел элек хуҗабикәләрнең керне ни рәвешле юулары турында белерсез. Чын чуен мич, агач торбалар, чаннар, 19 гасыр сүткәргеч торбалары, күптән онытылган көнкүреш кирәк-яраклары... – искиткеч тәэсирләр!

Алабуга ш., Кече Покров ур., 9

Фотолар: tatar-inform.ru, Л.Пахомова/elabuga.com, «Татарстан» журналы архивы, kazan.eparhia.ru, К.Васильевның «Зәя» картинасы

6

ТУ-144

ЛАЙНЕР БАЗАСЫНДА ОЕШТЫРЫЛГАН ИНТЕРАКТИВ ТЕХНИКА МУЗЕЕ

НӘРСӘ КАРАРГА

Дөньяда тавыш тизлегеннән дә югарырак тизлектә очучы беренче пассажир самолеты – совет авиатөзелешенең горурлыгы. Казандагы раритет – дөньяда сакланып калган өч Ту-144 самолетының берсе. Очкычта пилот кабинасы тулысынча реставрацияләнгән, идарә системасы торгызылган. Виртуаль чынбарлык технологиясе ярдәмендә үзеңне тавыш тизлегеннән югарырак тизлектә очарга сәләтле легендар очкычның чын пилоты итеп тоярга мөмкин. Дөрес, уңыш елмайса гына – бүгенгә кадәр бик азларга гына самолетның эченә үтәргә рөхсәт бар...

Казан ш., Четаев ур.,18а

СЕБЕР ТРАКТЫ ТАРИХЫ МУЗЕЕ

КАРАДУГАН СӘҮДӘГӘРЕ МОРТАЗА БАЙНЫҢ ЭЛЕККЕГЕ ЙОРТЫ

7

НӘРСӘ КАРАРГА

Музей экспозициясен. Сез богауларын сөйрәп сөргенгә атлаган декабрист һәм революционерлар, илнең иң акыллы затлары һәм иң явыз җинаятьчеләре язмышына бәйле атаклы тракт тарихы турында ишетерсез. Безнең көннәргә кадәр куну йорты ишегалды сакланып калган, экспонатлар арасында – 19 гасырда ямчылар кигән кием, ат дирбияләре, ул заман сигналлары – элемтә атлары экипажларына гына тагарга рөхсәт ителгән кыңгыраулар...

Балтач районы, Карадуган авылы



8

ЮРЬЕВ МӘГАРӘСЕ

БОГОРОДСК ТАУЛАРЫ, ТАБИГАТЬ ҺӘЙКӘЛЕ

НӘРСӘ КАРАРГА

Җир асты заллары, гротлар, сталактитлар һәм сталагмитлар. Мәгарә башында – Көмеш һәм Бабуиннар залы, анда баскан килеш йөрергә була. Алга таба – авыррак, Куркынычлар залына, мөгаен, иң кыюлар гына җитә аладыр... Урта Идел буенең иң озын мәгарәсен карап чыгып булмастыр – аның тикшерелгән мәйданы 3500 квадрат метрны мәшкил итә. Әмма җир астына әзерлекле туристларга, иң яхшысы тәҗрибәле профессионаллар җитәкчелегендә төшәргә кирәк – экстрим да куркынычсыз булырга тиеш.

Кама Тамагы районы, Тенеш бистәсе



9

БОГОЯВЛЕНИЕ СОБОРЫНЫҢ ЧАҢ МАНАРАСЫ

КАРАУ МӘЙДАНЧЫГЫ

НӘРСӘ КАРАРГА

Казанның борынгы өлешен тулысынча – Кремльдән алып Иделгә кадәр. Манараның биеклеге – 74 метр, шуңа күрә каршыгызда гаҗәеп манзара ачылачак, фотога төшеп, кабатланмас тәэсирләр дә алырсыз. XIX гасыр ахырында шәһәр өстеннән күтәрелгән манара башкалабызны 125 елдан артык бизәп тора. Карау мәйданчыгына менгәндә чаңнарга карап сокланырга була – монда алар 14.

Казан, Бауман ур., 78

ӘҖЕМ МӘЧЕТЕ

МАНАРАСЫ ҺӘМ НАМАЗ ЗАЛЫ

10



НӘРСӘ КАРАРГА

Гаҗәеп матур манара шәһәр өстеннән 51 метрга күтәрелгән. Менә инде 130 елдан артык үзенең нәзакәтле купшылыгы белән сокландырып тора. Көнчыгыш әкиятләрен хәтерләткән мәчетне карагында, намаз залына да керегез, әлбәттә инде, бусагада аяк киемегезне салып калдырырга онытмагыз (кагыйдәләр шундый). Аның бизәлеше – тыйнаклык һәм зәвык үрнәге.

Казан, Фәткуллин ур.,15

11

КОНСТАНТИН ВАСИЛЬЕВ МУЗЕЕ

КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ

НӘРСӘ КАРАРГА

Даһи рәссамның кыска гына гомере эчендә иҗат иткән шәп картиналарын. Кызганыч, Константин Васильевның исеме үзе үлгәннән соң гына ишетелә башлый. Үзе исән чакта аның иҗаты рәсми хакимиятләр тарафыннан танылмый. Музейда рәссамның үзе исән вакытта замандашларына һәм яшь буынга атап язылган мөрәҗәгате саклана: «Әгәр минем картиналарым Ватаныма кирәк булмаса, бөтен иҗатымны юк дип санарга була». Вакыт, бәхеткә, барысын да үз урынына куйды.

Казан, Бауман ур., 29/11

12 АЛПАВЫТ ПЕРЦОВЛАР УТАРЫ

ИЗГЕ ЧЫГЫШ ҺӘМ ПЕТРОПАВЛОВСК ЧИРКӘВЕ

НӘРСӘ КАРАРГА

Нарат урманы эчендә урнашкан утарны – Пушкин, Боратынский, Лев Толстойлар белән аралашкан алпавыт Перцовларның нигезен. Риваять буенча, утарга нигез салган Перцов биредәге чыгыштан су эчкәннән соң чирен җиңә һәм мәңгелеккә бу якларга гашыйк була. Соңрак, 1830 елда, ул Хотняда таштан зур чиркәү – Франциянең Ницце шәһәрендәге Никольск чиркәвенең төгәл күчермәсен салдыра. Гыйбадәтханәне Петропавловск чиркәве дип атыйлар. Чиркәү безнең көннәргә кадәр сакланып калган, гәрчә 1970 елдагы янгыннан зыян күрсә дә. Чиркәүне караганнан соң, чыгыш суын татып карарга онытмагыз – аның суы изге санала, чирләрне дәвалый, суга дип хәтта күрше төбәкләрдән дә киләләр. Изге чыгыш янында «Хотнинская» табигый суын савытларга тутыру цехы төзелгән.

Арча районы, Хотня авылы

МӨХӘММӘТГАРИФ МУЛЛА УТАРЫ

13

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ МЕМОРИАЛЬ МУЗЕЙ КОМПЛЕКСЫ ҺӘМ ТУКАЕВЛАР ГАИЛӘСЕ МУЗЕЙ-ЙОРТЫ

НӘРСӘ КАРАРГА

Кушлавыч авылында Мөхәммәтгариф мулла утарын, анда бөек татар шагыйренең туган нигезе мохите торгызылган. Көнкүреш кирәк-яраклары, бүген дә эшли торган мич, Тукайның әнисенең шәхси әйберләре... – болар барысы да сезгә унтугызынчы гасыр татар гаиләсенең яшәү рәвешен күзалларга ярдәм итәр. Тукайга илһам биргән якларның тыйнак гүзәллеге белән хозурланыгыз, шагыйрь йөргән Изге чишмә суын татып карагыз. Ә аннан соң Яңа Кырлайга юл тотыгыз: Тукай иҗатына багышланган экспозиция белән танышыгыз, «Шүрәле» поэмасында сурәтләнгән искиткеч табигатькә, шагыйрь «хәтта тавыклары җырлай» дип язган авыл манзараларына сокланыгыз.

Арча районы, Кушлавыч авылы



14 ЧУЛМАН ЯРЫНДАГЫ СЕМРУК

МӘДӘНИ-РЕКРЕАЦИЯ КЛАСТЕРЫ

НӘРСӘ КАРАРГА

Семрукны саклаячаклар һәм төзекләндерәчәкләр. Халык арасында күбрәк «Семрук» дип аталган «Ак таулар» Лаеш мәдәни-рекреация кластеры Бөтенроссия кече шәһәрләр конкурсында 70 миллион сумлык грант откан. Бу «Зөләйха күзләрен ача» сериалын төшерү өчен ясалган кинодекорацияләр озак еллар дәвамында Лаеш халкын һәм килгән кунакларны шатландырып торачак дигән сүз. Район башлыгы Илдус Зарипов әлеге якларның гүзәл табигатькә һәм бай тарихка ия булуына бер генә мәртәбә басым ясамады. «Бездә Чулман елгасы, матур урманнар, кыр-болыннар бар. Биредә традицияләр, мәдәният сөюче халык яши. Без оештырылган, тәртипкә салынган туризм, куркынычсыз һәм чисталыкны саклап ял итү яклы».

Лаеш шәһәре

СӘҮДӘГӘРЛӘР ШӘҺӘРЕ 15

БАЙ ӘДӘБИ МИРАСЛЫ

НӘРСӘ КАРАРГА

Тарихи үзәктә сакланып калган XIX гасыр башы сәүдәгәр утарлары, храмнар, җәмәгать биналарына сокланмый мөмкин түгел – Чистайда 140 тан артык мәдәни мирас объекты санала! Борис Пастернакның Россиядә беренче Мемориаль музеена керми калмагыз, уникаль сәүдәгәр утарында урнашкан Шәһәр тарихы музеен урап узмагыз. Гаяз Исхакый Тарихи-мемориаль һәм этнография музеена сугылыгыз. Музей сувенир салонына кереп, истәлеккә кулдан эшләнгән берәр сувенир алыгыз һәм елга ярында урнашкан әлеге шәһәрне фотога төшерергә онытмагыз.

Экскурсиягә түбәндәгечә заказ бирергә була:

– туристлык-мәгълүмат үзәге телефоннарына шалтыратып: 8 (84342) 5-17-01, 5-11-00

– электрон почта аша: gorodnakame2012@mail.ru

– адрес буенча: 422980, Татарстан Республикасы, Чистай ш., Карл Маркс ур., 31.

Сайт: www.chisto-muzei.ru

Фотолар: Максим Новиков, Арча районы администрациясе, tatar-inform.ru РЕКЛАМА



КУКМАРА КИЕЗ ИТЕКЛӘРЕ:
СӨЕП ҺӘМ КАЙГЫРТЫП...

КУКМОРСКИЕ ВАЛЕНКИ

«Кукмара киез итекләре» – киез итекләр һәм 100% сарык йоныннан юеш ысул белән басылган киез аяк киемнәре җитештерә торган зур комбинат.

Фирма кибетләрендә һәм сайтта «Кукмара киез итекләре» продукциясен киң ассортиментта сатып алырга мөмкин:

КИЕЗ ИТЕКЛӘР, КУНЫЧЛЫ ИТЕК, БОТИНКА, ЧУНИ, БАШМАК, КРОССОВКА, ОДЕЯЛЛАР
һ.б.лар.

Күмәртәләп сату бүлеге:
e-mail: opt@kvvk.org
Телефоннар: (84364) 2-08-31,
8-800-250-11-32

Интернет-кибет:
магазин-валенок.рф

Фирма кибете.
Адресы:
Кукмара ш., Вахитов ур., 1.
Телефон: (84364) 2-08-78

«Кукмара киез итек-киез комбинаты» АҖ, Кукмара ш., Вахитов ур., 1. ОГРН 1021607752396

Фотолар «Кукмара киез итек-киез комбинаты» АҖ тарафыннан бирелде. РЕКЛАМА

PRESSA

ТАРТЫЛУ КӨЧЕ

Туристлар ник Татарстанга тартыла? Нигә монда кабат-кабат әйләнеп кайта? Алар биредә ни эзли?

– Берәр хатын-кыз эзлим, – дип турысын әйтә Санкт-Петербургтан килгән туй фотографы Андрей Мигунов. – Мин чынлап әйтәм. Монда төрле чорларга караган, бу як өчен ниндидер күркәм эшләр башкарган хатын-кызлар турында матур легендалар шулкадәр күп ки, мин аларны, дөресрәге, шул хатын-кызлар турында тарихны туплый башладым. Аннары дусларыма сөйлим, һәм алар да минем кебек үк кызыксынып китә – үз күзләре белән күрү, үз колаклары белән ишетү өчен, Казан якларына юлга кузгала.

Фото: Александр Ефремов



СТУДЕНТНЫҢ ТУЙ БҮЛӘГЕ

Казанда туристларны бер серле ханымның олы, әмма кыска гомерле мәхәббәте турында бик кызыклы бәян көтә. Ул мәхәббәт әлеге ханымны Казанның иң матур йортына алып килә. Бу йортны исә, аның йөрәген яулау өчен, 25 яшьлек Казан студенты Алексей Ушков төзетә.

БЕРАЗ ЭКСКУРСИЯ ТУРЫНДА

– Бу экскурсия түгел, ә алтын гасырга, бөтендөнья сугышының да, революциянең дә әле исе дә килмәгән гаҗәеп чорга сәяхәт, – дип сөйли Казанның матур үткәненә һәм Зинаида Ушкова тарихына премиум-тур авторы Эдуард Хәйруллин. – Бу сәнәгать һәм сәнгать гөрләп үскән искиткеч вакыт була. Казан үзәгендәге һәр йорт, Ушкова өе белән бераз гына булса да тиңләшә алу өчен, үзгәрергә тырыша. Воскресенская, Зур Проломная кебек үзәк урамнарда гадәти йортларны яңадан үзгәртеп төзиләр, хуҗалары аларны бераз патша сараена да, бераз борынгы замокка да охшатырга тели... Гасыр башындагы мондый үзгәрешләрнең кайбер нәтиҗәләре безнең заманга кадәр сакланып калган. Бу – тарихның бик кечкенә бер кисәге генә, ул чакта Казан да үзгәрә, ил дә матурлана. Нәкъ менә Ушкова йорты боларның барысын да мөмкин кадәр ныграк сеңдергән, чөнки хуҗаның үзгәртеп коруга акчасы була, аны архитектура дизайнының соңгы яңалыклары кызыксындыра. Йортны төзетергә ул иң талантлы, могҗиза тудырырга сәләтле архитекторны сайлый. Йорт 1906 елда төзелә һәм бүгенгәчә яхшы сакланган – обойлары, паркеты, витражлары борынгы, Алабугада эшләнгән керәч плитәләрдә хәзер дә тыпырдап биергә мөмкин. Биредә революциягә кадәрге – вакыт җилләре тарих төпкелләренә алып киткән Россиянең барлык матурлыгы тупланган. Шуңа күрә минем экскурсия әнә шул чорга чуму ул. Бу экскурсия ул вакытны кире кайтара кебек. Ушкова йортына экскурсияләр уздырган ел ярым вакыт эчендә зур тикшеренү эшләре башкарылды – эш күләме узган йөз ел эчендә эшләнгәннән дә күбрәк булды. Әлеге йорт, әлеге гаилә турында күпме хатирә барланды. Мәһабәт бинаны шул чор предметлары белән тулыландырдык. Кешеләргә күрсәтер өчен экспозициягә куярлык кайбер әйберләрне әлеге нәселнең дәвамчыларыннан сатып ала алдым.



1

Банан пальмасы төбендә затлы рояль уйнап торган грот-залда Зинаида Ушкова концертлар һәм шигъри кичәләр оештыра.



2

Халык телендә «Тортик со сливками» дип йөртелгән балкон.

3

Бу залда Ушковлар Казан бомонды өчен баллар оештыра. Ушковлар йортында уңайлыклар да югары дәрәҗәдә була.



Шуңа күрә бу гадәти экскурсия генә түгел, ә искиткеч үткәнебезгә премиум-тур булып чыкты, монда барысын да капшап, тотып, тәмен татып карарга, виртуаль чынбарлыкка чумарга мөмкин. Бераз балет, тере музыка, шампан шәрабе, бакча җиләге – һәр экскурсиядә нинди дер бер вакыйга, хәрәкәт була – шул мохиткә чумып, без бу йортка аның асыл максатын кайтарабыз. Ул мәхәббәт хакына һәм мәхәббәт өчен төзелгән. Аны хуҗасы да ярата, төзелеш вакытында архитектор да ихлас сөя башлый, чибәр Зиночка исә әүвәл әкияти матур йортка, аннары аның хуҗасына гашыйк була. Бу йорт әлегәчә сөю белән сугарылган. Моны экскурсиягә килүчеләр дә тоя дип уйлыйм.

БЕРАЗ СӨЮ ТУРЫНДА

Алексей Ушков әтисе һәм бабасының бай варисы санала. Ул Казан университеты профессорының кызы Зинаида Высоцкаяга гашыйк була, тик кыз егетне хәтта күрми дә. Ул вакытта кияү булырга тиешле ир-егетләр исемлегендә төп урынны ат үрчетү белән шөгыльләнүче танылган дворян Малютин били.

Әмма мәхәббәт могҗизалар кылырга сәләтле, сөю хакына иң юләр гамәлләр башкарыла. Риваятькә караганда, Ушков, гаҗәеп сер һәм табышмаклар белән тулы искиткеч йорт төзеп, Зиночкасын тәмам әсир итәргә ниятли. Казанның ул чордагы иң күренекле архитекторы Карл Мюфке ярдәмендә йортны салып та куялар. Мюфкегә экономия турында бөтенләй уйламаска һәм ул вакытның иң модалы архитектура стильләрен кулланырга кушыла. Яңа төзелгән йортка иң беренче булып аяк басу бәхетен татыган Зиночка хәйран кала. Бер бүлмәдән икенчесенә күчкәндә, ул соклануын һәм гаҗәпләнүен яшерми. Туташ Малютинны йөрәгеннән алып ата, ә Воскресенская урамындагы йорт студент Ушковның туй бүләгенә әйләнә. Ушков гүзәл кәләшенең исемен Казан тарихында һәм йорт фасадында мәңгеләштереп язып куя – бинаны «ЗУ» хәрефләре сырланган бормалы монограмма белән бизи. Югыйсә Зинаида Высоцкая фамилиясен алмаштырырга ризалык бирергә уйламаган да була эле. Тик мондый бүләк каршында «юк» диярга мөмкинме соң?!

4 Кайчандыр Зиночка Высоцкаяны хәйран калдырган деталь һәм бизәкләрне Эдуард Хәйруллин фонарь белән яктыртып күрсәтә.

БЕРАЗ ЙОРТ ТУРЫНДА

Мөгаен, Казанның безнең көннәргә кадәр беренчел рәвешендә сакланып калган иң затлы йортыдыр ул. Акчаны немецларча бәрәкәтле тотарга яраткан Карл Мюфке гомерендә беренче тапкыр үзен заказчы малын уңга-сулга туздыручы итеп тойгандыр. Монда ул төрле – ампир, модерн, готика, рококоны, япон, Мавритания өслүбләрен моңарчы күз алдына да китереп булмаганча катнаштыра. Витражларны Париждан алып кайталар, мәрмәр идәндәге ирисләр ярымкыйммәтле ташлардан ясала, баскыч Казанда күз күрмәгән, колак ишетмәгән агачлар – Африка тамарискы һәм япон сакурасыннан эшләнә, тәрәзәләр һәм ишекләр өчен бронза тоткалар Кытайда коела, балкон һәм капкаларның рәшәткәләре Санкт-Петербургта чүкеп ясала, ә түшәмдә япон гейшасы образында яшь хуҗабикәнең йөзе сурәтләнә... Һәм һәркайда – ниндидер вензельләр, сюрпризлар, шифрланган хатлар һәм табышмаклар. Аларның күбесен хәзерге заман белгечләре генә чишә, әйтик, Кытай иероглифлары рәвешендә рус хәрефләре белән язылган архитектор автографы шундыйлардан.

СҮРЕЛГӘН СӨЮ ТУРЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ

Әкияти йортта тормыш гөрләп тора – Зиночка үзенең дә, өенең дә игътибар үзәгендә булуын ярата. Банан пальмасы төбендә затлы рояль уйнап торган грот-залда ул концертлар, шигъри кичәләр оештыра – әлеге зал гаҗәеп акустикага ия була.

Әмма экияти йорттагы Алексей белән Зинаиданың мәхәббәте шактый тиз сүрелә. Алексей үзенә хыянәт итүдә шикләнеп хатыны белән аерылыша һәм Мәскәүгә китеп бара. Анда исә Ушков, озак уйлап тормыйча, Зур театрның прима-балеринасы Александра Балашовага өйләнә. Һәм аның өчен «Пречистенка урамы, 20 нче йорт» адреслы нәкъ шундый ук йорт салдыра.

Элекке иренең мондый кыланышы Зинаиданың җанына тия. Ул Мәскәүгә юл тота һәм күршедә генә бер йорт сатып ала. Тарихта күршеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең нечкәлекләре турында мәгълүмат сакланмаган, өстәвенә, инкыйлаб давылы куба, һәм Ушков яңа хатыны белән Парижга күчеп китә.

Эдуард Хәйруллин Казандагы атаклы йортның хуҗабикәсе элекке ире артыннан Парижга китмәгән, дип саный. Ул, мөгаен, кабат кияүгә чыккандыр, бай ханымның каберен Хәйруллин Мәскәүнең Новодевичье зиратында эти-әнисе Мария Васильевна һәм Николай Федорович Высоцкийларның каберләре янәшәсендә таба. Стелага Зинаиданың фотосурәте төшерелгән һәм «Зинаида Николаевна Руднева» дип язылган. Үлем көне – 1929 елның 29 июле.

БЕРАЗ РӘХМӘТ СҮЗЕ

1918 елның августында Воскресенская урамындагы (хәзер Кремль урамы) мәһабәт йортны ак чехлар басып ала. Кызыллар Казанны азат иткәч, йортка татар-башкорт бригадасы урнаша. Биредә китапханә урнаштырырга тәкъдим итеп, бинаны «квартирантлардан» коткарган дөнья пролетариаты юлбашчысының хатыны Надежда Константиновна Крупскаяга бик зур рәхмәт. 1919 елда бирегә Үзәк губерна китапханәсе күченә. Хәзер ул Татарстан Милли китапханәсе дип атала.

Китапханә урнашу нәтиҗәсендә йорт шактый яхшы сакланган, дип саный Эдуард Хәйруллин. Ул яңа экспонатлар белән тулылана тора һәм реставрация кичерә. Ә әлегә кунаклар сакланып калган тарихка чумарга әзер. Өстәвенә, экскурсия балетны да, шампан шәрабен дә, җиләкне дә, кунакларга Ушковлар сейфында саклана торган бүләкләрне таратуны да үз эченә ала. Төрле деталь һәм бизәкләрне Эдуард Хәйруллин фонарь белән яктыртып күрсәтә – бик матур һәм серле килеп чыга. Т

PRESSA

БОЛГАРДА «КАРА ПУЛАТ». ҖАНЛАНДЫРЫЛГАН ЛЕГЕНДА

Михаил Рябинин, Александр Ефремов (фото)

Бихисап йолдызлар балкыган күк йөзе, тулган ай. Һәм сигез гасыр буе үзенең серен саклаган Кара пулат... Нәкъ менә биредә, аның борынгы диварлары янында, без хәзер «Кара пулат» операсы белән хозурланачакбыз.





Кара пулаттан сирпелгән серле яктылык караңгы күк йөзе фонында искиткеч могҗизалы күренә, әсәрләндерә. Әмма бу әле манзараның башлануы гына. Бераздан инде бөтенләй башка – кандай куе кызыл төстәге Кара пулат калка, диварларында ялкын телләре биешә. Ә инде дошманга баш бирмичә җаннары кыелганнарны кызганып елар вакыт җиткәч, диварларында гарәп язулы хәсрәтле пулат пәйда була...

КОМПОЗИТОР ЭЛЬМИР НИЗАМОВНЫҢ РЕНАТ ХАРИС ЛИБРЕТТОСЫНА ЯЗЫЛГАН «КАРА ПУЛАТ» ОПЕРАСЫ ПРЕМЬЕРАСЫ 2015 ЕЛДА КӘРИМ ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ СӘХНӘСЕНДӘ БУЛГАН ИДЕ. Куючы режиссеры – Татарстанның халык артисты Георгий Ковтун. Опера «Яңарыш» республика фонды инициативасы һәм ярдәме белән куелды. Идел буе Болгарстанында исламны кабул итүнең 1100 еллыгына, җиде еллык тәнәфестән соң, спектакль кабат сәхнәгә менде. «Кара пулат» операсының 12–13 августта Болгарда опен-эйр форматында тәкъдим ителгән версиясенең режиссеры – Илгиз Зәйниев.

Боларны күзәткәндә, тәннәр чымырдый. Әйләнә-тирәне декорация генә дип әйтергә тел әйләнми. Кара пулат – нәкъ шул замандагы чын корылма бит, риваять буенча, Аксак Тимер сугышчылары унике кызны нәкъ менә шунда яндырган: ташка сеңгән корымны ничәмә-ничә гасыр яңгырлары да юып, җилләре дә ашап бетерә алмаган.

Сәхнәдә барган тамаша җанландырылган легенданы хәтерләтә. Менә әсәрнең төп персонажы – хан кызы Нәргиз, аны Аксак Тимернең кәнизәге итмәкче булалар. Менә аны тугры дус кызлары үзләре арасына «яшерә». Менә болары исә – дошман сугышчылары, алар кызларны пулатка бикли һәм ут төртә: янәсе, хан кызы гына утта янмаячак... Дөрес, операның финалы легендадагы кебек түгел, анда Нәргиз ахирәтләре белән бергә һәлак була. Опера – мәңгелек кыйммәтләр турында.

Кара пулат янәшәсендәге чирәмдә утырган тамашачы карап һәм тыңлап кына калмый, үзе дә шундагы хисләрне кичерә. Һәм бу, мөгаен, ачык һавада искиткеч тамаша куючылар ирешкән төп нәтиҗәдер. Борынгы диварлар, заманча видеоинсталляцияләр, җанлы музыка, Илүсә Хуҗина тудырган Нәргиз образы, аның коллегалары эше – болар барысы да һәркемгә үзен борынгы тарихның кисәкчеге итеп сизү мөмкинлеген бирә.

Килешерсездер, болар барысы да Болгардагы премьераны берничек тә карамый кала алмаган Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев әйткән сүзләргә бик тәңгәл килә:

– Соңгы елларда бирердә эшләнгән эшләрне миңа әле үзебез дә тулысынча аңлап бетермибездер кебек тоела. Кыска гына вакыт эчендә без Болгарны мәңгеләштердек. Һәм быел без ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын – искиткеч мөһим вакыйганы билгеләп үтәбез. Тыныч шартларда, бернинди каршылыкларсыз. Ихластан тырышып эшләгән республика менә нинди казанышларга ирешә ала.

ИЛГИЗ ЗӘЙНИЕВ, РЕЖИССЕР:

– Безгә спектакльне бүгенге көнгә яраклаштырырга кирәк иде. Биредә, табигый ки, түгәрәк сәхнә дә, күпбаскычлы декорацияләр дә юк. Сәхнәне без Кара пулатның ике ягына урнаштырдык. Пулатның үзенә менәргә ярамый, чөнки объект ЮНЕСКО тарафыннан саклана.

Фото: Анна Арахамия, «Сөембикә» журналы

КҮП БАЛАЛЫ ГАИЛӘ: ТОРМЫШКА АШКАН ХЫЯЛ

Руфия Фазылова

Гаҗәпкә калу. Соклану. Күрәсе килү... Актаныш районының Киров авылында яшәүче Сабитовларның тормышын башта социаль челтәрләр аша күзәттем. Балаларын ияртеп, әти белән әни кая гына бармый: әле алар иген кырында йөри, әле бергәләп табигатьтә таң аттыра, әле Россия күләмендәге ярышта көч сынаша, әле камыр ризыклары әзерли... Ир белән хатынга моның кадәр көч, энергия кайдан килә икән? Шуңа өстәп, уникe баланың сигезе тәрбиягә алынганын да исәпкә алсаң, кыюлык та кирәклеген аңлыйсың.

«Сез ничек шулай булдыра аласыз?» Аларга йөзләрчә кеше шундый сорау бирә. Без дә әлеге сорауга җавапны Әни кеше – Венера Рәис кызыннан сорадык, чөнки нәкъ менә хатын-кыз гаилә учагын саклаучы бит...

ЯТИМЛЕК

– Алмас белән гаилә коруыбызга 35 ел булды. Ул мине бик күп нәрсәгә өйрәтте, хәтта камыр ризыклары пешерергә дә. Олы җанлы, булдыклы иргә тап булдым, монысы өчен Аллаһыма мең рәхмәт. Тормышта бик күпне күрдем. Китап язарлык дип әйтәләр бит, минем язмыш та шундыйрак.

1969 елның буранлы февраль аенда туганмын. Миңа кадәр абый туган, тик ул суык тиеп үлгән. Шуңа күрә кадерле булганмын. Миннән соң ике энем туды, аларны күбрәк үзем тәрбияләп үстердем.

Кечкенәдән хыялый булдым. Тургайлар тавышын җиргә ятып тыңлый идем. Хәтта алар белән «сөйләшкәнем» истә. Әни дә еш кына минем белән болынга бара иде. Пардан күлмәк тектереп, җитәкләшеп йөргәнебез бүгенгедәй хәтердә. Балачакның иң бәхетле мизгелләре кебек истә калган.

Матур балачак кыска гомерле булды шул. Ун яшемнән оялу, гарьләнү кебек тойгылар белән яшәргә туры килде... Ниндидер сәбәпләр аркасында әни аракы белән дуслашты. Әти дә читтә калмады. Эчкән килеш күрмәсеннәр дип, кеше керсә, әнине караватт астына яшерә идем. Салып йөргән вакытларда әни өчен фермага сыер саварга да төштем.

Аек чагында менә дигән тормыш алып бара торган кешеләр иде югыйсә. Әнинең чисталыгы, уңганлыгы! Җиләкне күп итеп җыеп варенье кайнатты, ярты авылга җитәрлек итеп кыяр тозлады. Аннан кышын ярты авыл халкы тозлы кыяр сорап килер иде. Шундый тырыш кешеләрне аракы харап итте... Без беркайчан пычрак, начар киенеп йөрмәдек. Иң авыры – яшьтәшләрем алдында кимсенү иде. Белгәнемне дә дәрестә сөйләргә батырчылык итмәдем.

Ләкин сынауларның иң олысы алда көткән икән – әнинең вафатыннан соң әтине төрмәгә утырттылар. Безне, өч баланы, әтинең абыйсы үз гаиләсенә сыендырды. Туган йортыбызның ишегенә йозак элене.

Әти дүрт ел утырды. Абый белән апа безне әти янына алып барып йөрде. Аларга мин әле дә мең рәхмәтле: укыттылар, тәрбияләделәр, какмадылар, сукмадылар, барыбызны тигез күрделәр.

Унҗиде яшемдә күрше егетенә кияүгә чыктым. Әти төрмәдән кайткач та өйләнде. Минем алар белән яшисем килмәде, шуңа да тизрәк өйдән китү ягын карадым. Баштагы мәлдә төрлесе булды: икебез дә баш бирмәскә тырыштык. Аннан балалар тугач, тынычлана төштек. Башта улыбыз Рузат, аннан кызыбыз Алсу дөньяга килде. Ун елдан соң Азат улыбызны алып кайттык. Үзем гел фермада эшләдем: сыер саудым, мөдир булып та тордым, учетчик, лаборант та булдым. Колхоз акча бирми башлагач, олы улым белән авыллардан сөт җыйдык.

Кызыбыз кияүдә, Актанышның үзендә киявебез белән 4 бала үстерәләр. Азатыбыз Казанда эшли. Олы улыбыз гына 24 яшендә бакыйлыкка күчте. Өйләнгән, бер кызы бар иде. Һич уйламаган җирдән арабыздан китте дә барды...



БЕР ЯНЫНА ИКЕ-ӨЧ ТӘ СЫЯ...

Әйткәнемчә, яшьтән хыялый идем. Ни өчендер кечкенәдән күп балалы әни буласым килде. Алай гына да түгел, ул балаларны тәрбиягә алам дип хыялландым. Гомерем буе әлеге уй минем белән йөрде. Газеталарда ятимнәр турында язылган мәкаләләрне укыганда, караучысы юк, бала алырга теләгән кеше юкмы, дигән җөмләне эзләдем.

Сөт җыйганда Кужәкә авылында бер гаилә белән таныштым: Хәниф абый белән Фәнзилә апа тәрбиягә балалар алган иде. Мин аларга карагач, янә теге күңелдәге хыял тынгылык бирми башлады. Ләкин бит әле ирне әзерләргә кирәк. Ул турыда сүз башлап карыйм, ләкин үзе ятим булмаган кеше аны аңлыймы соң?

Тамчы тама-тама боз тишә, ди бит: бала алырга иремне күндердем. Үзебезнең фамилияне бирәбез, дип сөйләштек. Яшел Үзән районының Норлат балалар йортында яшәүче бертуганнар – Руслан белән Алинә турында ишеттек. Документлар тутырдык. Әле аннан соң да алты ай көттек. Шул вакыт эчендә күңелем гел алар белән булды. Балаларны уйларым белән иркәләп йокларга яткырдым, назлап уяттым... Беренче очрашу гел истә: балалар йортына килгәч тә, сабыйларга уенчыклар, тәм-том тараттым. Ә берничә бала безгә ияреп директор бүлмәсенә керде. Ул да түгел берсе алдыма ук менеп утырды.

– Русланмы әллә бу? – дип сорадым. Директор баш какты.

Русланга инде 18 яшь тулды, КФУга укырга керде. «Исәнме, әнием», – дип елмаеп кайтып керә. Чиста, пөхтә, мәктәптә яхшы укыды. Ачуланганда да «эх» дип тә әйткәне булмады. Сеңлесе Алинәгә генә түгел, бүтән балаларыбызга да үрнәк абый ул...

Бала алу вирус белән бер икән ул – туктап булмый. Руслан белән Алинәдән соң Лилия белән Лианабыз кайтты. Лилия ун айлык, ә Лианага унөч яшь иде. Бүген бездә сигез бала, Аллага шөкер. Хыялым тормышка ашты. Алар дөньясында яшәүнең ничек ләззәтле икәнен сөйләп аңлата торган гына түгел. Моны күңел, йөрәк белән тоярга кирәк...

...Венера апа белән күпме аралашсам да, аны ачып бетерә алмадым төсле. Бер кешедә моның кадәр ярату, энергия ничек буладыр, аңлашылмый. Моннан тыш бит әле нинди генә бәйгеләрдә катнашмыйлар: «Идел буе төбәгенең уңышлы гаиләсе» конкурсында өченче урын, «Ел хатын-кызы» конкурсында «Хатын-кыз – әни» номинациясендә җиңү (2021 ел), «Нечкәбил» финалисты һ.б. лар. Әйткәнемчә, күп балалы әнинең социаль челтәрләрдә актив булуы да гаҗәпкә калдырды. Баксаң, көндез гаилә белән төшергән видеоларны ул балалары йоклаган арада монтажлый, шуңа җырлар сайлый. Аннан исә социаль челтәрләргә урнаштыра.

Венера апа һәркемгә ачык. Тәрбиягә бала алырга теләгән кешеләрнең төрле сорауларына җавап, киңәш бирергә ул һәрчак әзер. Аның күңел җылысы һәркемгә җитә...

ТӘРБИЯГӘ БАЛА АЛЫРГА ТЕЛӘГӘН АТА-АНАЛАРГА ВЕНЕРА САБИТОВАДАН КИҢӘШЛӘР:

– Башта барысын да яхшылап уйларга кирәк. Телевизордан гына балалар йортындагы малай-кызларны матур, ягымлы итеп күрсәтәләр. Чынлыкта хәл бүтәнчә. Бала гына булсалар да, алар тормышның ачысын, төчесен күргән. Күпләр гомер буе яшәп тә, аның кадәр авырлыклар кичерми. Аларның күңеле каткан була. Аны йомшату өчен бик күп укырга, өйрәнергә, бала алган гаиләләр белән аралашырга, күзәтергә кирәк.

– Баланы ятимлек арбасыннан йолкып алгансың икән, беренче адымыңны атладың дигән сүз. Шуннан инде сынаулар башлана: бала беренче хатасын ясауга, күңелеңне төшермә. Барысы да әйбәт булачагына ихластан ышан. Бала сезнең гаилә әгъзасына әйләнсен, сезнең тәрбияне алсын өчен, ким дигәндә, ике ел вакыт кирәк. Иң мөһиме – бала белән һәрчак янәшәдә булу. Аның бикле күңеленә ачкыч таба аласың икән, син – җиңүче!

– Вакытында усал да булырга кирәк. Шул ук вакытта рәхәтләндереп ярата, назлый да бел. Ярату чын күңелдән булсын. Бу балалар – тормыш мәктәбендә «бик яхшы» билгесенә укыган, югары белемле психологлар. Йомшак якны тиз күреп алалар.

– Алар белән күп вакыт бергә булырга кирәк. Шул рәвешле бала эшләргә дә, уйнарга да өйрәнә. Һәм баланы еш кына читтән күзәтегез: башкалар белән ничек сөйләшә, кайсы эшкә сәләте күбрәк? Нәтиҗәдә, баланың уңай, тискәре якларын тиз арада ачыклап булачак.

– Әләкләшү проблемасы. Ул бик еш була. Хата ясап, андый вакытта син икенче балаңны шундук ачуланырга мөмкинсең. Ләкин ашыкмаска кирәк! Андый очракта мин әләкләп килгән баланы күзгә каршына утыртам. «Әнә, бу малайдан (кыздан) кем гаепле икәнен сора», – диям. Үзем дә күзгә каршына барып: «Минем матур кызымны (улымны) кем кыерсытты икән?» – дим. Гаеп

> **– ЙӨЗ БАЛАНЫ ТЕЗЕП БАСТЫРСАЛАР ДА, ШУЛАР АРАСЫННАН ЯТИМНӘРНЕ ТАНЫРГА МӨМКИН.** Нинди генә затлы киемнән булсалар да... Аларның карашлары бүтән төрле, чөнки күңелләре китек. Син аларга йөрәгеңне ярып учларына сал, барыбер күңелләрен тулысынча тутыра алмыйсың. Моны башына төшкән кеше генә аңлый...

икесендә дә булганлыгы ачыклана. Уйнаганда дус булырга кирәклеген янә бер кат аңлатам.

– Ватылган бер уенчык (ертылган китап, дәфтәр) та игътибарсыз калмасын. Ай, кулым сынды, дип уенчык «еласын», ә бала аны кызгансын. Бергәләп курчакның кулын, аягын төзәтеп куегыз. (Китап-дәфтәрләр белән дә шул ук хәл.) Аннары курчак, баланы кочаклап, рәхмәт әйтсен. Шул рәвешле балада уенчык, китап-дәфтәрләргә карата сак караш тәрбияләнә.

– Бервакытта да балалар алдында талашырга ярамый. Һәм тагын – берең баланы ачуланганда, икенчең якламасын. Әтиең нәрсә дип әйтер, әниеңнән сорарга кирәк дип, гаиләдә ата-ананың абруен күрсәтергә кирәк. Хатын-кыз бу очракта төп рольне башкара – ир белән балалар арасында күперне нәкъ менә ул сала бит.

– Дини тәрбия турында да әйтми кала алмыйм. Балаларны: «Без күрмәсәк тә, Аллаһы Тәгалә күрә», – дип үстерәбез. Нәфесне тыюның бер зыяны да юк, ә киресенчә, әлегә файдасын гына сизәбез. Фанатларча дингә бирелү димим, ә Аллаһның барлыгын, берлеген искәртү турында сүз бара. Үскәч үзләре кайсы динне сайлаячагын карарлар. (Безнең очракта арада рус балалары да бар.) Бүген исә безнең балаларның барысы да намаз укый, ураза тота. Ихластан әйтәм, без кушмадык.

Әле күптән түгел Чабаксарга, «Идел буе төбәгенең уңышлы гаиләсе» конкурсына барганда, балалар сумкаларына иң беренче намазлык, кәләпүшләрен алып тыктылар. Ирем белән читтән моны күреп сөендек, әлбәттә. Күңелендә иман булган баланың киләчәге өметле.



ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

shop.tatmedia.ru

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

«ТАТМЕДИА» АҖ. Адрес: 420066 Казан ш., Декабристлар ур., 2. ГРН 1071690057834

16+ Реклама

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Кайсы шәһәр татар-мөселман «җәмгыять-шәһәре» саналган

Сәүдәгәр Борнаев үзеннән соң **нәрсә** калдырган

Нинди йола кунакчыллык билгесе саналган

Карашәмдә **нинди** осталар яши

Татар баянчысы чат-рулетканы **ничек** әсир иткән

ТӨБӘК ӘЙДӘМАННАРЫ: ГАБДЕЛВӘЛИ ЯУШЕВ

Илдус Заһидуллин, тарих фәннәре докторы

Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы
922
2022

XIX йөз ахыры – XX гасыр башында татарлар арасында гражданлык җәмгыятенең нигезләре формалаша. Гомумән, бу иҗтимагый алгарыш чорында җәмгыятьтә күзәтелгән яңарыш фидакарь затларның тырышлыгына бәйле булып чыга. Мондый шәхесләрне ике зур төркемгә бүлергә мөмкин. Бер яктан, алгарышның идеологлары һәм гыйлем таратучылары булган муллалар һәм зыялылар, икенче яктан, европалашуны финанс ягыннан тәэмин итүче сәүдәгәрләр, эшмәкәрләр.

ТРОИЦК – ТАТАР-МӨСЕЛМАН «ҖӘМГЫЯТЬ-ШӘҺӘРЕ»

Бүген әлеге вакыйгаларга XXI гасыр башы биеклегеннән күз ташлаганда, яңарыш хәрәкәтендә, бигрәк тә ул массачыл күренешкә әйләнгәнче, нәкъ менә финансларның роле аеруча мөһим булганлыгы күләгәдә кала сыман. Чөнки дәүләткә түләнгән салымнар мөселманнарга дини яки мәдәни тормышларын алга җибәрү өчен финанс ярдәме булып әйләнеп кайтмый. Мөселман руханилары мәчетләр салуны, сәдака бирүне, вакыф итүне бакыйлыкта оҗмахка эләгү өчен туры юл дип аңлатса, эшмәкәрләргә җәдид мәктәпләре ачкан, тормышны үзгәртерлек яңалыклар кертергә тырышкан өчен шәригать берни дә вәгъдә итми. Мондый шартларда сүз фәкать шәхеснең җәмгыять өчен риясыз хезмәте турында гына бара.

Бу яктан империя чоры татар өяз үзәкләре арасында Оренбург губернасының Троицк шәһәре аерылып тора. Аның тарихында халкын алдынгы милләткә әйләндерү юлында тырышлык куйган татар эшмәкәрләре һәм мөселман руханиларының шәһәр җәмгыяте файдасына кылган гамәлләре мөһим урын били.

Руслар арасында яшәү татарларны рухи яктан ныграк берләштерә, башка этник төркем вәкилләренең тормышын күзәтү, аларның иҗтимагый яшәү модельләрен өйрәнү мөмкинлеге бирә.

Троицк татарларына бердәмлеге «татар җәмгыять-шәһәре»нә туры килә. Чөнки татарлар шәһәр җәмгыяте һәм икътисадый тормышына йогынты ясый; кварталларда, урам-урам булып тупланып, күрше йортларда яши; автоном тормыш алып бара, социаль һәм мәдәни проблемаларны мөстәкыйль хәл итә; мөселман (кимендә, 2–3 мәчет, мәхәллә, дини һәм милли белем бирү йорты) һәм шәһәр инфраструктурасына (күчемсез милек, йортлар,кибет, ашханә, базар һ.б. җәмәгать биналары) ия була; икътисадый яктан нык җәмгыятьнең вәкилләре шәһәр үзидарәсе органнары эшендә катнаша һ.б.лар.

«Татар җәмгыять-шәһәре»н булдыруда сәүдәгәрләрнең өлеше искиткеч зур була, аларның йортлары, кибетләре, сәнәгать биналары, алар төзеткән мәчет-мәдрәсәләр Троицкиның татар өлешенең архитектура йөзен билгеле, җәмгыять территориясенең киңәюен тәэмин итә.

1897 елда Троицкида 8430 мөселман яшәп, аларның шәһәр халкының өчтән бер өлешен тәшкил иткәнлеге мәгълүм. Алар арасында татарлар 7283 кеше була (86,3%). 1910 елда бирегә 15701 мөселман күчеп килгән, алар кала халкының 42% тәшкил итә.

Сәүдәгәрләр һәм активистлар 1898 елда, Оренбург губернасында беренче булып, «Троицк мөселман иганәчелек җәмгыяте»н

Фотолар автордан алынды

оештыра, бу җәмгыять китапханә һәм ятимнәр приюты ачып җибәрә (1901 елдан аның рәисе Габделвәли Яушев була). 1911 елдан калада мөселманнарның мәгариф, сәхнә, театр сәнгатен үстерү җәмгыятьләре эшли. Соңгысы каршында оркестр һәм Троицк татар театрына (1911–1941) нигез салган театр труппасы оеша.

Шулай ук 1911–1916 елларда калада татарча «Акмулла» юмористик журналы һәм казах телендә беренче «Айкап» журналы нәшер ителә.

1915 елда бирелә башлангыч мәктәп хатын-кыз укытучылары әзерли торган 1 еллык хәзерлек сыйныфы һәм 5 еллык уку курсы булган яңа уку йорты ачыла. Аны Габделвәли Яушевның вафат булган әнисе Мөхәммәтшәрифнең хатыны Гайнижамал финанслый.

СӘҮДӘГӘР ЯУШЕВЛАР

Казан губернасы Иске Мәңгәр авылыннан Троицкига бәхет эзләп күченеп килгән лашманчы Гайсә Яушев беренчел капиталны, күпчелек татар эшмәкәрләре кебек үк, Бохарага баручы кәрваннарда хезмәтче, йөк бәйләүче булып эшләп туплый. Аннары Гайсә кибетләр ача, мәчетләр төзергә, булганнарын яңартырга ярдәм итә. Мәчет, мәктәп-мәдрәсәләрне төзүче һәм алар турында кайгыртучы татар сәүдәгәре булып таныла.

Гайсә Яушевның уллары – икенче буын сәүдәгәрләр Хәкимҗан белән Әхмәтҗан XIX гасырның икенче чирегендә инде үзләре кәрван йөртә. XX гасыр башында да 2 нче мәчет Яушев нәселе вәкиле вакыфы хисабына көн күрә. Гайсә Яушевның нәселе, зураеп, Урта Азиядә, Себер шәһәрләрендә бик йогынтылыга әйләнә. Туган-тумачалык, агай-энелек сәүдә элемтәләрен ныгытуда, бер-береңә ышаныч белән карау, авыр чакта ярдәмгә килүгә мөһим нигез булып тора.

Әхмәтҗан алыш-биреш операцияләрен Ташкент якларында җәелдерә, шәһәрнең 1 нче гильдия сәүдәгәре булып языла. Аның уллары – шулай ук Ташкентның 1 нче гильдия сәүдәгәрләре Габделвәли, Муллагали, Мөхәммәтсадыйк һәм Мөхәммәтшәриф 1887 елда, берләшеп, «Габделвәли Әхмәтҗан угылы Яушев вә борадәрләренең тиҗарәтханәсе» исемле сәүдә йортын оештыралар.

Яушевлар Оренбург далаларында һәм Урта Азиядә сәүдә иткән татар сәүдәгәрләре арасында, Каргалы бистәсеннән чыккан бертуган Хөсәеневләрдән кала, сәүдә әйләнеше күләме буенча икенче урында торган «сәүдә империясе» төзи. Бертуган Хөсәеневләр уртак капиталларын бүлгәннән соң, XX гасыр башында Яушевларның сәүдә йорты иң зур табыш алучы татар фирмасына әйләнә.

Сәүдә йортының баш конторасы Троицкида булып, Мәскәүдә һәм Варшавада тагын ике контора ачыла. Контора бүлекләре Чиләбедә, Кочкарда (Оренбург губернасы), Кустанайда (Тургай өлкәсе), Ташкент һәм Таразда (Сырдарья өлкәсе), Тукмакта (Җидесу, Семиречинск өлкәсе), шулай ук Казах даласының даими ярминкәләр була торган җиде торак пунктында (Звериноголов, Карачел, Николаев, Тукман, Тургай, Усть-Уй, Чөмләк) һәм Кытай шәһәре Голҗада уңышлы эшли. Яушевлар халык көнкүрешенә йөз тоткан, һәрдаим кирәк булган йон, терлек мае, чи һәм иләнгән тире, чәй һәм шикәр кебек товарлар белән зур масштабта сәүдә итә. Төрле шәһәрләрдә ачылган 20 кибеттә мануфактура, галантерея, бакалея, ювелир эшләнмәләре, тимердән хуҗалык кирәк-яраклары, күн, ислемай, тәмәке, аяк киемнәре, галошлар, дарулар һ.б. товарлар сатыла. 1895 елда компаниянең тукымалар белән сәүдә әйләнеше генә дә 3,6 млн сум тәшкил итә.

Яушевлар кибетләрендә үзләре җитештергән товарларны да саталар. 1852–1859 елларда Гайсә Троицкида сабын кайнату һәм тире иләү мануфактуралары ачкан була. Атасыннан калган тире эшкәртү мануфактурасын Габделвәли зурайта һәм киңәйтә. 1895 елда Яушевларның бу мануфактураларында 78 эшче 216 019 сумлык товар җитештерә: ат, кәҗә, сарык, тана тиреләрен илиләр, сабын кайнаталар.Троицкида сугым урыны, терлек мае эретү, сарык йонын юу предприятиеләре ачып, терлекчелек продукциясен беренчел эшкәртүне һәм сатуны оештыралар.

Яушевлар игенчелек продукциясен дә эшкәртүгә алына. 1881 елда Троицкида пар машинасы белән хәрәкәткә китерелә торган тегермән төзиләр, он һәм ярма җитештерү һәм сатуны җайга салалар. Аларның Ташкент янындагы плантацияләрендә үстерелгән мамык, чистартылып һәм тыгызландырылып, Россия шәһәрләренә озатыла.

ГАБДЕЛВӘЛИ ЯУШЕВ – ҖӘДИДЧЕЛЕК ИГАНӘЧЕСЕ

Габделвәлинең белем алуы башка сәүдәгәр балаларыныкыннан аерылмый. Ул үзе яшәгән 2 нче мәхәллә мәдрәсәсендә һәм Верхнеурал өязе

Гайсә Яушев акчаларына төзелгән Троицкиның 3 нче мәчете.



Кустанайдагы мәчетнең эчке күренеше.

Илче авылында Юлмөхәммәт һәм Гариф исемле хәлфәләрдә укый.

Бертуган Яушевларның сәүдә йортын Габделвәли җитәкли. Иганәчелек юнәлешендәге эшчәнлекне бертуганнар абыйлары Габделвәли ихтыярына тапшыра. Шуңа күрә Габделвәлинең иганәчелек эшчәнлеге, нигездә, Яушевларның уртак капиталы хисабына барган дип уйлыйбыз.

Габделвәли 1894 елда шәһәрнең 6 нчы мәчетен, аның янында мәдрәсә комплексын, янәшәдә вакыф итеп елына 100–120 сум табыш бирә торган кибет бинасын төзетә. 1901 елда бу мәчеткә, тагын вакыф итеп, шәһәрдәге барлык каралтыкурасы белән 4 йорт урынын бүләк итә. Ул шулай ук Кустанайда – таш мәчет, Троицк өязе Звериноголов һәм Борһан авылларында мәчетләр һ.б. гыйбадәтханәләр төзүгә зур акчалар сарыф итә.

Габделвәли Яушев акчаларына төзелгән Троицкиның 6 нчы мәчете.

Габделвәли бай мәчет-мәдрәсә салдыру, уку һәм укытуга ярдәм итү кебек эшләрдә Әхмәтхаҗи ахун Рахманколый, дамелла Мөхәммәт Бикмәти һәм шәех Зәйнулла Рәсүли белән киңәшләшеп эш йөртә, аларның уку йортларына ярдәм дә итә.

1912 елда шәһәрдәге 7 нче мәчет шулай ук Яушевлар нәселе вәкилләре хисабына төзелә.

Троицкида мәктәп реформасын нәкъ менә шушы шәхесләр башлап җибәрә. Замандашлары Габделвәли Яушевның иң зур хезмәте дип шәһәрдә җәдидчә укыту кертү өлкәсендәге тырышлыкларын атыйлар.

5 нче мәхәллә имамы һәм «Рәсүлия» мәдрәсәсе мөдире шәех Зәйнулла ике хәлфәсен Бакчасарай шәһәренә, Исмәгыйль Гаспринский янына, ысуле җәдид буенча укыту методикасын үзләштерергә җибәрә. 1895 елда Троицкида җәдиди башлангыч мәктәп эшли башлый. Әхмәтхаҗи ахун Рахманколый ысуле җәдидне гамәлгә кую нияте белән хәлфәсе Мөхәммәтзакир Ваһаповны Истанбулга җибәргәндә,чыгымнарның күп өлешен Габделвәли каплый. Габделвәли Троицк шәһәренең үзендә генә түгел, ә Троицк һәм Чиләбе өязләрендәге авылларда да җәдиди башлангыч мәктәпләр ачтырып, аларга матди ярдәм күрсәтә.

Ләкин яңалык акрынлык белән юл яра. Беренче чиратта, абруйлы дин башлыгыннан фатиха кирәк була. Габдерәшит Ибраһимов үзенең истәлекләрендә 1897 елда мөфти Мөхәммәдьяр Солтановның, Троицкига килгәч, Габделвәли Яушевның үтенеп соравына карамастан, ысуле

җәдидчә укытуны яклап шәһәр муллалары алдында бер кәлимә сүз дә әйтми китүен теркәп калдырган.

Русча ару сөйләшкән, ләкин укый-яза белмәгән, Ташкентның 1 нче гильдия сәүдәгәре Габделвәли, рус газеталарын укыттырып, дөнья хәлләре белән танышып баруны гадәткә кертә. Ул мөселманнарның балаларына русча укытуны яклап чыга. Башка төбәкләрдән аермалы буларак, биредә 1877 елда мәдрәсә каршында ачылган рус сыйныфының уңышлы эшләп китүендә бу уку йортының шәрәфле карап торучысы 1 нче гильдия сәүдәгәре Габделвәли Яушевның роле зур булу бәхәссез. Ул мәгариф өлкәсендә хезмәтләре өчен 1898 елда Анна лентасына тагылган «Тырышлык өчен» медале белән бүләкләнә, Габделвәлигә Оренбург уку-укыту округы попечителенең дә рәхмәте ирештерелә.

Укырга теләүчеләр нык күбәю, укытырга урын җитмәү сәбәпле, 1897 елда Габделвәли, ир туганнары белән бергә, хакимият алдына уку йортын 2 сыйныфлы рус-татар училищесы итеп үзгәртү мәсьәләсен куя. 1898 елда теркәлү узган «Троицк мөселман хәйрия җәмгыяте» уку бинасы өчен 7000 сумга, флигеле һәм хуҗалык корылмалары булган, беренче каты – кирпечтән, икенче каты агачтан төзелгән иркен йорт сатып ала, хәйрия җәмгыяте рәисе Габделвәли үз хисабына 4 мең сумга бинага төртке төзетә. «Троицк мөселман хәйрия җәмгыяте» ислам дине нигезләрен укытачак мөгаллим тотуны һәм 12 ярлы гаиләдән булган малайны укытуны, аларны тулай торак белән тәэмин итүне үз өстенә алачагын белдерә. 1903 елда яңа уку йортын аякка бастыруга куйган хезмәтләре өчен Габделвәли Яушев Александр лентасына тагылган «Тырышлык өчен» алтын медаленә лаек була.

Сәүдәгәрләр тырышлыгы белән Троицк каласы, Каргалы һәм Оренбург мәктәп-мәдрәсәләре төбәктәге иң зур уку-укыту һәм методик үзәгенә әверелә. Биредә казах шәкертләре дә белем ала.

Русча укытуны яклау белән бергә, Яушев руслаштыруга һәм милли изүгә каршылык хәрәкәтендә дә катнаша. Әхмәтхаҗи ахун Рахманколыйның «мөселман эшләре» буенча эшчәнлеген финанславы мәгълүм. Әйтик, 1904 елның 20 декабрендә ахун эчке эшләр министры исеменә мөселманнарның никах һәм аерылу мәсьәләләренә кагылышлы «Гражданлык уложениесе»нең яңартылган текстын эшләячәк комиссиягә үз тәкъдимнәрен җиткерә. 1892–1893 елларда мөселман дини китапларын цензор тарафыннан төзәтү башлангач, татар җәмгыяте Әхмәтхаҗи ахун Рахманколыйны һәм Мулламөхәммәт Бикмәтине, вәкилләр итеп, Санкт-Петербургка җибәрә, алар белән бергә Уфадан юрист Әбүсогуд мирза Әхтәмев тә бара. Троицк мөселманнары вәкилләре тәкъдиме белән башкалада кырымлы Ильяс мирза Бораганский нәшриятында Габделвәли Яушев биргән 6000 сум акча хисабына 1000 данә «Мишкат әл-мосабих» (хәдисләр җыентыгы) китабын бастыралар.

Сәүдәгәр Габделвәли Яушев зур хөрмәткә ия шәхес була. 1895 елны ул мөфти Солтанов, Әхмәтхаҗи ахун Рахманколый белән Николай II нең тәхеткә утыруын котлар өчен башкалага чакырыла, Кышкы сарайда император тарафыннан кабул ителә һәм императрицага дип ун мең сумлык мех һәдия тапшыра.

Габдерәшит Ибраһимов, 1904 елның октябрендә Троицк шәһәренә килеп, Габделвәли Яушев һәм Әхмәтхаҗи ахун Рахманколый белән киләчәктә татар дөньясында башкарыласы эшләр турында киңәшләшә. 1905 елның гыйнварында Минзәлә ярминкәсе вакытында татар җәмәгать эшлеклеләре мәҗлесен үткәрү уена килгәч, Габдерәшит Ибраһимов 1904 елның 20 ноябрендә Габделвәли Яушевка бу хакта хат яза. Габделвәли Яушев Түбән Новгород шәһәрендәге ярминкә вакытында 1905 елның августында үткән Бөтенросия мөселманнарының I съездында катнаша, ул милләткүләм яңа проектка иганәче буларак җәлеп ителә.

1906 елның 13 сентябрендә 67 яшьлек Габделвәли Яушевның йөрәге тибүдән туктый. Вафатыннан соң аның капиталын балаларына мирас итеп бүләләр.

Габделвәлинең тол калган хатыны Әшраф 1914 елда ачылган 8 еллык (4 еллык башлангыч һәм 4 еллык урта дәрәҗәдә белем курслары) хатын-кызлар мәктәбен тота, укытырга Мөхлисә Бубыйны чакыра. Урал артында иң зур сәүдә оешмаларының берсенә әверелгән фирманы Муллагали Әхмәтҗан улы Яушев җитәкли башлый. Казан шәһәре сәүдәгәре Сөләйман Аитовка кияүгә чыккан кызы Фатиха Аитова үзенә тигән мирас хисабына 1910 елда Казанда 4 сыйныфлы дөньяви кызлар мәктәбе оештыра, 1914 елда уку йортын татар кызлары гимназиясе итеп үзгәртә. Габделвәли Яушевның иҗтимагый эшчәнлеген балалары дәвам итә.

Кустанай каласында бертуган Яушевлар төзеткән мәчет.

КАЗАН ХАНЛЫГЫНДА ИСЛАМ

922
2022
Идел буе Болгар дәүләтендә
Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы

Булат Хәмидуллин

XV гасыр уртасына Алтын Урда бердәм империя буларак яшәүдән туктый. Аның калдыкларында пәйда булган дәүләтләрдә исә империянең традицияләре һаман саклана. Казан ханлыгы шулардан берсе була. Аның дәүләт төзелеше һәм мәдәнияте баштарак тулысынча диярлек Алтын Урданың Болгар вилаяте мирасына нигезләнә.

Тарихи чыганаклар шуны дәлилли: XIV гасырның икенче чирегеннән үк Алтын Урдада сөнничелек исламының хәнәфи мәзһәбе өстенлек иткән, анда җирле гореф-гадәтләр һәм юридик практика актив файдаланылган. Әлеге мәзһәп соңрак Кырым, Казан, Касыйм, Әстерхан һәм Төмән/Себер ханлыкларында киң таралган. Чыңгызлы ханнар һәм югары социаль страта булган татарлар белән беррәттән, мөселман руханилары да андагы иҗтимагый-сәяси тормыш агышын билгеләгән.

«ТАТАРЛАРНЫҢ ЮГАРЫ КАҺИНЕ» ТУРЫНДА

Мөселман хокукый доктринасы дәүләтне һәрвакыт бер үк вакытта конфессиональ дә, дөньяви да вәкаләтләргә ия институт буларак шәрехли. Казан ханлыгындагы суд-хокук системасы нигезен Коръәнгә, Мөхәммәд (с.г.в.) сөннәтенә һәм дин тәгълиматчылары белән хокук белгечләренең уртак фикеренә таянган шәригать тәшкил иткән. «Барлык гамәлләрендә һәм тормышларындагы

Иллюстрация: tatmitropolia.ru

һәр вакыйгада [Казан ханлыгы халкы] шәригатькә мөрәҗәгать итә... Бәхәсләр һәм мәхкәмә эшләре шәригать буенча хөкем ителә», – дип искәртелә татар елъязмаларыннан берсендә.

Мөселман руханилары Казан ханлыгының дәүләт системасында мактаулы урында булган, әлеге руханиларның башлыгы исә (югары сәед, Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) варисы) дәүләт советын (диванны) һәм еш кына «бөтен Казан җире» җыенын (корылтайны) җитәкләгән, илнең эчке һәм тышкы сәясәтендәге төп процессларда актив катнашкан. Татар ханнары ярлыкларында ул «судат гызам» яки «садати гозам» дип йөртелгән, Изге Рим империясе дипломаты Сигизмунд фон Герберштейн аны «татарларның баш каһине», рус кенәзе Андрей Курбский «олуг бискуп», татар тарихчысы Шиһабетдин Мәрҗани исә (безгә мәгълүм булмаган урта гасыр чыганакларына таянып) «бөекләр җитәкчесе» («нәкыйбел-әшраф») дип атаган.

1524 елда Казан янында уздырылган бер тантаналы татар мәрасимен сурәтләгәндә, Герберштейн үз укучысына сәеднең «аларда шулкадәр хакимияткә һәм мактауга ия булуын, ул якынлашканда хәтта ханнарның да аңа каршы килүен, ат өстендә утырган сәед белән ханның аягүрә басып, башын иеп күрешүен; герцог һәм түрәләрнең исә аның кулына түгел, тезенә генә, бәкләрнең – аяк табанына, гади халыкның исә киғән киеменә яки атына гына кагылырга хокуклы булуын» хәбәр итә. Шунысын да искәртеп үтик: Казан ханлыгы җирләре сәеде турында соңгы тапкыр 1554 елда телгә алына.

«ТАТАР СУФИЧЫЛЫГЫ» ТАМЫРЛАРЫ ТУРЫНДА

Руханилык структурасы төгәл һәм киң тармаклы була. Язма, фольклор һәм археологик чыганакларда, аерым алганда, татар кабер ташларындагы эпитафияләрдә дингә хезмәт итүче, суд эшләре белән шөгыльләнүче, миссионерлык, дипломатик, канцелярия, мөгаллимлек һәм хәтта хәрби эшчәнлек алып баручы баш һәм кече сәедләр, сәед уллары, шәехләр һәм шәехзадәләр, муллалар һәм муллазадәләр, имамнар, дәрвишләр, суфыйлар, хафизлар, казыйлар, абызлар, мәүлә һәм дәнишмәндләр хакында мәгълүмат бар. Кызганыч ки, аларның конкрет «вазыйфаи» һәм «дөньяви» бурычлары безнең көннәргә кадәр килеп җиткән тарихи материалларда бик төгәл күрсәтелмәгән.

Казан ханлыгы руханилары арасында Урта Азиядәге төрки халыкларда киң таралган Ясәвийә суфичылык тарикате вәкилләренең дә булуын аерып әйтәсе килә. Татар риваятьләре әлеге тарикатьнең Урта Идел буенда кимендә Алтын Урданың соңгы чорыннан бирле өстенлек итүе хакында сөйләү мөмкинлеген бирә. Суфичылык символикасы мәдәниятнең барлык өлкәләрендә (архитектура, поэзия, каллиграфиядә һ.б.) очрый, Ясәвийә тарикате идеологиясе һәм горефләре

Панно: Александр Иванов, «Казан ханлыгы». 570 х 930, 1998 ел.

Панно: Александр Иванов, «Казан ханлыгы». 600 х 1320, 2001 ел.

дәүләттә ислам сәнгатенең классик каноннары белән берләшеп тарала.

Казан шагыйрьләре, прозаиклары, публицистлары Мөхәммәдьяр, Мөхәммәд-Әмин (1484, 1487–1495, 1502–1518 елларда хакимлек иткән Казан ханы) һәм бигрәк тә Кол Шәриф (Әстерхан ханлыгында туган, Казанның югары сәеде, «Шәриф Хаҗи-Тархани» әдәби псевдонимы булган) әсәрләре суфичылык сюжет һәм мотивларына бай. Күрсәтелгән чорда мөселман җәмгыятенә әкренләп Нәкышбәндия тарикате үтеп керүе дә күзәтелә. Алдагы гасырлар дәвамында әлеге тарикатьләрнең идеяләре тирәнтен үзләштерелә һәм Урта Идел буе халыкларының мәдәни мирасына үтеп кереп, дөньяга «татар суфичылыгы» буларак танылa.

БӨТЕНДӨНЬЯ МӨСЕЛМАН ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕНЕҢ БЕР ӨЛЕШЕ

Җирле чыңгызлы ханнар үзләренең ислам өммәтенә һәм бөтендөнья мөселман цивилизациясенә керүен бик яхшы белгән дип фаразлау өчен шактый нигезле җирлек бар. Бу турыда күп кенә татар риваятьләрендә сөйләнә, аларда «Казанның мөселман ханнары» еш телгә алына. Моны Коръән аятьләре язылган хан ярлыклары һәм Казан ханнарының кирмән территориясендәге төрбәләре дә дәлилли. Бу хакта рус язма чыганаклары да хәбәр итә.

Тагын бер саллы дәлил – Казан ханы Мөхәммәд-Әминнең Мөхәммәд пәйгамбәргә багышланган «Могҗизанамә» поэмасы. Казан ханнары Сәхибгәрәй (1521–1524 елларда – Казан, 1532–1551 елларда – Кырым ханы) һәм Сафагәрәйгә (1524–1531, 1535–1546, 1546–1549 елларда Казан ханы) мактаулы «гази» («дин өчен көрәшүче», «дин өчен көрәштә катнашучы мөселман») титулы бирелү дә моның ачык дәлиле булып тора.

Дәүләт хакимнәре кебек үк, аксөякләр дә мөселман була. Аерым алганда, моны рус Патша архивы дипломатик документлары арасында сакланган «татар Коръәне» (хәзер югалган) һәм Казан ханлыгы татарлары дипломатия мәдәниятенең елъязмалардагы даими сюжеты – Коръән тотып ант итүләре дә дәлилли. Казанның күренекле шагыйре һәм тылмач-дипломаты Мөхәммәдьяр ислам пәйда булу һәм таралу тарихы, пәйгамбәр һәм хәлифәләр тормышы хакында күп язган.

Татарлар еш кына Мәккәгә хаҗга барган һәм аннан мактаулы «хаҗи» титулына ия булып кайткан. Мәсәлән, без Нурсолтан «патшабикә»нең туганнары һәм якыннары белән Гарәбстанга сәфәре хакында беләбез, бу турыда ул 1495 елда олуг

Мәскәү кенәзе Иван III гә хатында шәхсән үзе хәбәр итә. Чыганакларда без хаҗи титуллы Казан ханлыгы татарлары исемнәрен еш очратабыз.

ТОЛЕРАНТЛЫК – ГАСЫРЛАР МИРАСЫ

Дәүләт составында күпсанлы мәҗүсиләр дә була, әмма Казан вилаятенең күпчелек халкы ислам динен тота. Мәсәлән, рус чыганакларында аларны «бесермен динен тотучы Казан сарациннары» дип атыйлар. Казан арты, Идел алъягы, Түбән Кама алъягы һ.б. территорияләрдә табылган күпсанлы мөселман зиратлары, Коръән аятьләре язылган кабер ташлары җирле халык мохитендә ислам диненең өстенлек итүен ачык дәлилли. Күрәмсең, XVI гасыр уртасында Казан дәүләтендә яшәгән 400–500 мең кешенең кимендә 200–250 меңе мөселман булгандыр.

Шунысын да искәртү мөһим: ислам өстенлек иткән һәм тормышның барлык сфераларына аның йогынтысы арткан ханлыкта бөтен диннәргә караш тигез була, бу Хәзәр каһанлыгы, Идел-Чулман Болгары, Монгол империясе һәм Алтын Урда традицияләренә бәйле. Үзара хөрмәт, толерантлык һәм динара түземлекне пропагандалауда суфый шәехләренең роле бигрәк тә зур була.

Казанда әрмән чиркәве эшли, дәүләт халкының яртысы диярлек мәҗүсилекнең төрле төрләренә табына. Күп чыганаклардан күренгәнчә, чит дин мохитендә ислам көч белән түгел, ә этномәдәни элемтәләрнең көчәюе нәтиҗәсендә тарала. Шунысын да аерым әйтергә кирәк: ханлыкта төрле этносоциаль төркемнәрнең үзара интенсив мәдәни хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә бердәм этносоциаль бергәлек төзү процессы башлана.

Моңа бигрәк тә ислам мәгърифәтенең бай традицияләре, мөселман уку йортларының (ил мәчетләрендәге барлык мәктәп һәм мәдрәсәләрнең һәркайсында һичшиксез китапханә дә булган) югары үсешкә ирешкән системасы, галим-голәманың күплеге дә булышлык иткән.

Дәүләттә канцелярия эшләрен алып бару, юриспруденция, тарих фәне, әдәбият һәм әдәбият белеме, музыкаль иҗат, декоратив-гамәли сәнгать, архитектура һ.б. актив үскән. Дәүләттә эш башкаруның югары дәрәҗәдә булуын могҗиза белән сакланып калган татар документлары (мәсәлән, хан ярлыклары), шулай ук ханнарның дипломатик хат язышуы (мәсәлән, Бөек Литва кенәзлеге белән) дәлилли.

Казан ханлыгындагы мәктәп һәм китапханәләр, галимнәр, шагыйрьләрнең күпсанлы булуы хакында халык риваятьләре, Аднаш Хафиз, Гарифбәк, Кол Шәриф, Мөхәммәдьяр, Мөхәммәд-Әмин, Өмми Камал һәм башка авторларның әдәбитарихи әсәрләре тәфсилләп хәбәр итә. Мөхәммәд-Әмин әл-Болгари шәрехләүләре белән «Савыгу» медицина трактаты һәм Мөхәммәд ибне әл-Хаҗи Әтмаҗинең «Арифметика фәне кагыйдәләре җыелмасы» трактаты төрле төгәл фәннәрнең дәүләттә югары үсештә булуы хакында сөйли. Тагын бер дәлил – Казан ханлыгындагы шәһәрләр төзү югары культурасы кульязма чыганакларда билгеләп үтелгән һәм археологик тикшеренүләр белән расланган.

Боларның барысы бергә барон Сигизмунд фон Герберштейнга үзенең Rerum Moscoviticarum Commentarii («Мәскәү эшләре турында язмалар», 1549) хезмәтендә «бу [Казан] татарлары башка күп халыктан укымышлырак» дип язып калдыру мөмкинлеген биргән...

Ислам Казан ханлыгы халкы тормышының барлык тармакларына үтеп кергән, аның идеологиясенә, рухи үсешенә, икътисадына, көнкүрешенә, халыкара бәйләнышларына гаять зур йогынты ясаган. Урта Идел буенда мөселман дине үсешенең үз үзенчәлекләре булган, алар, барыннан да бигрәк, бу динне тотучыларның конфессиональ толерантлыгында чагыла.

ислам ядкәрләре

КАЗАНДАГЫ БОРНАЙ МӘЧЕТЕ

Кызыл таштан бизәкләп ясалган сигез кырлы манара уйларга канат куя. Кемнәрдер – «Мең дә бер кичә» сарайларын, икенчеләре Византия соборларын, өченчеләре Урта Азия мәчетләрен күз алдына китерә.

922 2022 Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы



Фото: Әскәр Сабиров

Мөгаен, һәркем үзенчә хаклыдыр. Белгечләр раславынча, Борнай мәчете эклектика стилендә төзелгән, анда архитектор татар, рус һәм көнчыгыш мөселман архитектурасы мотивларын берләштерә алган. Ә тагын мәчет манарасы IX–XIII гасыр Хәрәзем һәм Хива гыйбадәтханәләрен хәтерләтә. Урта Азия архитектура ядкәрләре белән янәшә куйганда, яше буенча ул, аңлашыла ки, сабый, әмма барысы да чагыштыруда беленә. Борнай мәчете Казанның барлык мәчетләре арасында, Мәрҗани һәм Апанай мәчетләреннән кала, яше буенча өченче санала.

ЧИРЕК ГАСЫРДАН СОҢ ПӘЙДА БУЛГАН МАНАРА

Мәчеткә исем тире белән сәүдә итүче, сабын заводы хуҗасы 1 нче гильдия сәүдәгәре Мөхәммәтсадыйк Борнаев хөрмәтенә бирелә.

Бәхәссез абруйга ия Борнаев үзенең байлыгы белән генә түгел, иганәчелек, җәмәгать эшчәнлеге белән дә танылган шәхес була: егерме җиде ел рәттән Шәһәр думасына гласный булып сайлана. 1872 елның язында Мөхәммәтсадыйк Борнаев Казан шәһәр Думасына «Зур Мещан һәм Екатерина урамнары арасындагы кварталдагы буш шәһәр җирен анда таштан җәмигъ мәчете төзү максатына сатып алу турында» үтенеч белән мөрәҗәгать итә. Хакимиятләр үтенечне кире какмый, кишәрлекне 137 сумга сата. Ул вакытлар өчен шактый акча, ләкин, замандашлары бәяләмәсенә караганда, 500 меңлек күчемсез милеккә ия Борнаев өчен бу алай зур булмый.

Кызыл кирпеч мәчетне кырыс өслүбтә ул вакытта күренекле Казан архитекторы Петр Романов проекты буенча шул ук 1872 елда төзиләр. Аның фонында купшы бизәкләр мулдан кулланылган манара – чын архитектура шедевры. Мондый аерманы аңлатып була. Манара күпкә соңрак – мәчет диварларында беренче намаз укылганнан соң егерме өч ел узганнан соң гына өстәп төзиләр. Проектның авторы инде башка архи-

тектор – Федор Малиновский була. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: Казандагы барлык мәчет манаралары башкача урнаштырылган – намаз залының уртасыннан диярлек үсеп чыга.

ЯХШЫ ҺӘМ ТӨРЛЕ ИМАМНАР

Борнай мәчете Казанда өченче җәмигъ мәчете – исәп буенча шәһәрдә өченче мөселман мәхәлләсе санала. Ул әле таш гыйбадәтханә салынганчы ук була – бу урында янгында юкка чыккан агач мәчет эшләгән. Мәчет акчага кытлык сизми: Борнаев юмарт иганәче, монда күренекле мөселман галимнәре һәм педагоглары хезмәт куя.

Шулай да мәхәллә тарихында күңелсез сәхифәләр дә бар. Борнаевның үтенече буенча җитәкчелеккә чакырылган күренекле дин белгече Сәләхетдин Исхаков*, сәүдәгәрдән бүләккә торак йорт һәм яхшы акчалар алгач, берничә айдан мәхәлләне ташлый һәм абруйлырак саналган икенче җәмигъ мәчетенә күчә. Шуннан соң 16 ел дәвамында Борнай мәхәлләсе үз имамыннан башка көн күрә.

Борнай мәхәлләсенең шәһәрдә иң абруйлыларның берсенә әверелүе имам Шакир Кулиевның эшчәнлегенә бәйле була. Хәзрәт мәхәллә кварталларында шәригать канунnarының саклануын катгый күзәтә, мәктәптә аның дәресләре дә популярлык казана: бирегә, укырга дип, Казан губернасының төрле почмакларыннан киләләр. Кулиев 1917 елгы инкыйлабка кадәр мәчеттә имам-хатыйб булып хезмәт куя.

Исеме Борнай мәчете тарихына язылган тагын бер шәхес – Казан сәүдәгәре Абдрәхим Залюшев. Ул 1899 елда мәчеткә кибете дә булган зур таш йорт бүләк итә. Милектән кергән табыш мәчетне карап тотуга, руханиларга һәм мәктәпкә финанс ярдәме күрсәтүгә бара.

ЧОРЛАР АЛМАШКАНДА

Бервакыт өченче җәмигъ мәчете чак кына беренче һәм бердәнбер Казан мәчетенә әйләнми кала. Казанда мәчетләрнең күбесе ябылган, манаралар киселгән, ә намаз заллары большевиклар тарафыннан склад һәм клубларга әйләндерелгән 30 нчы елларда Борнай мәчете әле һаман да эшләвен дәвам итә. Шулчакта җаваплы иптәшләрнең башында, Мәрҗани мәчетен ябып, аны шәһәрдә төп һәм бердәнбер мөселман гыйбадәтханәсе итеп калдыру нияте туа.

Әлеге болгавыр заманнарда Борнай мәчетендә имам булып карт хәзрәтнең улы Мөхәммәтфарук Кулиев эшли. Яшь мөселман буынының әлеге вәкиле үзенең гыйлемле һәм югары әхлакый сыйфатларга ия булуы белән аерылып тора. Сугышчан атеизм чорында ул, рухи-дини остаз буларак, үзенең бурычын намус белән үтәп, мәхәллә халкына тугры кала. Күрәсең, Кулиев хакимиятләрнең ачуын китерми торган дипломатлык сәләтенә дә ия булгандыр. Мәчетне япмый калдыру форсаты чыгу шуңа да бәйледер.

Әмма хакимиятләр тарафыннан озак һәм җитди тикшерелгән идея тормышка ашырылмый. 1939 елда Татреспублика ҮБК карары белән Борнай мәчете ябыла. Мәчет манарасын кистерергә большевикларның кыюлыгы җитми – бәхеткә, ул безнең көннәргә кадәр шул килеш сакланып кала. Мәчетне дин тотучыларга 55 елдан соң – 1994 елда кайтаралар.

Адрес: Казан, Иске Татар бистәсе, Әхтәмов ур., 7.

> 30 нчы елларда Борнай мәчете әле һаман да эшләвен дәвам итә. Шулчакта җаваплы иптәшләрнең башында, Мәрҗани мәчетен ябып, аны шәһәрдә төп һәм бердәнбер мөселман гыйбадәтханәсе итеп калдыру нияте туа.

* *Соңрак ул Галимҗан Барудиның укытучысы һәм остазы була.*

МУҢЧА – КУНАК СЫЙЛАУНЫҢ БЕР ЙОЛАСЫ...

Рабит Батулла,
язучы-прозаик, драматург

Татар гомергә йолаларны санлап, аларга таянып яшәгән. «Татарстан» журналы да гореф-гадәт, йолаларны барларга булды. Бу эштә ярдәмгә язучы, драматург, татарның аксакалы Рабит Батулланы чакырдык. Бүген ул безгә мунча йоласы турында сөйләде.

КЕМ БЕРЕНЧЕ?

-Юнан халкы әйтер: мунчаны безнең бабайлар уйлап тапкан. Урыс, мунчаны башка халыкларга без керттек, дияр. Татар, иң башлап мунчаны безнең әби-бабайларыбыз уйлап чыгарган, дип әйтер. Нишләтәсең, һәр халыкның борынгы буласы килә. Ләкин бу милләт борынгы дип әйтер өчен нигез, дәлил кирәк. Мунча мәсьләсендә дә шуңа охшаш әкәмәтләр гел булгалап тора. Зур совет энциклопедиясен ачып баксаң, анда акка кара белән язылган: русларда мунча Печора монахларына XI гасырда ук билгеле булган икән. Сәяхәтче Олеарий исә XVII йөздә русларда мунча булганлыгына ишарә ясаган, ди. Татарларда (Идел буе төркиләрендә) мунча турындагы язма мәгълүмат Печора монахларыныкына караганда – 200, Олеарий язганга караганда 800 ел алдан күренә. Мәгълүм булганча, Бөек Болгар дәүләтендә (IX йөз) мунча культы киң тарала. Җәмәгать мунчалары, шәхси мунчалар гадәти күренеш була. Җәмәгать мунчаларында шахмат, шакмак тәгәрәтеш (нард) уеннары, хәтта чит ил дәүләтләренең илчеләре белән гамәли күрешүләр дә уздырылган. Болгар мунчалары юыну, тазарыну, дәвалану урыны гына түгел, шәхесләр мөнәсәбәтенең мәркәзе ролен дә башкарган. Мисал өчен, Кызыл пулат мунчасы таш идәненең каты җылытылуы белән башка агач мунчалардан аерылып торган. Юынучы утырган таш астан кыздырылып, ләүкә вазифасын да үтәгән. Хәзер мондый мунчаны ни өчендер «Төрек мунчасы» дип йөртәләр. Бәлки шушы рәвештәге мунча йолалары татарларда онытылып, Төркиядә яхшы сакланганга күрә шулай атаганнардыр.

КАРА МУНЧА

Кара мунча хәзер татарларда юк, дип әйтергә мөмкин. Без үскәндә, сугыш вакытында, сугыштан соңгы елларда кара мунча бар иде әле, ләкин ул фәкыйрьрәк кешедә була торган иде. Агач бура эчендә мич, аның өстендәге тимер-томырларга чуерташ өелгән була. Янында тактадан эшләнгән ләүкәсе дә бар. Агач утыргычлар, түндәләр, агач ләгәннәр, агач саплы ужау (чүмеч). Агачтан, чөнки тимердән булса, пешерә. Имәннән яки өрәңгедән ясалган агач тараклар, салкын су ләгәннәре, мурт сөягеннән ясалган кисмәкләр...

Әзерләде Руфия Фазылова. Фотолар: «Татарстан» журналы архивыннан.

МУНЧА ЙОЛАСЫ ТУРЫДА БИК КҮПЛӘР УЙЛАП ТА КАРАМЫЙ, Ә БИТ УЛ ТУЛЫ БЕР ФӘЛСӘФӘ. Мунча ягу мичкә утың тыктың да сүгенә-сүгенә шырпы төрттең түгел ул. Иң беренче, ким дигәндә, бисмилланы әйтеп эш башлау зарур. Ә мунчага барганда ун, аннан җиде адым кала «эхем-эхем» дияргә кирәк. Инде ишекне ачып җибәрер алдыннан тагын «эхем»нәргә кирәк. Әчтә тавыш булмаса, ишекне ача аласың. «Эхем»ләмичә керсәң, анда пәриләр мунча кереп ятарга мөмкиннәр, пәриләрне күргәч, сине зәхмәт суга. Пәрине дә зәхмәт суга, ул да имгәнеп кала. Безгә әби-бабайлар шулай дип өйрәттеләр. Әлбәттә, бу куркыту булган. Ә чынлыкта алар әдәплелеккә өйрәткән. Бәлки, әни күрше хатынын дәшкән дә, мин белми калганмындыр, ә ул юынып ятадыр? Кыен хәлгә куймас өчен эшләнгән ул. Ул халык тәрбиясе. «Эхем-эхем» дип керсәң, эчтә юынып ятучы ишетә дә: «Кеше бар, туктап торыгыз!» – дип кисәтә бит.

Төнлек – мунчаның бер диварындагы кеше йодрыгы сыярлык тишек ул. Төеп тутырылган мунчала яки чүпрәкне алып, төнлекне ачасың да мунча мичен ягып җибәрәсең. Төтен бөтен дөньяны каплый. Ишек белән төнлекне ачык калдырасың, ә мунча мичендә ут яна. Кызурак булсын дисәң, бераздан тагын утын өстисең. Утын янып, шаулап торган күмерләрне тимер кисәү агачы белән болгатып җибәрәсең дә иң башта төнлекне каплыйсың. Эссе чыгып китәрлек булмасын дип, мунчаланы тыгызлап, төеп куясың. Ишекне ябып, агач белән терәтеп куясың. Мунча кыза башлый. Кара мунчаның эче тулы төтен, сөрем, агулы ис була. Сак эш итәргә кирәк. Ике сәгатьләп узгач, мунчаны барып карыйсың: ут-күз юкмы, исе беткәнме? Ишекне ачып җибәрүгә үк, сыек зәңгәр төстәге җылы һава күренә. Тагын томалап куясың. Бераздан соң янә барып карыйсың: мичтә ис чыгарырлык күмер калмаса, һавада ис беткән булса, ишекне ачып чак кына җилләтеп, исле һаваны кудырып, мунчаны томалап куясың. Ул шунда өлгерә, кыза. Тагын бер сәгатьтән соң барып, янә җилләтәсең. Бераз ябып торгач, ишекне ачып куеп, эссе саласың. Шул эссе агулы һаваны куып алып чыгып китә. Аннан соң тагын мунча ишеген ныгытып ябасың. Бераздан мунча әзер була.

Юынырга кергәч тә, башта идәнгә утырып, аннан түндәккә, бераздан соң ләүкәгә менеп кызынасың, тирлисең. Алдан ук чабынсаң, хәл китүе бар. Башта бер кат җылынып алырга, аннан соң чабынырга кирәк... Кара мунчада ак киемнәр тиз корымлана, шуны истән чыгармаска кирәк. Юынып коенганнан соң диварга да таянырга ярамый, чөнки ул корым гына. Инде иске киемнәреңне мунчада калдырып, чисталарын киеп, кайтып китәсең.

Берәр кеше юынмаган, пычрак битле булса, аңа: «Һи, мунча пәрие», – диләр. Ихтимал, бу гыйбарә кара мунча заманнарыннан телгә кереп калгандыр. Гаҗәп түгел, кара мунчадан каралып чыгучылар да булган, чөнки мунчаны, гадәттә, кич яки төнлә кергәннәр. Ке-

Мәгълүм булганча, Бөек Болгар дәүләтендә (IX йөз) мунча культы киң тарала. Җәмәгать мунчалары, шәхси мунчалар гадәти күренеш була.

росин юк, шәм юк, шуның өчен чыра яктысында юынып чыккан кешенең берәр җире корымга буялмый калмаган. Сукыр лампасы булган кешенең дә корымга буялмый чыгу ихтималы аз, чөнки аның яктылыгы тычкан утыныкы кебек зәгыйфь кенә була иде.

АК МУНЧА

Бәхәссез, ак мунча кара мунчаны кысрыклап чыгарды. Ак мунчаның сәкеләре, ләүкәләре чиста, диварлары сап-сары бүрәнәдән. Корым, сөрем кебек нәрсәнең заты да юк. Ак мунчаны һәркем үзенчә кора. Гадәттә, аларда төнлек булмый, чөнки ак мунча миченең төтен юлы – морҗасы, торбасы бар. Морҗада юшкы (эшермә) була. Мунча ягар алдыннан иң беренче шул юшкыны тартып, төтен юлын ачарга кирәк. Биектау, Шәле, Балтач якларындагы ак мунчаларның пакьлеген, чисталыгын күрсәң, исең китәр. Аның һавасы саф була. Мунча – кунак сыйлауның бер йоласы да. Кунакка чакырып та, мунча якмасалар, хуҗаның поты бер тиен! Мунчасыз кунак ул яртылаш кына сыйлану дигән сүз. Килгән кунакны аш ашатмыйча, юл чәе генә эчертеп, мунчага алып китү – иң олы хөрмәт. Халык мәкале дә шул турыда сөйли бит: «Әүвәл мунча, аннан сумса».

Ак мунчаның сәкеләре, ләүкәләре чиста, диварлары сап-сары бүрәнәдән.

Уттай кызу эш өстендә мунча ягарга вакыт булмый. Эш өстендә яңгыр явып, урак урырлык, печән чабарлык булмаса, бөтен халык мунча яккан, мич ашлары пешергән, тәмләп чәй эчкән. Үзенә күрә бер бәйрәм ясаган. Ул турыда такмак та сакланып калган:

«Яу, яңгыр!
Байның йөргән яндыр.
Яңгыр яуса кайтырбыз,
Мунча кереп ятарбыз...»

Мунча керү кайчан рәхәтрәк була? Кышкы зәмһәрир салкындамы, әллә җәйге чилләдәме? Салкыннан соң эссе мунчага кереп ятуның никадәр ләззәт икәнен сөйләп торырга да кирәк түгелдер. Әмма җәйнең иң эссе вакытында шаулап торган мунчага кереп, кат-кат чабынып, урамга чыксаң, көн эсселеген сизмәячәксең дә. Ни өченме? Беренчедән, синең тәнеңдә тир калмаган, син тирләмәячәксең. Икенчедән, көн никадәр эссе булса да, мунча эссесеннән күпкә калыша һәм син үзеңне салкынга чыккан кебек, рәхәт хис итәчәксең. Шуңа күрә эссе көнне суынырга теләсәгез, эссе мунчага барыгыз!

Үзбәкстан, Кыргызстан, Казахстанга гастрольләргә барган вакытта артист Ринат Мифтахов белән Казаныбыздан алып барган икешәр каен себеркесен тотып, көн саен мунча кердек. Һәм һич сусамыйча, тирләмичә, Урта Азия эссесен бик җиңел үткәрә торган идек.

Тәртип

Казан 93,1 FM
Яр Чаллы 90,2 FM

Тәртипле халык югалмый!
Татар тәртипсез була алмый!

tartip.tatar
@tartip.tatar
tartip.tatar

App Store
Google Play

Реклама 6+

PRESSA

КАРАШӘМ – ЯКТЫЛЫККА ТАБА...


Фото: Александр Ефремов

КАРАШӘМ

«Мондый матурлыкны бүтән бер авылда да күрә алмыйсыз, килегез әле», – дип, бер укучыбыз күп итеп фотолар җибәрде. Чынлап та, кулдан ясалган сыннарны күреп гаҗәпкә калдык. Укучыбыз киңәшен тотып, Яшел Үзәннең Карашәм авылына – әкият иленә барырга булдык.

Руфия Фазылова

«ЕЛ САЕН БЕР-ИКЕ СЫН ЯСЫЙМ»

Тукаебыз: «Тау башына салынгандыр безнең авыл», – дип язса, Карашәм нәкъ тау астына утырган. Кешеләрнең бәрәңге бакчалары тауга ук терәлеп тора. Кызык бит – җиләк җыярга арт бакчага гына чыгып керәсең.

Әкияти матурлык тудыручы Рәшит Хәмидуллинны эзләп йөрисе булмады – безне ул авыл башына ук чыгып каршы алды. Һәм туры үзе яшәгән йортка алып китте... Рәшит абыйның йорты нәкъ чишмәгә терәлеп тора икән. Бу урамда бүтән бер генә йорт та юк. Тау астында чишмә һәм гүзәл бер йорт. Бер шагыйрь булса шул мизгелдә үк шигырь язып ташлар иде. Андый сәләт юк шул... Менә шулвакыт Рәшит абыйның ни өчен сыннар ясый башлавы да аңлашылды. Мондый җирдә бары туң йөрәкле кеше генә иҗат итми яши аладыр. Ә иҗат ул төрле була.

– Монда элек кычыткан, әрем үсә иде, – дип елмайды Рәшит абый. – Шундый гүзәл җирдә чүп үләне үстереп буламыни?! Тау астыннан искән җил дә йомшак монда. Капка төбендә исә шифалы сулы чишмә ага. Ә җәен туктаусыз кошлар сайрый... Кыскасы, җәннәт бакчасы бу.

Рәшит абый Карашәмдә туып-үскән кеше. Гомерен Яшел Үзән шәһәрендә уздырган – тимер юлда утыз алты ел машина йөрткән. Шәһәрдә яшәсә дә, атна саен диярлек әти-әнисе йортына кайтып йөргән. Аннан исә әлеге йортны сатып алганнар. Җәмәгате Ризидә апа белән иртә яздан кара көзгә кадәр Карашәмдә яши алар. Кышны исә Яшел Үзәндә – үзләренең йортларында уздыралар. (Бер карасаң, шәһәрдә дә фатирда яшәмиләр, тик барыбер күңелләре авылга тарта, нишләтәсең...)

1

– Ризидә төп ярдәмчем. Сыннарны да ясагач, иң беренче аңа күрсәтәм, – диде Рәшит Хәмидуллин.

2

Останың әкият бакчасы...

– Төп йортта энекәш гаиләсе белән яши, – диде оста. – Шуның өчен дә аерым оя булдырасы килде. Бу йортка, Ризидәләрнең туганнарына, еш килеп йөрдек, урыны бик ошый иде. Кем уйлаган үзебезгә яшәргә насыйп булыр дип.

Хәмидуллиннар йортны 2010 елны сатып ала. Дистә ел эчендә әрем, кычыткан үскән җирдән гүзәл бакча ясыйлар. Хуҗа башта җәмәгате Ризидә апа белән капка төбенә чәчәкләр утырта. Аннан инде чәчәкләр янына күбәләк сыны ясап куя.

– Дөресен әйтим, сыннар өчен махсус материал сатып алганым юк, – диде Рәшит абый. – Кул астына нәрсә очрый, шуны эшкә җигәм. Кайвакыт чүплектән дә материаллар алып кайтам. Нигездә әкият, мультфильм геройларын ясыйм: Су анасы, Шүрәледән башлап, бүре, куян кебек җанварларга кадәр. Ел саен кимендә бер сын ясап куям инде. Коллекция тулыланып торырга тиеш бит.

Җәй азагы булуга карамастан, Хәмидулиннар ихатасы шау чәчәктә утыра иде. Гаҗәп түгел, хуҗа кеше аларга җәй буе икешәр сәгать су сипкән. Чәчәк түтәлләренең һәркайсының үз «сакчысы» бар: Убырлы карчык, җиһүле тычканнар дисеңме... Ә боларның барысын да өстән Карлсон «күзәтеп тора». Әйе, мультфильмдагы теге герой. Рәшит абый калын тимер чыбык сузган да, пенопласттан Карлсон ясап, шуны беркеткән. Нәтиҗәдә, җил искән саен мультфильм герое чыбык буйлап йөри.

– Аны быел ясадым, – диде Рәшит абый. – Яз башында шулай сыннарны яңартам – кайсын буйыйм, кайсының төшкән детальләрен яңартам. Кышка барлык сыннарны өйгә кертеп калдырабыз. Кар, яңгырда аның рәте китә бит. Язга исә тагын чыгарам. Ризидә төп ярдәмчем инде. Сыннарны да, ясагач, иң беренче аңа күрсәтәм.

– Авыл кешеләре бу гүзәллекне күреп таң калдымы соң? – дим.

– Төрле фикерләр ишеттек. Кайсы кешегә башта ошамады да. «Кыланышып яталар», – диюче дә булды. Ә болай халык моннан өзелми – кунакка кайтучылар да гел килә. Сыннар янында фотога төшәләр. Жираф, ишәк кебек сынында утырырга да мөмкин бит, алар агачтан ясалган, утыргач та берни булмый. Берничә ел рәттән Яшел Үзән район газетасы уздырган «Иң матур авыл йорты» конкурсында катнашабыз. Беренче урыннарны да алдык. Быел әле нәтиҗә чыгармадылар.

Хуҗаның тагын бер шөгыле турында әйтми мөмкин түгел – умартачы да ул. Дистә оя корты бар. Әтисе исән вакытында төп йортта да кортлар тоткан. Аннан инде умарталарны бу нигезгә күчергән.

– Кортларны үзем генә карыйм, балны сатабыз да, – диде Рәшит абый. – Быел уңыш әйбәт булды, Аллаһка шөкер.

Тәмле балдан без дә авыз иттек. Хуҗабикә – Ризидә апа чәйләр әзерләп көтеп торган иде. Ире кебек үк ачык, аралашучан кеше ул. Бер ул, бер кыз үстергәннәр, өч оныклары бар. Матур пар, бер-берсенә сөеп карыйлар. Бәлки әкият бакчасы да нәкъ менә шул мәхәббәт нәтиҗәсендә барлыкка килгәндер. Кешене мәхәббәт канатландыра бит.

«ӨЧ БАЛА ҮСТЕРӘБЕЗ»

Карашәм зур авыл түгел – 53 хуҗалык, 118 кеше яши. Советлар чорында ул бермәбер зуррак булган. Тик меңләгән авыл язмышы кебек үк, үзгәртеп кору елларында халык саны биредә нык кимегән. Нәтиҗәдә, бер дигән эшләп торган төп белем бирү мәктәбенең ишегенә йозак эленгән. Бүген ул буш тора. Авылда социаль объектлардан клуб, ФАП, мәчет, китапханә бар. Ә менә кибет ябылган, аның урынына автолавка килә. Ни хикмәт, кибет булмауны авыл кешесе проблемага санамый икән – күпләрдә машина бар. Кирәк-ярагын төяп алып кайталар.

Мәктәп ябылганга гына баштарак халыкның эче пошкан. Ни дисәң дә, мәктәпле авылның нуры була. Карашәмнең биш баласы

2

бүген сигез чакрым ераклыктагы Татар Танае урта мәктәбенә барып белем ала. Ул балаларның өчесе белән аралаштык та, чөнки алар бер йортта яши булып чыкты.

Хәялиевләр авылның күп балалы яшь гаиләсе. Һәм бердәнбер дип өстәргә кирәк. Зур йортта гөрләтеп яшәп яталар. Гаилә башлыгы – Илнур Карашәмнән, ә Зөлфия Кукмара районыннан. Икесенең дә даими эш урыны бар. Илнур Албаба юл төзелеше оешмасында эшли, Зөлфия Татар Танае урта мәктәбенә пешекче булып урнашкан. Гаилә корганнарына унбиш ел тулган.

– Бу нигезгә килен булып төшкәндә миңа егерме ике яшь иде, – дип елмайды Зөлфия. – Илнур төпчек малай, шуның өчен дә авылда калган иде. Дөресен генә әйткәндә, танышканда ук булачак иремнең ниятен белдем. Ләкин мине бу һич кенә дә куркытмады. Бер күрмәгән як булса да, Яшел Үзән районына күчеп кайтырга ризалаштым. Әле каенанам да бар иде. Бик матур каршы алды ул мине. Кызганыч, кисәк кенә мәрхүм булып куйды. Сабыр, бик тырыш иде, балаларны да үстереште.

Илнур белән танышып булмады – эшкә киткән иде. Аның каравы әтиләренә охшаган малайлар – Рәнис, Риназ белән аралаштык. Олысына ундүрт тула, икенчесенә унбер яшь. Өйдә төп ярдәмчеләр икән – мал да карашалар, бакча эшләрендә дә ярдәм итәләр. Әле җиде тула торган сеңелләренә дә күзколак булалар.

– Элек сыерлар тота идек, хәзер асрамыйбыз, көне буе эштә бит, – диде Зөлфия. – Үгезләргә иртән бер азык салгач, кичкә кадәр торалар. Җәен исә күп итеп кош-корт алабыз.

3
Карашәмнең берданбер күп балалы яшь гаиләсе – Хәялиевләр.

4
Авылның элеккеге мулласы, мәчет төзелешен башлап йөргән кешеләрнең берсе – Бәхтияр Шакиров.

– Авылда балалар аз булгач, улларыгыз белән кызыгызга күңелсез түгелме? – дим.

– Күңелсез түгел, алар болай да өчәү бит. Мәктәп чорында сыйныфташлары белән аралашалар, җәен исә авыл тулы кайткан бала була. Иремнең ике абыйсы, ике апасы бар. Җәй көне аларның балалары кайта. Гомумән, төп йорт булгач, бездән кеше өзелми.

– Зөлфия белән Илнур ачык, кунакчыл кешеләр, шуңа да туганнары гел монда, – дип сүзгә кушылды Рус Әҗәле авыл җирлеге башлыгы Гөлнара Семахина. – Авыл клубында берәр чара булса да гаиләләре белән чыгалар. Зөлфия бик матур җырлый, сәхнә күрке.

Зөлфия Кукмара районының Лубян урман хуҗалыгы техникумын тәмамлаган. Белгечлеге буенча хисапчы. Һөнәре буенча да эшләгән. Хәер, әле дә бу юнәлештән китеп бетмәгән – ашханәнең барлык документларын үзе алып бара.

– Балаларны иртән мәктәп автобусы килеп ала, мин дә алар белән йөрим, – диде Зөлфия. – Кичке дүрткә өйгә кайтып та җитәбез. Җитмеш биш балага көн саен кайнар ризык әзерлим.

– Үзең генә барысына да өлгерәсеңме? – дим.

– Әйе, өлгерәм. Кайчагында ит ризыкларын кичтән турап калдырам. Тиз эшләсәң җитешәсең.

Менә шулай итеп Кукмара кызы Яшел Үзәндә үз кешегә әйләнгән. Ә иң мөһиме – кечкенә авылга яңа сулыш өргән ул. Өч бала алып кайтуын әйтәм.

«КӨНДӘЛЕК АЛЫП БАРДЫМ»

Авылда мәчет бар дидем. Аны 2003 елда төзегәннәр. Бу эшне башлап йөрүчеләрнең берсе Бәхтияр абый Шакиров тугыз дистәне тутырган инде. Бүген ул кызы Гөлгенә тәрбиясендә яши.

– Ике ел элек әниебез вафат булды, шуңа да әтине үзебезгә алып килдек, – диде Гөлгенә апа. – Инсульт, инфаркт кичерде ул, аерым тәрбия кирәк.

Бәхтияр бабай мәрхүм хатыны Нәсимә апа белән дүрт бала – өч кыз, бер ул тәрбияләп үстергән. Балаларының барысы да башлы-күзле, матур тормыш корган. Атна саен диярлек әтиләре янына кайтып йөриләр. Бәхтияр бабай күп еллар төп нигезендә умарта тоткан. Бүген аның эшен уллары дәвам итә. Тик бал аертканда, кортлар караганда бабай әле дә төп киңәшче, сөялеп карап булса да тора.

– Минем бабам революциягә кадәр авылда мулла булган, – диде Бәхтияр абый. – Безнең авылда мәдрәсә дә эшләгән. Инде совет власте килгәч, барысы да җимерелгән. Туксанынчы еллардан соң, дин ирекле килгәч, без дә мәчет турында хыяллана башладык. Ләкин хыял әле тиз генә тормышка ашмады. Авылның зыялылары белән бер сөйләшкәндә

мәчет турында сүз чыкты. Ул да түгел, безнең авылдан чыккан Шакиров Шамил Шәйхи улы үзенә йорт салырга дигән барлык кирпечләрен мәчет төзелешенә дип бирде. Аның өлеше бик күп керде анда, кадагына кадәр кайтарды. Бүген Шамил Яшел Үзәндә яши, авылда йортлары бар, кайтып йөри. Озын гомерле, сау-сәламәт булсын.

Бәхтияр абый берничә авылдашы белән Казанга, ТР Мөселманнарының диния нәзарәтенә – ул чагындагы мөфти Госман хәзрәт Исхакый янына да бара. Мәчетне төзеп бетерү өчен мөфтият тә күпмедер акча бирә. Шулай итеп, күмәк көч белән 2003 елда Карашәмдә яңа мәчет ачыла. Мулла итеп Бәхтияр абыйны сайлыйлар.

– Менә бу муллалык чорында алып барылган көндәлегем, – диде Бәхтияр абый. – Күп еллар авылда бригадир булып эшләдем. Һәрнәрсәне теркәп бару гадәте шуннан да калган. Авылда булган тарихи вакыйгаларның берсен дә калдырмаска тырыштым. Киләчәк буыннарга бер ядкарь бит.

Бәхтияр абыйның көндәлегендә авыл клубы турында да язылган. «1967 елның 9 июлендә Карашәм авылы кешеләре өчен зур вакыйга – 350 урынлы яңа клуб бинасы файдалануга тапшырылды. Ул «Комсомолец» колхозы көче белән салынды», – дип язган ул. Нарат агачыннан салынган, заманына күрә бик яхшы булган клуб бүген дә эшли.

Илле биш ел элек салынган бинаны без дә карап чыктык. Агач тәрәзәләр пластикка алышынган, урындыклар да бүтән, ә идәннәре, ишекләре шул ук калган. Болай әле эшләрлек ул. Шунда ук китапханә дә урнашкан. Тарих белән сугарылган клубның һәр почмагын зур бер кызыксыну белән карап чыктык. Аның бүрәнәләре, түбә-идәннәре бик зур сер саклый төсле тоелды. Ничә буын үстергән, ничә идарә системасы алышынуын күргән бина бит ул.

– Вакытында капиталь төзекләндерү программасы буенча ремонт ясалса, бу клуб әле тагын дистә еллар халыкка хезмәт итәр иде, – диде Гөлнара Семахина. – Ләкин ул чакта без программага кертелмәдек. Яңа клуб турында сүз булган иде, хәтта урынын да карап куйган идек. Тик әлегә конкрет карар булмады. Карашәмдә халык бик актив, аларга клуб һичшиксез кирәк.

...Кечкенә авылларның үзенчәлеге – халык үзара тату һәм бик гади. Карашәм турында да шундый фикер туды. Аннары монда артык купшы йортлар юк – барысы да бертөрлерәк. Шуңа да без үскәндәге авылларны хәтерләтте ул. Гадилек, самимилек, шуның белән бергә тәртип, җыйнаклык бар биредә. Табигате аеруча әсир итте. Кыскасы, Карашәмгә тагын бер әйләнеп кайтасы килеп калды.

5
Илле биш ел элек салынган бинаны без дә карап чыктык.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Бәхтияр Шакиров, авылның аксакалы:
- Безнең авылларның бу урында бик күптән төпләнүен раслый торган бер язма бар. Ул – Карашәм кешеләренең нәсел шәҗәрәсе. Аны моннан 150 ел элек Габдеш улы Һидиятулла бабай төзегән. Үз чорының укымышлы кешесе булган. Һидиятулла бабай 1919 елны туксан яшендә Карашәмдә вафат булган. Шәҗәрәнең төп нөсхәсе Казан дәүләт университетының Лобачевский исемендәге китапханәсендә саклана. Менә шуннан күренгәнчә, Карашәм халкының беренче кешесе Абделхалыйк улы Дусмәмәт бабай булган. Ул 1350–1370 нче елларда әлеге урынга килеп төпләнгән булырга тиеш. (Хәзерге карьер.)
Авылның исеменә бәйле риваять бар. Күргәнебезчә, авыл түбәнлектә утыра. Бу урында наратлар үскән булган. Бабайлар моны күреп: «Кара әле, кара, шәм кебек төз утыралар», – дип сокланган. Шуннан авылның исеме Карашәм калган, имеш.

Ай кәефе: музыкаль

ЧАТ-РУЛЕТКАДА ТАТАР БАЯНЧЫСЫ

Раил Арсланов, шул ук ARSLAN – җырлар авторы, блогер, YouTube видеохостингының көмеш һәм алтын төймәләре иясе. Шактый зур музыкаль бэкграундка ия сәләтле башкаручы «Татарстанга» киләчәкнең инде монда булуы турында сөйләде.



– Үзеңне таныту теләге кайчан туды?

– 2009 елда, өйдә интернет пәйда булуга, Җир шарының ерак бер почмагында иҗатымны күрсәтергә мөмкин булуына нык гаҗәпләндем, башкаларның роликларын карадым. Һәм челтәр аша үземнең сәләтемне күрсәтәсем килде. Минем хыялга таба юлым Татарстандагы кечкенә генә Җәлил бистәсендә башланып китте.

– Тормышыгыз да кинәт үзгәрдеме?

– Интернет, минемчә, 21 гасырда уйлап табылган иң яхшы әйбердер. Бу үзеңне күрсәтү һәм үстерү өчен уңайлы мәйданчык кына түгел, бүген әле, мөгаен, күтәрелү һәм танылу өчен бердәнбер ысул дадыр, әлбәттә, әгәр син кызыклы әйберләр ясарга сәләтле булсаң.

Мин бөтен җирдә видео төшерәм: армия, уку яисә сәяхәт булсынмы... Ә аннан соң YouTubeтагы «Хижина музыканта» каналында боларның барысын да күрсәтәм. Бу минем тормышымның тарихы. Еллар үткәч, мин аларга кире әйләнеп кайта һәм кем, нинди булганымны карый алам. Видеода мин мәңге яшь калачакмын.

– Чатта аралашканнан соң дуслар каламы?

– Очраклы рәвештә чат-рулеткага килеп эләккән төрле ил кешеләре белән аралашканнан соң дөньяның төрле почмакларында күп кенә танышлар, элемтәләр кала. Кайберләре белән аралашуны дәвам итәм. Ләкин, әлбәттә, бу тере аралашуны беркайчан да алыштыра алмаячак.

– Әгәр син консерваторияне дистанцион тәмамласаң, музыка инструментларында шулай ук оста итеп уйный алыр идеңме икән?

– Әйе, иң мөһиме көчле теләк булырга тиеш. Консерватория, һичшиксез, төп белемне бирә һәм, иң мөһиме, нык тырышырга кирәклегенә инандыра. Хәзер минем заманча музыка нигезендә эшләнгән үз стилем бар. Мин музыкаль инструментларны һәм битбоксны кушам, гитара, баянга кушылып заманча җырлар башкарам. Алар интернетта да, телефон һәм радиода да яңгырый. Кызганычка каршы, вузларда боларга өйрәтмиләр. Ләкин бу яшьләрне нык җәлеп итә – чөнки мондый музыка күңелсез түгел.

– Музыкада ясалма интеллект... Аның киләчәге нинди?

– Музыка телен компьютерда сайлау һәм кушуны иҗат дип әйтә алмыйм. Музыка барыбер иҗади субстанция. Ә теләсә кайсы әсәр, шул исәптән музыка әсәре өчен дә төп фикер һәм идея мөһим.

– Миллион караучыны туплауга озак бардыңмы?

– 10 ел. Социаль челтәрләрдә беренче каналымны 2020 елда ачтым. Ул Татарстанда музыкага багышланган беренче блог иде. Чынлыкта бу гаять зур хезмәт – син үзең режиссёр да, сценарийны төзүче дә, актёр да, монтажлаучы да, ут һәм тавыш бирүче дә. Аның каравы күпме күнекмә аласың, алар тормышта кирәк була!

– Үзенең социаль челтәрен үстерү белән мәшгуль булганнарга нинди киңәш бирәсең?

– Иң мөһиме, экспериментлар ясауны дәвам итәргә. Һәм шул чагында нәрсә дә булса барыбер килеп чыгачак!

Барысы да бик гади – син кызык – сине карыйлар, тыңлыйлар, синнән өйрәнәләр. Шул...

Раил Арсланов фотолары

Реклама 16+

Кис тә
бүләк ит

«Татарстан»
журналының чәй
традицияләре

Җылы кешеләр
белән җылы очрашулар,
җылы теләкләр

101 еллык зирәклек
ТАТАРСТАН
журналы

ТАТАРСТАН

Журнал акыллы, игелекле, мәңгелек
кыйммәтләргә ия булган эксклюзив
открыткалар сериясе тәкъдим итә

чәй
– Чәй агызыгыз да
балкып торган
көзне каршылагыз!
ТАТАРСТАН
@PROTATARSTAN
Реклама 16+